ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Айдар Гайнетдинов**

# АДНАШ ХАФИЗНЫҢ «СИРАҖЕЛ-КОЛҮБ» ӘСӘРЕ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА АНЫҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Казан
2014

УДК 821.512.145
ББК 83.3(2Рос=Тат)
Г 17

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни мөхәррире**

*филология фәннәре докторы, профессор* ***М.И. Әхмәтҗанов***

**Рецензентлар:**

*филология фәннәре докторы, профессор* ***Х.Й. Миңнегулов,***
*филология фәннәре докторы, профессор* ***З.З. Рәмиев***

**Гайнетдинов А. М.**

**Г 17** Аднаш хафизның «Сиражел-колүб» әсәре һәм татар әдәбиятында аның традицияләре. – Казан: ТӘһСИ, 2014. – 168 б. – («Фәнни Татарстан» журналы китапханәсе» сериясе; 1 китап)

ISBN 978-5-93091-173-2

Китапта XVI гасырда яшәгән Аднаш хафиз бине Мөхәммәд Аднаш хафизның «Сиражел-колүб» әсәре беренче мәртәбә монографик планда анализлана, проблематикасы тикшерелә. Шулай ук әлеге әсәрнең XVII–XVIII гасырлар татар әдәбиятына йогынтысы ачыклана.

Хезмәт татар әдәбияты тарихын өйрәнүче студентларга, аспирантларга, мөгаллимнәргә, гомумән, татар халкы тарихы, әдәби мирас белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-173-2**

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2014
© Гайнетдинов А. М., 2014

# КЕРЕШ

XVI гасырның икенче яртысы, тарихтан белгәнебезчә, бик катлаулы чор булып санала. Бу – Казан ханлыгының шушы чорда яшәүдән туктавы белән бәйле. Күп кенә татарларның җирләре, йортлары, байлыклары тартып алына, ахыр чиктә диннәреннән дә ваз кичтерү куркынычы яный башлый. Монысы инде татар халкын, милләт буларак, бөтенләй юкка чыгару икәнен күпләр аңлый. Халык шундый авыр заманда нишләргә белми, динне, милләтне саклап калу мәсьәләсендә, нинди дә булса киңәшчегә, өйрәтүчегә мохтаҗ. Андый кеше табыла, аның исеме – Аднаш хафиз[1]. Ул зинданда утыруына карамастан, үз халкына акыллы киңәшләр бирә торган «Сираҗел-колүб» («Күңелләр чырагы») әсәрен иҗат итә һәм халыкка тапшыра. Бу әсәр гади дини әсәр булып тоелса да, анда, төрле кинаяләр аша, килеп туган проблемалардан чыгу юллары тәкъдим ителә. Автор халыкка киңәшләрен турыдан-туры бирә алмаган, чөнки моңа ирек тә бирелмәс иде. Шуңа күрә ул әлеге хезмәтендә кинаяләр кулланып эш итә. Бу әсәрне тарих белән бәйләп караганда гына тулысынча аңларга мөмкин. «Сираҗел-колүб» – синкретизм үрнәге, чөнки анда әдәбият, тарих, сәясәт, дин, фәлсәфә – һәммәсе дә бар.

---

[1] Халык арасында бу исемнең Адниш, Атнаш, Әтнәш вариантлары да кулланылышта.

Аднаш хафизның «Сиражел-колүб» әсәренең кыйммәте бәяләп бетергесез. Аның актуальлеге шунда ки, бу әсәр XVI гасыр татар әдәбиятын тулыландыра, баета. Хәзерге көндә, татар әдәбияты үрнәкләрен эзләү, барлау, төрле яктан өйрәнү заманында, «Сиражел-колүб» әсәре дә ныклап торып өйрәнүне таләп итә. Укыту прогаммаларында, дәреслекләрдә аны бөтенләй искә алмау, төшереп калдыру безнең әдәбиятыбызны фәкыйрьләтә генә. Киләчәктә бу әсәр бөтен дөньяга танылып, тирәнтен өйрәнелеп, татарларның горурланып сөйли торган хәзинәсенә әверелер, дигән өмет бар.

«Сиражел-колүб» әсәре татар әдәбияты тарихында аз өйрәнелгән язма әдәби истәлекләрнең берсе булып санала. Монографик планда исә ул бөтенләй өйрәнелмәгән. Аның татар халкы арасында шактый киң таралган кулъязма нөсхәләре һәм басма текстлары булуы мәгълүм.

Аднаш хафиз үз кулы белән язган «Сиражел-колүб» кулъязмасы Мәскәү шәһәрендә урнашкан Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана. Анда әдипнең тулы исеме, әсәрнең язылу вакыты, урыны күрсәтелгән: «Фи-т-тарих вә тукуз йөз алтмыйш бердә, җөмадиел-ахир аеның тулугунда тәмам булды. Ике китабдур, берсе “Сиражел-колүб”дүр, берсе “Шәраигыль-әхкям”дер. Әл-фәкыйрь әл-хәкыйрь Аднаш хафиз бине Мөхәммәд Аднаш хафиз язды. Чәһаршәнбе көн тәмам булды. Вә Аллаһү әгъләм (Аллаһ белүчерәк)! Мәскәүгә илче барганда, доснак торганда, андак бетелде»[1]. Әлеге датаны Әмир Нәҗип, чәршәмбе көнне ай тулганда язылган булганга, 1554 елның 16 маена туры килгәнлеген ачыклаган[2]. Димәк, Аднаш хафиз әсәрне 1554 елның 16 маенда Мәскәүгә

[1] Наджип Э.Н. Датированная тюркоязычная рукопись XVI в. «Сирадж ал-кулуб» из Центрального государственного архива СССР в Москве. М.: Изд-во восточной литературы, 1960. С. 2.

[2] Шунда ук.

илчелек составында барганда яза башлаган, шуннан соң Мәскәүдә ниндидер сәбәпләр белән төрмәгә утыртылгач, шунда язып бетергән булып чыга. Аның «хафиз» дигән титулыннан Коръәнне яттан белүче булган икәне аңлашыла. Кызганычка каршы, автор турында бүтән мәгълүматлар юк. Безнеңчә, Ә. Нәҗип «доснак» сүзен дөрес аңлатмаган, ул аны, Доснак дип аталган җирдә язып бетергән, дип яза. М. Гайнетдинов фикеренчә, «доснак» сүзе «тоткын» дигәнне аңлата[1]. Без үзебез дә шул фикердә.

Бер шигъри кульязмасының фрагменты Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә 39 нчы коллекция, 2308 нче шифр астында саклана. Ул 1979 елда галим М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан Азнакай районы, Сөендек авылында табыла. Димәк, әле әсәрнең шигъри варианты да булган. Ярты бит тәшкил иткән әлеге кульязма биттән бернинди дә нәтиҗә ясап булмый. Киләчәктә, бәлки, тулы шигъри варианты да табылса, аны прозада язылган әсәр белән чагыштырып, ниндидер нәтиҗәгә килергә мөмкин булачак.

«Сираҗел-колүб» әсәренең басмаларына килгәндә, ул берничә мәртәбә Казанда басылып чыга. Беренче мәртәбә 1863 елда Казан университеты табгыханәсендә нәшер ителә. 1864 елда шул ук табгыханәдә Казан мещаны Фәтхулла Хәмидулла углы Амашев иганәсе хисабына басыла. 1895 елда Казанда Чиркова, 1903 елда Казанда Кәримовлар табгыханәләрендә нәшер ителә. Шулай ук 1904, 1905, 1909, 1912 елларда басылып чыкканлыгы мәгълүм.

Татар әдәбияты тарихын тикшерүче Әмир Нәҗип (1899–1991) бу әсәрнең Казан ханлыгы дәверендә үк укылганлыгы

---

[1] Гайнетдинов М.В. «Сирадж ал-кулюб» // Средневековая татарская литература (XVI–XVIII вв.). Казань: ФЭН, 1999. С. 141.

һәм аның гарәпчәдән татарчага иҗади тәрҗемә ителгән кульязма булуы турында сөйли. 1960 елда шәрыкны өйрәнүче галимнәрнең XXV халыкара конгрессында ул доклад белән чыгыш ясый. Аның доклады СССРның Үзәк Дәүләт архивында (Мәскәү) саклanучы XVI гасырга караган «Сираҗелколүб» әсәре турында бара. Әмир Нәҗип бу әсәрне язган кеше турында кыскача белешмә бирә, әсәрнең нәрсә турында икәнлеген ачыклый, телен тикшереп чыга һәм аңлашылмый яки авыр аңлашыла торган сүзләреннән сүзлек төзи[1]. Шулай ук әлеге галим Аднаш хафизны күчереп язучы, милләте буенча төркмән дә булырга мөмкин, дип язса да, аның Идел буенда язылганлыгын таный[2]. М.Гайнетдинов исә, аңа кискен каршы чыгып, Аднаш хафизның татар булуын һәм «Сираҗел-колүб» әсәрен иҗат итүче икәнен дәлилли[3].

Әмир Нәҗиптән башка бу кульязма әсәрнең теле турында рус тюркологы А.М. Щербак та язып чыга. Ул аны «Сираҗелколүб» әсәренең Казан басмаларына бик якын, тел ягыннан да охшаш хезмәт булганлыгын исбатлый, бу әсәрнең күләменә, тарихына карата да мәгълүмат бирә. Шулай ук Лондонда Британия музеенда 1432 елда уйгыр хәрефләре һәм графикасы белән язылган, төрки телгә тәрҗемә ителгән мәҗмуга кульязмасы барлыгы турында яза. Бу мәҗмугага «Сираҗел-колүб» әсәре дә кертелгәнлеген күрсәтә[4].

А.М. Щербак китергән В.В. Бартольд фикерләренә таянып, без «Сираҗел-колүб» әсәренең беренче мәртәбә гарәп телен-

---

[1] Наджип Э.Н. Датированная тюркоязычная рукопись XVI в. «Сирадж ал-кулуб» из Центрального государственного архива СССР в Москве. М.: Изд-во восточной литературы, 1960. С. 3–11.

[2] Шунда ук. С. 2–3.

[3] Гайнетдинов М.В. «Сирадж ал-кулюб» // Средневековая татарская литература (XVI–XVIII вв.). Казань: ФЭН, 1999. С. 146.

[4] Щербак А.М. Рукописный сборник Or. 8193 и его значение для узбекской филологии // Советская тюркология. Баку, 1983. № 3. С. 72–74.

дә язылган булуын һәм гарәпчәдән фарсычага, фарсычадан төркичәгә күчерелгәнлеген аңлыйбыз[1].

А.М. Щербак язганча, әйтеп үтелгән мәҗмуга Иранның Йезд шәһәрендә төзелә. Аның төзүчесе Мансур Бахши исемле кеше була[2].

Ихтимал, Британия музеендагы нөсхә Алтын Урда әдәби традицияләре буенча уйгыр хәрефләре белән төрки телгә тәрҗемә ителгәндер. Чөнки Иранда төрки әдәбият традициясе 1432 елларда күренми. Шунлыктан, «Сираҗел-колүб» әсәрен Иранга килгән Алтын Урда укымышлысы эшләгәндер, дигән фикер туа. Чөнки уйгыр хәрефләре белән язу традициясенең үзәге Алтын Урдада була. Бу дәүләттә хан ярлыклары, Харәзминең «Мәхәббәтнамә» әсәре кульязмасы һәм башка уйгыр хәрефләре белән язылган төрки әсәрләр дә булуы мәгълүм.

«Сираҗел-колүб» әсәре турында шулай ук хәзерге татар әдәбиятчысы Мәсгуд Гайнетдинов та үз фикерен әйтә. Ул бу әсәргә анализ ясый, әсәрнең кыйммәтен күрсәтә[3].

Бу хезмәттә Мәскәүдә сакланган «Сираҗел-колүб» кульязмасы белән аның Казанда басылган нөсхәләре арасындагы эчтәлек һәм тел ягыннан булган якынлыкларны искә алып, аны татар әдәбияты истәлеге итеп карап өйрәнү максат итеп куелды.

Аның структурасын Лондондагы текст структурасы белән чагыштыру алар төрле дәвердә төрле әдипләр тарафыннан, үз заманы вазгыяте таләпләреннән чыгып язылуын күрсәтә, авторларының тәрҗемәдә үзләренең фикерләрен керткәннәре сизелә.

---

[1] Щербак А.М. Рукописный сборник Or. 8193 и его значение для узбекской филологии // Советская тюркология. Баку, 1983. № 3. С. 73.

[2] Шунда ук. С. 72.

[3] Гайнетдинов М.В. «Сирадж ал-кулюб» // Средневековая татарская литература (XVI–XVIII вв.). Казань: ФЭН, 1999. С. 141–147.

Инглиз галиме Дж.Р. Уолшның язуына караганда, фарсы телендә язылган яки тәрҗемә ителгән «Сираҗел-колүб» әсәрендә 70 фасыл, икенче фарсы кульъязмасында 33 фасыл бар[1]. Димәк, фарсы әдәбиятында Ирандагы проблемалар гарәп теленнән тәрҗемә ителгән «Сираҗел-колүб» әсәренә кертеп җибәрелә.

Аднаш хафиз «Сираҗел-колүб» әсәрен 40 фасылда эшли. Ул татар халкы яшәешендәге проблемаларны әсәрендә яктыртып, кирәклеләрен генә сайлап алып һәм, бәлки, үзеннән дә өстәп иҗат иткән булырга тиеш.

Лондонда, Иранда, Мәскәүдә сакланучы «Сираҗел-колүб»-нең безгә мәгълүм булган текстлары асыл гарәп чыганакларыннан хасил булып, һәр регионның үз заманы проблемаларына яраштырып, иҗади эшкәртелеп тәрҗемә ителгәннәр. Аларның барысына да нигез булган гарәп телендәге «Сираҗел-колүб» әсәренең төзелеше турында хәзергә төгәл итеп бер фикер дә әйтеп булмый, бәлки, ул киләчәктә бер ачылыр.

Бу хезмәт татар әдәбияты белемендә Аднаш хафизның «Сираҗел-колүб» әсәренә багышланган беренче монографик тикшерү булып тора. Хезмәттә әсәргә анализ ясала, Аднаш хафизның татар әдәбияты һәм тарихындагы урыны һәм роле билгеләнә, аның башка әдипләргә ясаган йогынтысы тикшерелә. Аднаш хафиз ислам дине генә татарларны милләт буларак юкка чыгудан коткарып калачагын аңлап ала. Ул ислам дине тарихына караган чыганакларны барлап, үзенең киңәшләрен, гади халыкка аңлавы җиңел булсын өчен, әдәбият аша бирә. Аднаш хафиз иҗатының әһәмияте менә шунда чагыла.

[1] Щербак А.М. Рукописный сборник Or. 8193 и его значение для узбекской филологии // Советская тюркология. Баку, 1983. № 3. С. 73.

# 1. «СИРАҖЕЛ-КОЛҮБ» ӘСӘРЕНЕҢ ЧЫГАНАКЛАРЫ, СТРУКТУР БҮЛЕНЕШЕ

Урта гасырларда әдәби әсәрләр дин белән тыгыз бәйләнгән була. Татар әдәбияты да Коръән, хәдисләрдән алынган фикерләр, сюжетлар, образ-сурәтләр белән тирәнтен сугарылган. Гасырлар дәвамында ул татар кешесен шушы кыйммәтләр ярдәмендә рухи азыкландырган һәм әхлакый тәрбияләгән. Ислам дине мифологиясе, тарихы, шәригать өйрәтмәләре матур әдәбият аша укучы күңеленә ирештерелгән. Кыскасы, ислам диненең урта гасыр әдәбиятына йогынтысы бик көчле булган.

Аднаш хафизның «Сираҗел-колүб» әсәре дә ислам идеологиясе һәм фәлсәфәсе белән үрелеп бирелгән. Аны чып-чын дини әсәр буларак та карарга мөмкин. Чөнки ул синкретик әсәр.

«Сираҗел-колүб» әсәренең чыганакларына килгәндә, аның үзәген Коръән һәм хәдисләр тәшкил итә. Һәрбер дини әсәрдә бу ике чыганак төп чыганаклар булып киләләр. Алар бер-берсеннән аерылгысыз дияргә мөмкин. Чөнки Коръәнне хәдисләрдән башка дөрес аңлап булмый, ә хәдисләр исә шул ук Коръәннең өйрәтмәләрен тәшкил итәләр.

«Тарихи, риваяти, фәлсәфи аңлатмаларны эченә алган Коръән тәфсирләре һәм хәдисләр ислам мәдәнияте даирәсендәге халыклар өчен урта гасыр әдәбияты тарихын

яктыртканда да, ислам фәлсәфәсе һәм дин тарихын язганда да бәһасез кыйммәткә ия чыганак саналалар»[1].

Хәдисләр Коръәннән кала икенче урында тора. Мәшһүр хәдисләр җыентыкларын түбәндәге кешеләр төзиләр:

1. Әхмәд бине Хәнбәл. Тулы исеме Әбү Габдуллаһ Әхмәд бине Хәнбәл әш-Шәйбәни. Күренекле дин галиме, фәкыйһ һәм хәдисләр белгече. Аның дини карашлары аерым бер мәзһәб тудыра. Аны «хәнбәлиләр мәзһәбе» дип атый башлыйлар. Әхмәд бине Хәнбәл һиҗри ел буенча 164 елның рабигыль-әүвәл аенда туа. Кечкенә чагыннан ук Багдад шәһәрендә хәдисләр, фикыһ һәм башка шәригать гыйлемнәрен өйрәнә башлый, соңыннан укуын Шам, Хиҗаз, Йәмән шәһәрләрендә дәвам итә. Аның хәдисләр җыентыгы «Әл-Мөснәд» дип атала. Галим аларны 750000 хәдис арасыннан сайлап ала. Ул һиҗри ел буенча 241 елда рабигыль-әүвәл аеның 12 нче көнендә вафат була.

2. Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Бохари. Тулы исеме Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд бине Исмәгыйль бине Ибраһим бине әл-Мугыйра бине Бәрдизбах әл-Җөгъфи әл-Бохари. Ул һиҗри ел буенча 194 нче елның шәүвәл аенда Бохара шәһәрендә туа. Кечкенә чагыннан ук хәдисләр өйрәнә башлый һәм күп еллар гыйлем эстәп сәяхәттә йөри. Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Бохари Әхмәд бине Хәнбәл, Яхья бине Мәгыйн, ибне әл-Мәдини, әл-Хәмиди һәм башка күренекле дин галимнәреннән хәдисләр китерә. Аның шәкертләре булып Мөслим, Нәсаи, Тирмизи, Фирабри кебек галимнәр санала. Бохариның «Әт-Тәрих әл-Кәбир», «Әл-Әдәб әл-Муфрад» җыентыклары булуы мәгълүм. Ләкин иң зур хезмәте булып «Әл-Җәмигъ әс-Сахих» исемле хәдисләр җыентыгы санала. Анда 7563 хәдис туплан-

[1] Хисамов Н.Ш. Энциклопедик хезмәт, яки руханият дигән гыйлем бар // Хәтер сагында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. Казан: Мәгариф, 2004. Б. 399.

ган, галим аларны 600000 хәдис арасыннан сайлап ала. Бу китап, әһәмиятлелеге ягыннан, Коръәннән кала икенче урында тора. Бохари һиҗри ел буенча 256 елда вафат була.

3. Мөслим бине Хәҗҗаҗ. Тулы исеме Мөслим бине әл-Хәҗҗәҗ әл-Кушәйри ән-Нишапури. Ул һиҗри ел буенча 204 елда Нишапур шәһәрендә туа. Кечкенә чагыннан ук хәдисләр өйрәнә башлый һәм күп еллар гыйлем эстәп Гыйрак, Хиҗаз, Шам һәм Мисыр илләре буенча сәяхәттә йөри. Бохари, Әхмәд бине Хәнбәл, Яхъя бине Мәгыйн, Әбү Хәйсамә һәм ибне Әбү Шәйбә кебек галимнәрдән гыйлем ала. Үзе исә, Тирмизи, ибне Әбү Хатим, Ибраһим бине Мөхәммәд бине Суфьян исемле шәкертләрне тәрбияли. Мөслимнең «Әл-Җәмигъ әс-Сахих», «Әл-Гыйләл», «Әл-Вәхдән» исемле хезмәтләре билгеле. Иң зур хезмәте булып «Әл-Җәмигъ әс-Сахих» исемле хәдисләр җыентыгы санала. Анда 9200 хәдис тупланган. Галим аларны 220 хәдис белгечләреннән җыя. Бу китап, абруйлылыгы буенча, Бохари җыентыгыннан соң икенче урында тора. Мөслим һиҗри ел буенча 261 елның рәҗәб аеда вафат була.

4. Әбү Дауд Сөләйман бине Әшгас. Тулы исеме Әбү Дауд Сөләйман бине Әшгас бине Исхак әл-Әзди әс-Сиҗистани. Ул һиҗри ел буенча 202 елда Сиҗистан шәһәрендә туа. Әбү Дауд Әхмәд бине Хәнбәлнең шәкерте була, үзе исә Тирмизи, Нәсаи кебек танылган хәдис белгечләрен укыта. Ул, үзенең әйтүе буенча, 500000 хәдис җыйган. Бик күп хезмәтләре билгеле, алар арасыннан иң мәшһүре – «Әс-Сөнән» җыентыгы. Анда 4800 хәдис тупланган. Галим һиҗри ел буенча 275 елның шәүвәл аенда вафат була.

5. Мөхәммәд бине Гайсә әт-Тирмизи. Тулы исеме Әбү Гайсә Мөхәммәд бине Гайсә бине Сура әт-Тирмизи. Күренекле хәдис белгечләренең берсе. Ул һиҗри ел буенча 209 елда Тирмиз шәһәрендә туа. Бохариның шәкерте була. «Әл-Җәмигъ» исемле хәдисләр җыентыгын төзи. Соңыннан бу җыентык

«Сөнән әт-Тирмизи» дип йөртелә башлый. Анда 4000 хәдис тупланган. Галим һиҗри ел буенча 279 елда, рәҗәб аеның 13 нче көнендә вафат була.

6. Әхмәд бине Галиән-Нәсаи. Тулы исеме Әбү Габдрахман Әхмәд бине Гали бине Шогаеб бине Галиән-Нәсаи. Күренекле хәдис белгечләренең берсе. Хорасан шәһәреннән ерак түгел Нәса дип аталган җирдә һиҗри ел буенча 215 елда дөньяга килә. Хәдисләрне һәм аларның методологиясен ныклап өйрәнгәч үзенең «Сөнән ән-Нәсәи» дигән хәдисләр җыентыгын төзи. Аның бу хезмәте дөреслеге буенча әл-Бохари һәм Мөслимнең җыентыкларыннан гына калыша. Шулай ук ән-Нәсәи Гали бине Әбү Талибның күркәм сыйфатлары турындагы хәдисләрне җыеп янә бер җыентык төзи. Галим һиҗри ел буенча 303 елда, сәфәр аеның 13 нче көнендә Рәмлә шәһәрендә вафат була, Иерусалим шәһәрендә күмелә.

7. Мөхәммәд бине Язид бине Маҗә. Тулы исеме Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд бине Язид бине Маҗә әл-Казвини. Һиҗри ел буенча 207 елда туа. Хәдисләрне һәм шәригать гыйлемен ул Мәлик бине Әнәс һәм әл-Ләйс шәкертләреннән өйрәнә. «Сөнән ибне Маҗә» исемле хәдисләр җыентыгы авторы. Аның бу хезмәтендә, дөрес хәдисләр белән, беррәттән зәгыйфь һәм хәтта шикле, ялган хәдисләр дә тупланган. Галим ибне Маҗә һиҗри ел буенча 273, кайбер риваятьләр буенча 275 елның рамазан аенда вафат була[1].

Әдәби әсәрләргә килсәк, «Сираҗел-колүб» әсәре Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» һәм авторы билгесез «Мәликә китабы» белән охшаш, күп җирләре тәңгәл килә диярлек. «Сираҗел-колүб»нең бу әсәрләрдән соңрак язылуын исәпкә

---

[1] Аль-Аскалани А. Булуг аль-Марам. Достижение цели; пер. с араб. Э. Кулиева. М.: Умма, 2006. С. 347–349.

алып, аларны төп чыганаклар дип карарга мөмкин. Әлбәттә, бу әсәрдә суфичылык әдәбияты элементлары булганлыктан, Хуҗа Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани әсәрләре дә, чыганак буларак, файдаланылгандыр, дигән фикер туа.

«Сираҗел-колүб» текстында да Аднаш хафиз үзенең хезмәтен язганда бик күп чыганаклардан файдаланганлыгын белдерә. Бу турыда ул еш кына «риваять кылдылар», «риваять кылыр», «хәбәрдә килгән», «шулай килмеш» һ.б. дип әйтә һәм кайбер исемнәрне дә күрсәтә. Алар арасында, мәсәлән, Габдулла бине Габбас, Әбү Һөрәйрә, Мансур бине Гаммәр, Ваһеб бине Мүнәббиһ әл-Йәмәни кебек күренеклеләр бар. Ул шулай ук Коръәннән аятьләр китереп үзенең фикерләрен дәлилли.

Аднаш хафиз үзенең әсәрен фарсы теленнән тәрҗемә ителүен әйтә. Фарсы теленә исә бу әсәр гарәп теленнән күчерелгән була. Ләкин Аднаш хафизның «Сираҗел-колүб» әсәрен турыдан-туры тәрҗемә дип карарга ярамый. Чөнки язучы бу әсәргә, үзенең яшәгән чорына карап, үз субъектив фикерләрен керткән булса кирәк.

Әдәби әсәрләр башка җирлеккә йә оригиналда, йә тәрҗемәдә үтеп керә. Бер үк яки якын телләрдә сөйләшә торган халыклар өчен тәрҗемә кирәкми. Урта гасыр Шәрык әдәбиятлары өчен бу – киң таралган күренеш. Урта гасырларда фарсы теле, мәсәлән, шигърият теле булып саналган һәм фарсы телендә иҗат ителгән әсәрләр киң туфракта таралып, тәрҗемәсез укылып йөргән. Шундый ук күренеш белән без төрки әдәбиятларда да очрашабыз.

«Тәрҗемә – чит әдәбиятны үзләштерүдә киң кулланылган алым. Сүз, турыдан-туры тәрҗемәдән бигрәк, иҗади тәрҗемә турында бара. Бу очракта әдәби әсәр яңадан туып, яңа тормыш белән яши башлый, әсәрнең оригиналы үрнәк буларак кулланылган булып чыга. Оригиналда йә тәрҗемәдә укыла килгән әдәби әсәрләрнең вакыт белән җирле әдәбиятка да йогынтысы

күзәтелә башлый. Моның 2 төрен күрсәтәләр: әдәби йогынты һәм әдәби алынма»[1]. Әдәби йогынты – әдәби иҗатка билгеле бер күзаллауның, фикерләрнең, сәнгати принципларның тәэсир итүе. Әдәби алынма дип язучы тарафыннан аерым сюжет, мотив, текст өлешләрен, сөйләм үрнәкләрен һ.б.ның кулланылуын атыйлар[2].

«Сиражел-колүб» әсәренең структурасын карап чыгыйк. Структур яктан аны 40 бүлеккә бүләргә мөмкин, чөнки анда 40 сорауга җаваплар карала.

Әсәрнең язу алымы – сорау-җавап. Бу алым үз чорында бик популяр була. Мисал өчен «Мәликә китабы»н китерергә мөмкин. Анда 100 сорау һәм аларга Коръән, сөннәт, хәдисләр белән җаваплар китерелә. Сорау-җавап формасы һәрвакыт иң яхшы укыту ысулы буларак кулланылган һәм кулланыла, чөнки ул аерым кешеләрне мавыктыру, кызыктыру һәм белемнәрне тиз отып калу, өйрәнү функцияләрен үтәргә дә сәләтле. Коръән үзе бу алымның иң зур мисалы булып тора. Анда бик күп урыннарда: «Һәм алар синнән ... турында сорыйлар», «Нәрсә белдертте сиңа … турында?» һ.б. шундый сорау формасындагы аятьләрдән соң җаваплар китерелә.

Бер хәдистә дә Җәбраил фәрештә Мөхәммәд пәйгамбәр янына килеп утыра һәм аңа бер-бер артлы ислам, иман, ихсан, кыямәт көне турында сораулар бирә. Мөхәммәд пәйгамбәр аларга җавап бирә. Аның янында утырган сәхабәләре бу сорауларның җавапларын бик тиз истә калдыралар һәм бу аларга карата бер өйрәтү алымы була.

---

[1] Мөхәммәтов И.Р. Татар-төрек әдәби багланышлары яссылыгында Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы: филол. фән. канд. дис. Казан, 2006. С. 16.

[2] Хализев В Е. Теория литературы. М.: Высшая школа, 2002. С. 406–407.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам үзе дә ничә тапкыр үзенең сәхабәләрен җыеп, аларга: «Сез ничек уйлыйсыз, нәрсә ул..?», «Сез беләсезме, нәрсә ул..?» кебек сораулар биреп, башта үзләренә җавап бирергә мөмкинлек тудырган, аларны фикерләргә мәҗбүр иткән, соңыннан бу сорауларның дөрес җавабын үзе биргән.

Шундый сораулар һәм җаваплар аркасында безгә ислам мирасының күп өлеше килеп җитә. Еш кына пәйгамбәр янына ерактан килгән бер кеше сораулар биреп җавап алганда, шунда алар янында утыручыларга да бу бер дәрес булган. Фикыһ гыйлеменең асылында кеше, әгәр нәрсә дә булса белми икән, ул белгән кешеләрдән сорарга тиеш, чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйткән: «Әгәр дә сез нәрсә дә булса белмисез икән, гыйлем ияләреннән сорагыз» («Нәмел» («Умарта кортлары») сүрәсе, 43 нче аять). Бу – сорауның гыйлем дөньясын ачу ачкычы булуы сәбәпле әйтелгән.

Әлеге алымны Аднаш хафиз да үзенең әсәрендә оста кулланган.

40 саны татар әдәбиятында да, шәрык әдәбиятында да ниндидер тылсымлы сан буларак билгеле. Әкиятләрдә дә батыр егет 40 көн һәм 40 төн чабып каядыр бара һ.б. Шулай ук әсәрләрне дә 40 бүлектән язып 40 саны белән атау бик киң таралган ысул. Мисал өчен «40 вәзир кыйссасы», «40 хәдис», «40 бакча», «40 тартма яки очкыннар», «40 карак», «40 сөаль китабы», «40 фарыз» һ.б.

Мәхмүд әл-Болгариның да «Нәһҗел-фәрадис» әсәре башында бер хәдис китерелә. Ул хәдискә караганда, әгәр берәү пәйгамбәрнең кырык хәдисен икенчеләргә өйрәтсә, ул кеше галимнәр җөмләсеннән санала, ә үлгәч шәһитләр (дин юлында корбан булучылар) рәтендә була.

Мәхмүт Гали әл-Болгари нәкъ шулай эшли дә: ул үзенең китабын дүрт бабка, һәр бабны ун фасылга бүлә, һәр фасыл

бер хәдис белән башланып китә. Димәк, автор пәйгамбәрнең кырык хәдисен укучыларына җиткерә һәм шуның белән үзенә оҗмахка юл ача[1].

Бәлки, шул хәдискә таянып, Аднаш хафиз да шундый максатларны күздә тотып язгандыр. Аның бөтен бүлекләре хәдисләр булмаса да, барыбер Коръәннән һәм буыннан-буынга сөйләнеп килгән дини риваятьләрдән төзелгән. Алар барысы да хәдисләр кебек каралырга мөмкин.

«Сиражел-колүб» әсәрендә пәйгамбәребезгә яһүдиләр 38 сорау бирәләр һәм ул аларга үзе җавап бирә. Ә 2 сорауны яһүдиләр ул вакытта инде хәлифә итеп сайланган Гомәргә әзерлиләр. Ләкин Гомәр бу сорауларга җавап бирә алмый. Шунда аңа Гали исемле сәхәбә дөрес һәм тапкыр җавап таба. Шулай итеп, сорауларның саны кырыкка тула. Монда Галинең Гомәрдән өстенлеге күрсәтелә. Гадәттә, Гали – татар әдәбиятында еш сурәтләнә һәм мактала торган образ. Мәсәлән, «Кисекбаш китабы»нда Галинең ниндилеге-кемлеге ачык сурәтләнә. «Ул юмарт һәм дәрәҗә иясе, шул вакытта гали дә, ягъни көч иясе, бөек кеше дә икән. Китапларда Шаһимәрдан, Шаһивилаять, Шире-Хода кушаматлары белән аталып йөртелә. Һиҗрәткә кадәр 23 ел элек, 599 елда Мәккә шәһәрендә дөньяга килә. Әбу-Талипның дүртенче улы була. Абыйлары: Талип, Гакыйль һәм Җәгъфәр. Җәгъфәр исә аннан – ун, Гакыйль – егерме яшькә өлкәнрәк. Әнисе – Фатыйма, Әсәд кызы бине Һашим. Хатыны – Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Фатыйма (чибәрлеге өчен «Зөһрә» дип атап йөрткәннәр), аларның никахыннан данлыклы Хәсән белән Хөсәен исемле уллары туган, имамлык мәртәбәсенә ирешкәннәр. Галинең Зәйнәп исемле хатыныннан өч ир баласы һәм бүтән хатын-

---

[1] Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 222.

нарыннан барысы бергә унсигез баласы булган. Гали сәхабә Бәдер сугышында үзен батыр итеп күрсәтә, уналты җәрәхәт ала. Гадел, чибәр, матур сүзле, шагыйрь, бик оста оратор-хотбәче, галим буларак таныла. Ислам дине өчен җанын фида кылырга әзер торган. Аның дәверендә мөселманнар ике тарафка бүленеп, хариҗиләр хәрәкәте – икенче төркем мәйданга чыккан. Бу каршылыклар тиз арада шактый зураеп, соңыннан Гали сәхабәнең һәлакәтенә китергән. 661 елда Гали Арысланны (Арыслан – төрки халыкларда киң таралыш тапкан кушамат, фарсылардагы Шир вариантына туры килә) хариҗиләрдән Габдеррахман бине Мөлҗим дигән мөэмин Күфә шәһәренең мәсҗидендә кылыч белән чәнчеп үтергән. Шул заманнардан бирле Гали сәхабәне суфи-дәрвишләр үзләренең рухи аталары дип саный башлаганнар, аның исеме белән рәсми дин башлыкларына карата тискәре мөнәсәбәттә булуларын белдергәннәр. Урта гасырларда кызылбашлар хәрәкәтенә бәйле шигыйлар да аның исеме астында хәрәкәт иткәннәр»[1]. «Сиражел-колүб» әсәрендә Галинең өстен куелуы авторның үзенең дә суфи булганлыгы белән аңлатыла.

Әсәрне тематик яктан өч өлешкә бүләргә мөмкин: ярату, ахирәт, кыйссалар.

«Сиражел-колүб» традицион рәвештә Аллаһы Тәгаләгә дан китерү һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә салават-шәрифләр әйтү белән башланып китә. Бу традициянең нигезе турыдан-туры Коръәнгә һәм хәдисләргә барып тоташа. Хәдисләрдә: «Аллаһы Тәгаләне зикер итүче һәм зикер итмәүче тере белән мәет кебектер»[2]. Шулай ук «Мин телгә алындым икән, шун-

---

[1] Яхин, Ф.З. Урта гасырлар татар әдәбияты: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Икенче басма. Казан: Раннур, 2003. Б. 181.

[2] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль Ибрагим», 2002. С. 58.

да ук миңа салават әйтелсен, чөнки кем миңа бер мәртәбә салават әйтә, шуңа Аллаһ Тәгаләнең ун рәхмәте булыр»[1], дигән хәдис бар. Коръәндә Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт истә тотарга һәм мактау-хәмедләр әйтергә боерган аятьләр дә күп. Коръәннең беренче сүрәсе дә: «Чын мактау галәмнәрне, бөтен мәхлукларны тәрбияләүче Аллаһы Тәгаләгә тиешле», дигән аять белән башлана («Фатиха» («Ачучы») сүрәсе, 2 нче аять). Шулай ук пәйгамбәребезгә салават әйтү дә Коръәндә боерыла: «Аллаһ Үзе вә фәрештәләре пәйгамбәр галәйһиссәламгә салават әйтәләр: "Ий, мөэминнәр, сез дә пәйгамбәргә салават әйтегез һәм сәлам әйтегез!"» («Әхзаб» («Гаскәрләр») сүрәсе, 56 нчы аять).

## 1.1. Әсәрдә дөнья яратылышы тасвиры

Әдип бөтен галәмнәрнең яратылышын тәфсилләп сурәтли.

Иң беренче итеп Аллаһ бер гәүһәрне бар итә, аны суга әйләндерә һәм ул җәелә, ташый, күбекләнә, төтене чыга. Төтененнән күкләр бар кылына, күбекләреннән җиде кат җир барлыкка килә[2].

Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә дә яратылыш «Сиражел-колүб» әсәренә охшаш рәвештә сурәтләнә. Анда язылганча, Хак Тәгалә барча мәхлукларны яратканчы бер гәүһәрне бар кылды. Үзенең бөеклеге һәм мәһабәтлеге белән шул гәүһәргә карады – гәүһәр эреп су булды. Ул су хозурына җил истерде – судан дулкыннар күбекләнеп, пар чыкты. Шул пардан күкне яратты, күбектән Кәгъбә урыны кадәр җир бар итте. Аллаһы Тәгалә гәүһәргә үзенең мәһабәтлеге белән карагач, гәүһәр икегә бүленде. Бер кисәге су, икенчесе ут булды.

---

[1] Мең дә бер хәдис. Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2003. Б. 79.

[2] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 4.

Су утка аккач, күбекләнеп төтен чыкты. Шул төтеннән күкне, күбектән җирне яратты һәм аларны җидешәр кат итте[1].

«Мәликә китабы»нда Аллаһ алдан «Кяф» белән «Нун»ны бар кылды, диелгән. Ягъни, бу ике хәрефтән «Күн» («Бул») дигән сүз ясала. Шул сүз белән Аллаһ бөтен мәхлукатьне бар итә[2]. Ләкин монда гәүһәр турында бер сүз дә юк.

Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабында «башта акыл яратылган» диелгән, соңыннан – нур, каләм, Ләүх, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сурәте, гареш, көрси, дүрт бөек фәрештә, сигез җәннәт, бер җәүһәр һәм аннан су белән ут, судан пар һәм томан, болардан исә җиде күк, җиде җир, соңра Каф тавы, ай һәм кояш, җәһәннәм, җен, фәрештә, Адәм һәм Хәвва. Ай һәм кояш башта бергә яратыла, соңыннан аерылалар. Гәүһәр (әсәрдә «җәүһәр» дип бирелгән) иң беренче яратылган нәрсә дип түгел, ә акыл, нур, каләм, Ләүх, Мөхәммәднең сурәте, гареш, көрси, фәрештәләр, җәннәттән соң гына бар ителгән дип әйтелә. Шул гәүһәрдән «Сиражел-колүб» әсәрендәге кебек төтен һәм күбек түгел, ә пар һәм томан яратыла, диелгән[3].

Традицион ислам динендә гәүһәр турында бер сүз дә әйтелми. Коръәнгә мөрәҗәгать итсәк, анда болар турында кыскача әйтелә: «Күн фәйәкүн» («Бул һәм ул булды»). «Бер нәрсәне булдырырга теләсә, фәкать: “Бул!” – дияр, ул нәрсә Ул теләгәнчә бар булыр» (Гыймран сүрәсе, 47 нче аять).

Хәдисләрдән килгәнчә, Аллаһы Тәгалә иң беренче: «Бул!» – дип әйтә һәм каләм белән ләүх барлыкка килеп, бөтен мәхлукатьның тәкъдирен яздырта. Шуннан соң күкләр, җирләр

---

[1] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 7.

[2] Мәликә китабы / Китапны нәшер итү өчен әзерләүче Ш.Х. Зәбиров. Казан: Идел-пресс, 2002. Б. 10.

[3] Чәләби М. Мөхәммәдия китабы. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1890. Б. 7–31.

һ.б. нәрсәләрне барлыкка китерә. «Сахих әл-Бохари» җыентыгындагы 1114 нче хәдистә китерелә: «Башта Аллаһы Тәгалә генә булган һәм аннан башка бер нәрсә дә юк иде, аның гареше су өстендә торган. Ул бөтен нәрсәләрнең тәкъдирен Ләүхел-Мәхфүзгә яза, күкләр һәм җирләрне бар итә»[1].

Хәдистә күренгәнчә, Ләүхел-Мәхфүзгә бөтен нәрсәләрне яздырып бар итә башлаганчы, Аллаһы Тәгаләнең гареше инде булган. Димәк, гареш – иң беренче яратылган нәрсә булып чыга.

Коръәндә дә, хәдисләрдә дә мәхлукларның яратылыш тәртибе һәм хронологиясе төгәл, ачык бирелмәгән. Бу исә язучыларның үз фантазияләренә һәм күзаллауларына бәйле рәвештә сурәтләүгә юл ачкан. Шуңа күрә төрле әсәрләрдә галәмнәр яратылышы төрлечә сурәтләнгән. Күргәнебезчә, «Сираҗелколүб» әсәре чагыштырмача «Кыйсасел-әнбия» әсәре белән тәңгәл килә.

«Сираҗел-колүб» әсәрендә Аллаһ җирне бер үгез өстенә урнаштыра, ул үгез үзе бер зур балык өстендә тора, җирне бер фәрештә ике элге белән тотып тора, диелгән[2]. Мондый күзаллау – урта гасыр кешесенең типик күзаллавы. Бу инде әле фәннең (нигездә, астрономия) җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәве белән аңлатыла.

Әсәрдә Аллаһның бу дөньяны алты көндә яратканлыгы турында әйтелә. Коръәндә дә бу шулай, ләкин кайсы мәхлукның нинди көндә барлыкка килүе һәм хронологиясе бирелми. «Сираҗел-колүб»тә исә болар бөтенесе билгеле: якшәмбе көн – җиде кат күк һәм җиде кат җир; дүшәмбе көн – кояш, ай, йол-

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В.Нирша. В двух томах. Т. 2. – М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль Ибрагим», 2002. – С. 92–93.

[2] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 5.

дызлар; сишәмбе көн – күк фәрештәләре, хайваннар, кошкортлар; чәршәмбе көн – диңгезләр, сулар; пәнҗешәмбе көн – оҗмах, тәмуг; җомга көндә Адәм, Хәвва, пәриләр, бөтен фәрештәләр барлыкка китерелә. Шимбә көн инде бөтен галәм яратылып тәмамланган була[1].

Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә якшәмбе – күкләр, дүшәмбе – ай, йолдызлар, сишәмбе – җанлы мәхлуклар, чәршәмбе – дәрья, балыклар, агачлар, үләннәр, пәнҗешәмбе – оҗмах, тәмуг, рәхмәт һәм газап фәрештәләре, җомга – Адәм, мәхлукларның бар ителүләре сурәтләнә[2].

Бу ике әсәрдә кайсы көннәрдә нәрсәләр яратылганы бертөрле тасвирлана дип әйтергә мөмкин.

Әсәрдә, «Кыйсасел-әнбия»дәгечә, Аллаһы Тәгалә бөтен нәрсәләрне күз ачып йомганчы да бар итә ала иде, диелә. Ләкин ни өчен алты көндә бар иткән соң? Автор моңа үзе җавап бирә: Аллаһы Тәгалә моның белән Үзенең сабырлыгын, ашыкмавын күрсәткән һәм һәр эштә сабыр булырга кушкан[3]. Аднаш хафиз Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйткән сүзләрен китерә: «Ашыгу – шайтаннан, сабыр итү – Рахманнан (Аллаһтан)»[4]. Автор, ашыгу хакимнәр, адәмнәр эше түгел, ә шайтаннар эше, ди[5]. Бу – кешеләргә эшләрендә беркайчан да ашыгып эшләмәскә кисәтү булып тора, чөнки бөтен ялгышлыклар ашыгудан килә.

Беренче кат күк яшел зөбәрҗәттән яратылган. Аның исеме «Бәркыя». Икенче кат күк «Әркалүн», нурдан яратылган. Өченче кат күк «Кадим» кызыл якуттан яратылган. Дүртенче

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 3.

[2] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003.– Б. 7-8.

[3] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 4.

[4] Шунда ук. Б. 4.

[5] Шунда ук. Б. 4.

кат «Сәгун» яшел зөбәрҗәттән бар ителгән. Бишенче кат күк яшел якуттан, ни сәбәпледер, аның исеме әйтелми. Алтынчы каты «Бәрфика» сары якуттан яратылган. Җиденче кат күк «Гарбия» саф энҗедән бар ителгән. Бер каттан икенче катка хәтле 500 еллык юл. Һәрбер катта фәрештәләр намаз укып, тәсбих әйтеп торалар. Һәр кат фәрештәләренең олы фәрештәсе бар, аларның исемнәре дә китерелә[1].

Нигездә, яратылыш турында сөйләгәндә, Аднаш хафиз параллель рәвештә Мөхәммәд өммәтенең, ислам диненең өстенлеген күрсәтеп бара. Күкләр турында сөйләгәндә дә, җиденче кат күк фәрештәләре Мөхәммәд өммәте өчен зар елап, алар өчен Аллаһтан ярлыкау сорап торганнарын искәртә.

«Кыйсасел-әнбия»дә бераз аерма бар: күкнең беренче каты яшел зөбәрҗәттән, анда фәрештәләр адәм сурәтендә; икенче каты энҗедән, андагы фәрештәләр ат сурәтендә; өченче каты кызыл якуттан, фәрештәләр бүре сурәтендә; дүртенче каты көмештән, фәрештәләре бөркет сурәтендә; бишенче каты кызыл алтыннан, фәрештәләре хур кызлары сурәтендә; алтынчы каты сары якуттан, фәрештәләре вилдән, ягъни ир балалар сурәтендә; җиденче каты нурдан яратылган, фәрештәләре адәм сурәтендә[2].

Коръәндә күкләрнең исемнәре турында мәгълүмат бирелми. Анда фәкать күкләрдә фәрештәләрнең гыйбадәт кылып торганнары әйтелә. Нәрсәдән бар ителүләре дә әйтелми. Ләкин, күргәнебезчә, әдипләр, күкләрнең кыйммәтен һәм бөеклеген күрсәтер өчен, аларны төрле кыйммәтле ташлардан бар ителүләрен сурәтлиләр.

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 6–7.

[2] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 8.

Җир шулай ук җиде каттан тора, аралары да 500 еллык юл. Беренче катта кешеләр тора. Икенче кат – җилләр урыны. Өченче катта йөзләре кешенеке, авызлары этнеке, аяклары үгезнеке, төкләре куйныкы булган затлар яши. Алар һәрвакыт Аллаһка буйсынуда, ләкин саваплары булмас. Дүртенче катта күкерт ташы, ул тәмугта газаплар өчен яратылган. Бишенче кат җирдә тәмугның чаяннары яши. Алтынчы катта исә тәмуг еланнары яши. Җиденче кат җирдә Иблис тәхетендә утыра[1]. Тәмуг чаяннары, еланнары бик куркыныч итеп, гипербола кулланылып сурәтләнәләр һәм аларның, иң беренче чиратта, кяферләрне газаплар өчен яратылганлыклары искәртелә[2]. Һәр кат җирнең исемнәре дә әйтелә: беренче кат – «Әдимә», икенче кат – «Бәтыйнҗә», өченче кат – «Шәкъбәл», дүртенче кат – «Бәтха», бишенче кат – «Мөсәфлә», алтынчы кат – «Мөсәбкә», җиденче кат бер җирдә – «Сиҗҗин»; икенче җирдә – «Сәри»[3]. Автор җиденче катның исемен, ни өчендер, ике төрле итеп бирә.

«Кыйсасел-әнбия»дә җирнең беренче катының исеме «Рукмә». Икенче каты «Җәлдә» дип атала, аның эчендә койрыклары сөңгегә охшаган тәмуг чаяннары бар. Өченче катның исеме «Гарка», аның эчендә Каф тавы шикелле биек тәмуг еланнары бар. Дүртенче кат – «Харбә», анда тәмуг газаплары бар. Бишенче кат – «Мәслә», аның эче тулы тәмуг ташлары. Алтынчы кат – «Сиҗҗин», аның эченә тәмугта булучыларның җаннары бикләнгән. Җиденче кат – «Гаҗибә», анда Иблис торыр һәм һәр елда бер мәртәбә чыгып керер[4].

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 8–11.

[2] Шунда ук. Б. 10.

[3] Шунда ук. Б. 11.

[4] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 8–9.

Коръәндә җирнең җиде кат икәнлеге «Талак» сүрәсенең 12 нче аятендә әйтелә: «Ул – Аллаһ күкне җиде кат итеп яратты һәм җирне шулай ук җиде кат итеп халык кылды».

Күргәнебезчә, «Сираҗел-колүб» әсәре белән «Кыйсасел-әнбия» әсәре арасында бераз охшаш яклар булса да, аермалары да шактый.

Коръәндә һәм хәдисләрдә күкләрнең һәм җирләрнең исемнәре һәм анда кемнәр яшәүләре төгәл әйтелми. Әйтелсә дә, ул хәдисләр бик зәгыйфь яки ялган («мәүдуг») булып саналалар. Шуңа күрә, традицион ислам динендә төгәл мәгълүматлар булмау сәбәпле, әйткәнебезчә, һәр автор үзенчә сурәтли. Бәлки, суфиларның боларга кагылышлы үзләре уйлап чыгарган төгәл мәгълүматлары, төрле риваятьләре бардыр, ләкин алар безгә билгеле түгел. Әгәр Коръән яки мәшһүр хәдис җыентыклары нәрсәгә дә булса төгәл мәгълүмат бирә икән, ул турыда бернинди ихтиляф, фикер төрлелеге чыкмый. Мәсәлән, фәрештәләр, пәйгамбәрләр исемнәрен алыйк. Бер язучы яки шагыйрь дә Җәбраил фәрештәне башка исем белән атамый. Мөнкир белән Нәкир фәрештәне дә беркем үз әсәрендә башка исем белән бирми. Чөнки алар диндә төгәл билгеләнгән. Күкләр, җирләр исеме Коръән, сахих (дөрес) хәдисләр белән төгәл билгеләнмәгәнгә күрә, төрле фикер каршылыкларына очрыйбыз.

«Сираҗел-колүб» әсәрендә оҗмах һәм тәмуг турында да бик күп мәгълүматлар бирелә. Оҗмах җиде кат күк өстендә урнашкан. Һәр оҗмахның исеме бар: берсе – «Дарес-сәлам» (кызыл якуттан яратылган), икенчесе –«Дарел-әхыйра» (энҗедән яратылган), өченчесе – «Дарел-хулүд» (зөбәрҗәттән яратылган), дүртенчесе – «Дарел-карар» (саф зөбәрҗәттән яратылган), бишенчесе – «Җәннәте гаден» (мәрҗәннән яратылган), алтынчысы – «Җәннәтел-мәэва» (нурдан яратылган), җиденчесе – «Фирдәвес» (нурдан, гәүһәрдән яратыл-

ган)[1]. Ислам дине өйрәтүе буенча, оҗмахлар сигез дип карала, әмма әсәрдә җидесе генә телгә алына.

«Мәликә китабы»нда сигез җәннәтнең дә исемнәре китерелә: беренчесе – «Дарес-сәлам», икенчесе – «Дарел-карар», өченчесе – «Дарен-нәһәр», дүртенчесе – «Җәннәтен-нәгыйм», бишенчесе – «Җәннәтел-фирдәвес», алтынчысы – «Җәннәтел-гаден», сигезенче – «Җәннәтел-гали»[2].

Имам Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә әл-Казагый (1043 елда вафат булган) үлем һәм кыяматкә кагылышлы «Хәзәинел-әфкяр» әсәрендә җәннәтнең исемнәрен китерә: беренчесе – «Дарел-җәнән», икенчесе – «Дарес-сәлам», өченчесе – «Җәннәтел-мәэва», дүртенчесе – «Җәннәтен-нәгыйм», бишенчесе – «Җәннәтел-хулүд», алтынчысы – «Җәннәтел-фирдәвес», җиденчесе – «Җәннәте гаден», сигезенче – «Дарел-карар»[3].

Коръәндә оҗмах төрле исемнәр белән бирелә: «Җәннәте гаден», «Җәннәте нәгыйм», «Җәннәтел-фирдәвес», «Дарес-сәлам», «Дарел-хулүд» һ.б. исемнәр белән әйтелә, әмма аларның дәрәҗәләре буенча хронологиясе бирелми. Шуңа күрә һәр әдип үзенең уйлавы, күзаллавы буенча оҗмахның дәрәҗәләрен билгели. Кайсы исем астында китерелгән оҗмах, аның фикеренчә, кыйммәтрәк, олуграк – шул оҗмахны ул иң югары дәрәҗәдәге оҗмах дип билгели. Шул рәвешле оҗмахның дәрәҗәләре төзелә.

Әсәрдә тәмугның сурәтләнүен дә карыйк. Аны Аллаһ газаптан бар иткән, җиде кат җир астына урнаштырган һәм алар җиде. Берберсенең арасы җитмеш мең еллык, бер

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 11.

[2] Мәликә китабы / Китапны нәшер итү өчен әзерләүче Ш.Х. Зәбиров. Казан: Идел-пресс, 2002. Б. 16.

[3] Әл-Казагый Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 74.

тәмугның газабы икенчесеннән катырак. Беренчесенең исеме – «Җәһәннәм», икенчесе – «Хотамә», өченчесе – «Һәвия», дүртенчесе – «Вәйл», бишенчесе – «Сәгыйрь», алтынчысы – «Сәкар», җиденчесе – «Җәхим». Газабы азрак булган «Җәһәннәм» исемлесенең җитмеш мең капкасы бар, һәрбер капка эчендә уттан җитмеш мең бүлек бар, һәрбер бүлек эчендә уттан җитмеш мең сарай бар, һәрбер сарай эчендә уттан җитмеш мең бүлмә бар, һәрбер бүлмә эчендә уттан җитмеш мең газап бар[1]. Монда автор шундый иҗади ысуллар белән, гиперболалар кулланып, тәмугны оста сурәтли.

Хөсам Кятиб та «Җөмҗөмә солтан» әсәрендә тәмуг турында бик күп яза. Ул тәмугны җидегә бүлә. Беренчесе – «Һәвия» исемлесе (иң каты газаплардан торганы) монафикълар өчен, икенчесе – «Сәкар» исемлесе яһүдиләр өчен, өченчесе – «Хотамә» исемлесе насранилар (христианнар) өчен, дүртенчесе – «Ләза» исемлесе мәҗүсиләр өчен, бишенчесе – «Сәгыйрь» исемлесе ялган сөйләүчеләр өчен, алтынчысы – «Җәхим» исемлесе гөнаһлы бәндәләр өчен, җиденчесе – «Җәһәннәм» махсус Мөхәммәд өммәте өчендер. Бу җиденче тәмуг Мөхәммәд өммәте өчен булганга, аның газабы һәм уты башкаларныкыннан азрак, ди автор[2]. Бу – Мөхәммәд өммәтенең башка өммәтләрдән өстенлеген күрсәтә.

«Мәликә китабы»нда да тәмугның исемнәре китерелә. Беренчесе – «Һәвия», икенчесе – «Хотамә», өченчесе – «Сәкар», дүртенчесе – «Сәгыйрь», бишенчесе – «Ләза», алтынчысы – «Җәхим», җиденчесе – «Җәһәннәм»[3].

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 12.

[2] Кятиб Х. Җөмҗөмә солтан; текстны басмага әзерләүче Р.Ф. Исламов. Казан: Иман, 2000. Б. 31–32.

[3] Мәликә китабы / Китапны нәшер итү өчен әзерләүче Ш.Х. Зәбиров. Казан: Идел-пресс, 2002. Б. 17.

Әл-Казагый үзенең «Хәзәинел әфкяр» әсәрендә тәмугның исемнәрен һәм анда кемнәр кергәнлеген әйтә: беренчесенә – «Һәвия»гә монафикълар, маидә (ашъяулык) иңгәннән соң кяфер булучылар, Фиргавенгә ияргән кешеләр керер; икенчесенә – «Җәһим»гә Аллаһка тиңдәшлек кылганнар керер; өченчесенә – «Сәкар»га йолдызга гыйбадәт кылучылар керер; дүртенчесенә – «Ләза»га Иблис, аңа иярүчеләр, мәҗүсиләр керер; бишенчесенә – «Хотамә»гә яһүдиләр керер; алтынчысына – «Сәгыйрь»гә насаралар керер; җиденчесенең исеме әйтелми, анда гөнаһлы мөселманнар керер, диелгән[1].

Фәкыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди да үзенең «Кыямәт, тәмуг һәм җәннәт рәвеше бәяны» әсәрендә, нәкъ әл-Казагый күрсәткәнчә, тәмугның исемнәрен һәм кемнәрнең кайсына керәчәген бәян итә[2].

Коръәндә тәмуг төрле исемнәр белән бирелә: «Һәвия», «Җәһим», «Сәкар», «Хотамә», «Ләза», «Сәгыйрь», «Җәһәннәм». Әмма, оҗмах кебек үк, аның дәрәҗәләре буенча тәртибе китерелми. Шуңа күрә һәр әдип үзенең күзаллавы буенча дәрәҗәләренә карап тәртибен төзи.

«Сиражел-колүб» әсәрендә оҗмах эчендәге Кәүсәр исемле бер күл һәм Туба агачы турында мәгълүмат бирелә. Кәүсәрне әдип бик күп чагыштырулар кулланып тасвирлый. Мәсәлән, аның киңлеге өч йөз агач җире хәтле, озынлыгын бер Аллаһ кына белер, суы кардан аграк, майдан йомшаграк, балдан татлырак, ташлары – энҗе-мәрҗәннән, якуттан, зөбәрҗәттән, балчыгы – зәгъфраннан һ.б. Кем дә кем бу суны бер йотым гына булса да эчсә, бүтән һич сусаулыкны белмәс, ди автор. Бу Кәүсәр суын, иң беренче чиратта, дөньяда суга, ризыкка

---

[1] Әл-Казагый Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 67–68.

[2] Сәмәрканди Ә. Кыямәт, тәмуг һәм җәннәт рәвеше бәяны. Казан: Матбугат йорты, 2005. Б. 36–37.

мохтаҗ булган дәрвишләр һәм мескеннәр татып караячак икән. Кем исә аларга карата шәфкатьсез һәм саран булса, алар бу суны эчә алмаслар, ди автор[1].

«Сахих әл-Бохари» җыентыгындагы 1749 нчы хәдистә китерелә: Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән: «Минем күлемнең (Кәүсәрнең) бер ярыннан икенче ярына чыгар өчен бер ай кирәк, аның суы сөттән аграк, аның исе мускус исеннән дә хуш ислерәк, аның ярындагы чүлмәкләре һавадагы йолдызларга тиң, кем дә кем аның суын эчсә, беркайчан да сусамас»[2].

Шулай ук бу җыентыктагы 1752 нче хәдистә дә пәйгамбәр галәйһиссәламнең сүзләре китерелә: «Бервакыт мин төшемдә үземнең яныма бер төркем кешеләрне алып килгәннәрен күрдем (Кәүсәр янына). Мин аларны таныгач, безнең арага бер фәрештә чыкты (ягъни аларга су эчәргә ирек бирмәде) һәм әйтте: «Ашыгыгыз!» – диде. Мин: «Кая?» – дип сорадым. Ул: «Утка, валлаһи», – диде. Мин сорадым: «Нәрсә өчен?». Ул әйтте: «Син үлгәннән соң алар синең динеңнән тайпылдылар (динне үзгәрттеләр, боздылар)». Аларның бик азлары гына котыла алганнарын күрдем»[3].

Шулай ук Кәүсәргә кагылышлы 1432, 1433, 1750, 1751 нче хәдисләрне дә атап үтәргә мөмкин.

Коръәндә махсус «Кәүсәр» сүрәсе бар. Аның беренче аятендә әйтелә: «Чынлыкта Без (Аллаһы Тәгалә) сине Кәүсәр белән нигъмәтләдек».

Кәүсәр турында Коръәндә дә, күп хәдисләрдә дә килә. «Сираҗел-колүб» әсәрендәге Кәүсәрнең тасвирламасы, нигездә, хәдисләр белән туры килә. Әмма «Сахих әл-Бохари» җыен-

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 14–15.

[2] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль Ибрагим», 2002. С. 377.

[3] Шунда ук. С. 377–378.

тыгының шәрхендә дингә төрле яңалыклар, бидгатьләр кертеп үзгәртүчеләрнең Кәүсәр суын эчә алмаулары әйтелә һәм тәнкыйтьләнәләр. Әсәрдә исә фәкыйрьләргә, мескеннәргә карата шәфкатьсез, саран кешеләр Кәүсәр суын эчә алмаслар, дип китерелә. Әдипнең бу хәдисне шушы рәвешле бераз үзгәртүе суфичылык белән бәйле булса кирәк. Традицион ислам вәкилләре фикеренчә, суфилар динне үзгәрткәннәр, яңалыклар, бидгатьләр керткәннәр. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхретдин дәрвишләрне, бик күп яңалыклар кертеп, саф ислам динен бозуда гаепли: «Дәрвишләрдән гангана (фәлән кеше әйтте дип сөйләү) булып килгән вә тәкияләрдән (дәрвишләр тора торган урын) мәнакыйб (мактау сүзе) китаплары сөйли торган голсу (ашып китү) вә ифратлар, ифтира (яла ябу) вә бөһтанлар (гадәтне бозучы) хәбәрләрнең иге вә чиге юк. Буларны укучылар бөтен күңелләре белән шулкадәр тасарраф (өләшү) вә кодрәт иясе булган әүлияләргә юнәлергә, Аллаһы Тәгаләне бөтенләй күңелләрендән чыгарып онытырга вә аңа вөҗүд бирмәскә мәҗбүр булачаклардыр. Хәлбуки, яхшы тикшерелсә, мондый хәбәрләрнең инсафлары вә динләре ким булган адәмләр тарафындан хосусый вә гомуми мәнфәгатьләр вә күбесе дә сәяси максатлар юлында эшләнеп чыгарылганлыклары мәгълүм булачакдыр. Мондый асылсыз хикәятләр, җөзаф (үлчәүсез сөйләү) вә ифратлар Ислам дөньясында Төркестан саранчасы кадәр күп тaралдылар вә Рәсүлулла китергән саф вә гали Ислам нигъмәте өстенә чабата, таракан булып төштеләр. Булар сәбәпле Ислам диненең сафасы вә зиннәте китте, мөлхидләр (динсезләр) вә зиндыйклар (денсезләр) кулларына Ислам динендән көләр вә гакылсызлык (ахмаклык) белән иттиһам (өстенә ялган сөйләнү) кылыр өчен сөрмәяләр хәзерләнде»[1].

---

[1] Фәхреддин Р. Җәвамигуль кәлим шәрхе: гарәби рус хоруфатында беренче басма. Казан: Иман, 1995. 287 б.

Шулай ук галим суфиларның бик күп хәдисләрне бозулары, үзгәртүләре, уйлап чыгарулары турында яза[1].

«Сахих әл-Бохари» җыентыгындагы хәдис суфиларның, дәрвишләрнең үзләренә каршы бер дәлил булыр иде, шуңа күрә алар, безнең уйлавыбызча, аны бераз үзгәртәләр. Суфиларның әсәрләрендә, гадәттә, байлар, саран кешеләр тәнкыйтьләнгәнгә, «Сираҗел-колүб» әсәрендә дә дәрвишләргә шәфкатьсез, саран байлар Кәүсәр суын эчә алмаячак, ягъни Аллаһ рәхмәтенә ирешә алмаячак, дигән фикер әйтелә.

Әсәрдә Туба агачының шулай ук җәннәттә урнашканлыгы әйтелә. Аны да автор гипербола, чагыштырулар куллану юлы белән сәнгатьчә тасвирлый: ул агач алтыннан, озынлыгы шулкадәр ки, әгәр бер кош гомере буе очса да, ул агачның бер ботагыннан икенчесенә кадәр җитә алмас һ.б.[2]

Әл-Казагый да бу агач турында әйтеп үтә. Туба агачы җәннәт агачларының иң зурысы һәм аның күләгәсе астына берничә мең кеше ышыклана ала, ди[3].

Әбү Ләйс Сәмәрканди атка атланган кеше ул агачның күләгәсендә йөз ел йөрсә дә, йөреп бетерә алмаганлыгын искәртә[4].

Коръәндә дә бу агач турында аять бар: «Иман китереп вә изге гамәлләр кылган кешеләргә, шиксез, шатлык, хушлык вә Туба агачы астында күләгәләнү булыр вә күркәм урыннар булыр». («Рәгыд» («Күк күкрәү») сүрәсе, 29 нчы аять).

Сәһел бине Сәгъд хәдис китерә: «Пәйгамбәр саллалаһү галәйһи вә сәлләм әйткән: «Җәннәттә бер агач бар, атка ат-

---

[1] Фәхреддин Р. Көтебе ситтә вә мөәллифләре. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1913. 10 б.

[2] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 15–16.

[3] Әл-Казагый Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 74–75.

[4] Сәмәрканди Ә. Кыямәт, тәмуг һәм җәннәт рәвеше бәяны. Казан: Матбугат йорты, 2005. Б. 47.

ланган кеше аның күләгәсендә йөз ел чапса да, барыбер күләгәсеннән чыгып бетә алмас»[1].

Шулай ук Әбү Сәгыйт Әл-Худри да пәйгамбәрдән шуңа охшаш хәдис китерә[2].

«Сиражел-колүб» Коръән, хәдисләр һәм төрле язучылар әсәрләре белән туры килә. Туба агачының зурлыгы төрле ысуллар белән тасвирланса да, нигездә, бер үк мәгънәдә бирелә.

Белгәнебезчә, ислам дине өйрәтүенчә, Аллаһы Тәгаләнең гареше һәм көрсие бар. Алар турында да автор тәфсилләп сөйләп бирә. Аларны Аллаһ нурдан бар иткән. Көрсинең зурлыгы җиде кат җир һәм җиде кат күккә карата бер олы ләгән белән бер кечкенә чынаяк бәрабәрендәдер, ягъни ләгән – көрси, чынаяк – җиде кат җир белән җиде кат күк. Гарешнең зурлыгы исә шулкадәр ки, көрсине – җиде кат җир, җиде кат күкнең бөтенесен бергә бер тары орлыгы, дип күз алдына китерсәк, гареш бу дөнья зурлыгы кебек, ягъни бу тары орлыгыннан никадәр зур, гареш тә көрсидән – җиде кат җир, җиде кат күктән – шулкадәр зуррактыр. Гарешне дүрт зур фәрештә муеннарында тотып тора[3].

Әсәрдә Бәйтел-Мәгъмүр, Каф тавы турында да мәгълүмат бирелә: Бәйтел-Мәгъмүр нәкъ Кәгъбә өстендә күктә урнашкан бер өйдер. Анда фәрештәләр даими рәвештә гыйбадәт кылып торалар[4]. Каф тавы бу җиһанның тирәсенә чолгап алынгандыр. Ул яшел зөбәрҗәттән булганга, аның яктылыгы күккә төшә. Шуңа күрә күкләр яшел төстә икән. Автор Коръәннән дәлил буларак бер аять китерә: «Каф. Вәл-коръәнил-

---

[1] Сахих Муслим. В четырёх томах. Т. 4. Казань: Иман, 2004. С. 802.

[2] Шунда ук. С. 802.

[3] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 24.

[4] Шунда ук. Б. 34.

мәҗид»[1]. Ләкин Коръәнне яхшы белгән кеше, бу аятьтә Каф тавы турында сүз бармый, ул фәкать гарәп телендәге «каф» хәрефе икәнен белә. Коръәндә хәрефләр белән башланган аятьләр күп. Мәсәлән: «Йә син», «Әлиф ләм мим» һ.б. Габдрахман бине Нәсир Сәгади исемле бөек Коръән белгече мондый хәрефләрне шәрехләүдән тыелырга киңәш итә һәм аларны ничек тә булса аңлатырга тырышучыларның бернинди дәлилләре булмауларын әйтә. Аның фикеренчә, бу хәрефләрнең хикмәте безгә ачылмаган[2]. Алда китерелгән аятьне Каф тавы белән бәйләү Аднаш хафизның Коръәнне үзенчә аңлатырга тырышуын күрсәтә.

Шулай ук әсәрдә күк эчендә бер кош яратылганлыгы сөйләнелә. Ул кош әтәчкә охшаган, аның башы гареш өстендә, аяклары җиде кат җир астында, башы кызыл якуттан, күзләре яшел зөбәрҗәттән, тәне гамбәрдән. Аның дүрт йөз мең канаты бар, бер канатында дүрт йөз мең йоны бар, барча йоннары зәгъфраннан икән[3]. Бу кош турында Коръәндә дә, хәдисләрдә дә бернинди мәгълүмат табылмады. Бәлки, бу суфиларның риваятьләрендә чагылыш тапкандыр.

Шулай итеп, Аднаш хафизның галәмне, анда булган барча мәхлукатьне, җәннәт-җәһәннәмнең ни рәвешле кылынуларын бөтен нечкәлекләре белән сурәтләп язуы диннең бу яратылыш өлкәсен бик яхшы белгәнлеген раслый.

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 35–36.

[2] Саади А. Толкование Священного Корана; пер. с араб. Э. Кулиева. Т. 1. М.: Умма, 2006. С. 35–36.

[3] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 13.

## 1.2. Әсәрдә ахирәт тормышы гәүдәләнеше

Тематик яктан әсәрнең икенче өлеше ахирәт белән бәйле нәрсәләргә кагыла. Ахирәт (*гар.* теге дөнья) – Ислам дине өйрәтүенчә, кеше кыямәт көнендә кабат терелеп, мәңге яшәячәк. Бәндәләрнең әнә шул мәңгелек галәме – әдәбиятта «ахирәт» дип атала[1].

Кеше үлгәч, инде аның кыямәте җиткәнгә күрә, үлем фәрештәсеннән башларга кирәктер. Үлем фәрештәсенең исеме – Газраил. Ул дүртенче кат күктә утыра, аяклары күкнең бер почмагында, күзләрен Ләүхел-мәхфузга төбәп карап тора, диелә әсәрдә. Ләүхел-Мәхфуздан кемнең кайчан гомере беткәнен белеп, җаннарын ала. Мөэмин-мөселманның җанын йомшаклык белән ала һәм рәхмәт фәрештәләре аны оҗмахка куялар. Бәдбәхетнең җанын үзе алмыйча газап фәрештәләренә фәрман биреп, йөз мең газап белән алырлар[2].

Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә дә, Газраил фәрештә явыз кешенең җанын юеш йоннан тигәнәк алган кебек алыр, диелгән[3].

Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәрендә, Газраил фәрештәнең алты йөзе бар, диелгән. Өстәге йөзен ачып, ул күктә фәрештәләрнең җаннарын алыр, уң як йөзен ачып, мәшрикъ халкының җаннарын алыр, сул йөзен ачып, мәгъриб халкының җаннарын алыр, Мөхәммәд өммәтенең җаннарын махсус бер йөзен ачып алыр. Шулай ук Газраил фәрештәнең җаннарны ни рәвешле алуы кызыклы:

---

[1] Ислам. Белешмә сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 8 б.

[2] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 28–29.

[3] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы Казан: Дом печати, 2003. Б. 14.

«Андыйн әйди Җөмҗөмә Газраилә:
“Ким ничөндүр ул къәдәх чәнгял илә?”

“Куйдый күксим үзрә ул чәнгял учун,
Ичүрди ул къәдәхдин дәхи кучүн”.

Әйди: “Бир замандин үзүңә килгәйсән,
Къәвем – къәрдәшләриңни күргәйсән”.

Җөмҗөмә чүн ул къәдәхни кыйлдый нуш,
Чыкдый җаный, калдый куруг гәүдә буш.

(*Күксим үзрә* – күкрәгем өстенә. *Ичүрди ул къәдәхдин дәхи көчүн* – тагын көч кулланып (ирексезләп) ул савыттан эчерде. *Үзүңә килгәйсән* – терелерсең. *Кыйлдый нуш* – эчте.)»[1]

Имам Габдулла Мөхәммәд бине Сәламә әл-Казагыйның үлем һәм кыяматкә кагылышлы «Хәзәинел-әфкяр» дигән хезмәтендә әйтелгәнчә, үлем фәрештәсе дүртенче кат күктә тәхетендә утыра, аның җитмеш мең аягы, дүрт мең канаты бар, тәне тел һәм күз белән тулган. Аллаһы Тәгалә адәмнәрне, хайваннарны, кошларны күпме бар иткән, аларның һәрберсе өчен үлем фәрештәсенә йөз, ике йөз кул биргән. Шуңа күрә ул җаннарны бернинди мәшәкатьсез ала. Үлем фәрештәсенең дүрт йөзе бар: алдында, башында, артында, ике аягы астында. Пәйгамбәрләрнең, фәрештәләрнең җаннарын башындагы йөзе белән, мөэминнәрнең җаннарын алдындагы йөзе белән, кяферләрнең җаннарын артындагы йөзе белән, мөэмин җеннәрнең җаннарын аяк астындагы йөзе белән алыр икән[2].

Ислам динендә Газраил фәрештә – дүрт олы фәрештәләрнең берсе. Ул кешеләрнең җаннарын алу өчен җаваплы. Гадәттә, аны үлем фәрештәсе дип кенә атыйлар, чөнки Коръәндә

---

[1] Кятиб Х. Җөмҗөмә солтан; текстны басмага әзерләүче Р.Ф. Исламов. Казан: Иман, 2000. Б. 27.

[2] Әл-Казагый, Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 13–14.

һәм хәдисләрдә ул «Мәләкел-мәүт» (үлем фәрештәсе) дип әйтелә, Газраил дигән исем телгә алынмый. Газраил исеме мөселманнарга яһүдиләрдән кергән. Газраил фәрештәнең җаннарны ни рәвешле алуы Коръән һәм хәдисләрдә төгәл әйтелми, ә гомуми сүзләр белән генә сөйләнелә, шуңа күрә язучыларга бу өлкәдә киңрәк иҗат итүгә юл ачылган һәм алар, белгәнебезчә, үлем фәрештәсен, аның җаннарны ни рәвешле алуын төрлечә сурәтләгәннәр.

Мөнкир белән Нәкир исемле фәрештәләр дә «Сираҗел-колүб» әсәрендә киң яктыртылалар. Алар кабердә кешеләрдән: «Раббың кем?», «Динең нинди?», «Пәйгамбәрең кем?» – дип, сорау алалар. Әгәр кешене гүргә куйсалар, алар кулларына тәмугның утлы чукмарларын алып, күзләре яшьләнеп, авызларыннан – ут, борыннарыннан төтен чыгып, җирне ертып, болыт кебек күкрәп, яшен кебек яшьнәп, куркыныч кыяфәттә килерләр һәм сорауларын бирерләр. Әгәр кеше: «Раббым – Аллаһ, динем – ислам, пәйгамбәрем – Мөхәммәд галәйһиссәлам», – дип җавап бирсә, ул котылыр. Әгәр җавап бирмәсә, аны төрле газаплар белән газапларлар[1].

Хөсам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» әсәрендә дә аларның кабердә сорау алырга килүләре сурәтләнә:

«Китди анлар. Килди ики гүр йара,
Ики сурәт: бири күк, бири кара.

Ул икиниң кулинда утдыйн гъәмуд
Ким, ани күрмиш иди Гад-у-Сәмуд.

Күрдүм ирсә титрәмәк тутдый мәни,
Әйдим: “И Җөмҗөмә, нә кыйлдуң? Каный?”

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 29–30.

Килиб улдәм мәни мүхкәм тутдыйлар,
Сурдилар, һәйбәт илә куркутдыйлар.

“Ким турур Тәңриң – тәйү – әйт, мәҗүси!
Йукса утлуг гъәмуд илә ургуси!”

Сүзләмәдим ирсә, какиб турдыйлар,
Һәрбири бир гүрзи бирлә урдыйлар.

(*Килди ики* – ягъни Мөнкир һәм Нәкир. *Гамуд* – күсәк. *Гад-у-Сәмуд* – гөнаһлары өчен Аллаһ тарафыннан юк ителгән халыклар. *Титрәмәк тутдый* –калтырый башладым. *Мүхкәм* – нык. *Һәйбәт илә* – биредә: дәһшәтлек белән. *Тәйү* – дия. *Какыб* – сугып. *Гүрзи* – күсәк.)»[1]

Әл-Казагыйның «Хәзәинел-әфкяр» әсәрендә дә Мөнкир белән Нәкиргә аерым бер баб багышлана. Анда алар нәкъ «Сиражел-колүб» әсәрендәге кебек сурәтләнәләр. Мөнкир белән Нәкир мөэмин бәндә янына кергәч, башы тарафыннан килмәкче булырлар – аларны шул бәндәнең намазы китермәс, аяклары яныннан килерләр – бәндәнең җәмәгать намазларына йөрүе китермәс, уң ягыннан килерләр – сәдакалары китермәс, сул ягыннан килерләр – уразасы китермәс. Соңыннан мөэмин бәндә уянып, аларның сорауларына җавап бирер. Аллаһы Тәгалә бу бәндәсе өчен сөенер[2].

Мөнкир белән Нәкир бик күп хәдисләрдә дә килә. Аларны тасвирлап тормыйбыз. Бу әсәрләрдә килгән Мөнкир һәм Нәкирне сурәтләү төрле хәдисләрдән алынып язылган. Нигездә, алар бер-берсенә охшаш һәм аермалар әллә ни күренми.

Аднаш хафиз кыямәт көнен һәм аның дәһшәтләрен тәфсилләп сурәтли. Кыямәт көне Исрафил пәйгамбәрнең сурга

---

[1] Кятиб Х. Җөмҗөмә солтан; текстны басмага әзерләүче Р.Ф. Исламов. Казан: Иман, 2000. Б. 28–29.

[2] Әл-Казагый, Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 34–35.

өрүе белән башлана. Кайчан кешеләр фәсәд (бозыклык) белән мәшгуль булырлар – Аллаһы Тәгаләдән сурга өрергә фәрман килер. Исрафил өрүгә җиде кат күк һәм җиде кат җир халыклары һушсыз калыр, таулар йон, мамык кебек һавада очарлар, ай һәм кояш караңгыланыр. Исрафил пәйгамбәр тагын икенче тапкыр өрер – бөтен җан ияләре үләр, мәгәр сигез фәрештә калыр: Исрафил, Микаил, Җәбраил, Газраил һәм гарешне тотып торучы дүрт фәрештә. Соңыннан Газраил аларның һәм үзенең җанын алыр. Кырык елдан соң Аллаһы Тәгалә янә кырык ел яңгыр яудырыр һәм кешеләр үләннәр кебек үсеп чыгарлар. Фәрештәләрне терелтеп, Аллаһ Исрафилгә тагын өрергә кушар. Ул өргәч бөтен җаннар тәннәренә кереп бөтен кешеләр тергезелер[1].

Әл-Казагый «Хәзәинел-әфкяр» әсәрендә кыямәт көнен бик киң һәм күләмле итеп сурәтли. Нигездә, ул нәкъ Аднаш хафиз кебек яза. Фәкать кайбер моментларны тирәнрәк, кайбер детальләр өстәп тасвирлый. Мәсәлән, сурга тулырак характеристика бирә, Газраил фәрештәнең Иблиснең һәм үзенең җанын ни рәвешле алуын сурәтли[2].

Фәкыйһ Әбү Ләйс Сәмәрканди «Кыямәт, тәмуг һәм җәннәт рәвеше бәяны» әсәрендә, Коръән аятьләре һәм төрле хәдисләр китереп, кыямәт көненең тулы картинасын бирә. Ул сурның ике өрүе арасында кырык ел икәнен искәртә һәм сурның ничә тапкыр өрелүендә ике караш барлыгын әйтә: Кәгъб риваятендә ике мәртәбә, Әбү Хөрәйрә риваятьендә өч мәртәбә[3].

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 37–39.

[2] Әл-Казагый Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 42–45.

[3] Сәмәрканди Ә. Кыямәт, тәмуг һәм җәннәт рәвеше бәяны. Казан: Матбугат йорты, 2005. Б. 3–27.

Коръәндәге 75 нче сүрә «Кыямәт» сүрәсе дип атала. Коръән нигезендә, кешелек дөньясының иң ахыр көне – кыямәт (мәхшәр) көне. «Кыямәт» сүрәсендә бу көннең тасвирланышы да бик ачык бирелгән: «Һәркайчан кыямәтнең куркынычыннан күзләр тонып караңгыланса, ай тотылса һәм кояш илә ай бергә кушылсалар, кыямәт булыр. Ул көндә кеше әйтер: «Бу куркынычтан кайда качарга?». Бүген качып котыла торган урын юк. Бу көндә карарланачак урын фәкать Раббың хозурындадыр. Ул көндә кешегә хәбәр бирелер исән чагында кылган эшләреннән һәм үлгәндә калдырып киткән яхшы, яман эшләреннән» («Кыямәт» сүрәсе, 9–13 нче аятьләр).

Коръәндә кыямәт көненең тасвирланышы бик күп урыннарда бирелгән. Мәсәлән, «Бәкара» («Сыер»), «Йәсин», «Мүрсиләт» («Җибәрелмеш»), «Нәба» («Хәбәр»), «Тәквир» («Чорналу»), «Инфәтар» («Ярылмак»), «Мүтаффифин» («Киметүчеләр»), «Иншикак» («Ярылмак»), «Гашийә» («Каплаучы»), «Нәзигать» («Суыргучы»), «Зүлзиләт» («Җир селкенмәк»), «Карига» («Җәза көне») һ.б.

Сурның ни рәвешле өрелүе түбәндәгечә китерелә: «Ул кяферләр Аллаһтан һичнәрсә көтмиләр, мәгәр фәрештәнең һәлак итә торган бер тавышын көтәләр, ул тавыш аларны сатуалу эшләрендә кычкырышкан вакытларында аңсыздан тотар, ул тавыш Исрафил фәрештәнең әүвәлге сур өрүедер. Аларны ул тавыш тотканда васыятьләрен әйтергә һәм өй әһелләре янына кайтырга кадир булмаслар. Сурга икенче мәртәбә өрелгәч, каберләреннән чыгып ашыга-ашыга Раббыларына барырлар. Кяферләр каберләреннән кубарылып чыккач: "Безне йоклаган урыныбыздан кем кубарды?" – диярләр. Шуннан соң икърар кылып әйтерләр: "Бу көн Раббыбыз вәгъдә иткән көндер, вә пәйгамбәрләр дә безгә хак сүзләрне сөйләгәннәр", – дип. Фәкать сурның каты бер тавышы белән барча кемнәр Безнең хозурыбызга килеп җыелырлар. Бу көндә һичкемгә хаксыз зо-

лым итү булмас һәм һичкем кылган эшләре өчен җәза алмыйча да калмас» («Йәсин» сүрәсе, 49–54 нче аятьләр).

«Нәзигать» («Суыргучы») сүрәсендә дә кыямәт көн җитүен хәбәр итеп, Исрафил фәрештәнең сурга өрәчәге, беренче өрүендә бөтен тереклекнең аңсыз халәттә калуы, икенче мәртәбә өргәч, барлык мәетләрнең каберләреннән кубарылып Аллаһ хозурына җыелулары хакында хәбәр ителә.

Бу күренеш хәдисләрдә дә югарыда китерелгән әсәрләрдәге кебек тасвирлана, тик сурның ике өрүе арасында күпме вакыт үтәсе төгәл бирелми. Әбү Хөрәйрәдән килә: «Аллаһ рәсүле (саллаллаһү галәйһи вә сәлләм) әйткән: «Ике өрү арасында – кырык». Алар (сәхабәләр) сорадылар: «Әбү Хөрәйрә: «Кырык көнме?». Ул җавап бирде: «Мин алай уйламыйм!» Алар сорадылар: «Кырык елмы?». Ул әйтте: «Мин алай уйламыйм! Аннары Аллаһ күктән яңгыр җибәрер һәм кешеләр үлән кебек үсеп чыгарлар». Пәйгамбәр галәйһиссәлам янә әйтте: «Адәм баласының оча сөягеннән башка бөтен тәне чери. Шул сөяктән ул кабат терелер» («Сахих Мөслим»)[1].

Мизан үлчәве «Сираҗел-колүб» әсәрендә таразу дип бирелә. Мизан – теге дөньяда бәндәләрнең кылган гамәлләрен үлчи торган үлчәү.

Әдип таразуны Коръән аяте белән тасвирлый башлый: «Хисаб көнендә булачак савап илә гөнаһны үлчәү мизаны хак, берәүнең үлчәүдә савабы авыр килсә, алар газаптан котылып, өстенлек табучылар. Вә берәүнең үлчәүдә савабы аз килсә, андый кешеләр һәлак булучылар, гамәл кылмыйча аятьләребезгә золым иткәннәре өчен» («Әгъраф» («Пәрдә») сүрәсе, 8–9 нчы аятьләр).

---

[1] Сахих Муслим / Пер. И. Попова. В четырёх томах. Т. 4. Казань: Иман, 2004. С. 832–833.

Аның бер тәлинкәсе мәшрикъта, икенчесе мәгърибтә булыр. Гыйбадәтләрне бер тәлинкәгә, гөнаһларны икенче тәлинкәгә салып үлчәрләр икән. Әгәр гыйбадәтләре басса, фәрештәләр: «Фәлән углы фәлән бәхетле булды», – дип, әгәр гөнаһлары басса: «Фәлән углы фәлән бәхетсез булды», – дип кычкырырлар[1].

Әсәрдә бу көннең куркынычлыгы, дәһшәте бик тетрәндергеч итеп сурәтләнә. Ул көндә һәр кешенең үз кайгысы башыннан ашкан булыр, ата-ана – баласын, баласы ата-анасын белмәс. Кешеләрнең гамәл дәфтәрләре яхшы бәндәләргә уң яктан, явыз бәндәләргә сул яктан, артларыннан бирелер. Беренчеләре котылыр, икенчеләре тәмугка атылыр. Бер кешене китерерләр, үлчәүнең бер ягына мәшрикътан мәгърибкәчә булган явыз гамәлләре язылган кәгазьләрне салырлар, икенче ягына «Лә иләһә иллаллаһ, Мөхәммәдер-расүлуллаһ» дип язылган кәгазь салырлар. Шул бер кәгазь тегеләреннән авыррак килер һәм ул оҗмахка кертелер[2]. Димәк, моның белән автор бу кәлимәнең фазыйләтләрен күрсәтә һәм мөселман булган кешенең котылачагын искәртә.

Әл-Казагыйның «Хәзәинел-әфкяр» әсәрендә дә мизан нәкъ шул рәвешчә сурәтләнгән, әйтерсең лә Аднаш хафиз бу әсәрен аннан күчереп язган. Фәкать Әл-Казагый мизанның бер табагы гарешнең уң ягында (изгелекләр куела торган як), икенче табагы гарешнең сул ягында (гөнаһлар куела торган як) урнашканлыгын әйтә[3]. Бу охшашлык ике язучының да Габдулла бине Габбас риваятен китергәнлеге белән аңлатыла.

Коръәндә мизанга кагылышлы аятьләр дә күп:

«Берәүнең, ягъни мөселманның үлчәүдә гөнаһына караганда савабы авыррак, күбрәк булса, ул мөселман җәннәттә

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 18.

[2] Шунда ук. Б. 18–19.

[3] Әл-Казагый Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 63.

үзе разый булган рәхәт тормыштадыр. Вә бер мөселманның үлчәүдә савабына караганда гөнаһы авыр килсә, ягъни яхшылыгына караганда яманлыгы күбрәк булса. Аның анасы – мәрхәмәтсез булган, “Һавийә” исемле җәһәннәм аңа урын булыр» («Карига» сүрәсе, 8–9 нчы аятьләр).

Аднаш хафиз сират күперен дә бик җентекләп тасвирлый. Сират – тәмуг өстеннән чыга торган күпер. Сират тәмуг өстендә урнашкан. Ул кылдан нечкә, кылычтан үткен, озынлыгы өч мең ел. Фәрештәләр кяферләрне сират күпереннән тәмугка башлары белән йөзтүбән атарлар. Мөэминнәр, кылган изгелекләренә карап, төрлечә үтәрләр: берәүләр яшен тизлегендә, берәүләр күз йомып ачканчы, берәүләр җил кебек, берәүләр кош кебек, берәүләр йөгереп, берәүләр йөреп, берәүләр сөртенә-сөртенә кичәрләр. Күпме вакыт эчендә кичүләре дә гыйбадәтләренә, изгелекләренә карата булыр. Соңыннан сиратны үткән мөэминнәр Аллаһы Тәгаләгә догалар кыла-кыла җәннәткә таба барырлар. Аллаһ аларның догаларын кабул итеп, ахыр чиктә аларны үз рәхмәте белән оҗмахка кертер[1].

Әл-Казагый сират күперен һәм аны үтү процессын тагын өстәмә детальләр белән баета. Сиратның җиде басмасы бар, һәрбер басмасы өч мең еллык юл, мең ел югары менәсе, мең ел тигез барасы, мең ел түбән төшәсе. Күпердән чыкканда кешедән иман, намаз, ураза, зәкят, хаҗ, тәһарәт, госел, ата-ана һәм карендәшләр хаклары, кеше рәнҗетү турында соралыр. Әгәр бу эшләрдә берәр нинди хилафлык булса, аска таба төшеп китәр. Шулай ук кайбер изге гамәлләр кешегә чыгарга ярдәм итәр. Мәсәлән, галимнәр белән утыру, аларны сөю, аларны сөйгән кеше белән дус булу, мәчеткә йөрү[2].

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 20–23.

[2] Әл-Казагый Г. Хәзәинел-әфкяр. Казан: Матбага Кәримия, 1915. Б. 64–65.

Аңлашылганча, әл-Казагый сират күперен кичү процессын Аднаш хафизга караганда тулырак, баерак итеп бирә. Ләкин, барыбер, мәгънә ягыннан бер үк нәрсә китерелә.

«Сиражел-колүб» әсәрендә сур өрү, мизан, сират күпере тасвирланышы Коръән һәм хәдисләр белән туры килә. Шулай ук башка язучыларның әсәрләре дә, нигездә, бу әсәр белән туры килә. Бу гаҗәп түгел, чөнки бөтен язучылар кыямәт көненең тасвирланышын сурәтләгәндә Коръән һәм хәдисләрне бердәнбер чыганак итеп файдаланганнар. Әсәрләрнең бераз аермалары язучыларның Коръән һәм хәдисләрне ни дәрәҗәдә белүләренә һәм аңлауларына бәйле булган.

### 1.3. «Сиражел-колүб» әсәре язылган вакытта тарихи вазгыять: күтәрелгән проблемалар

1552 елның октябрь аенда Казан ханлыгы Мәскәү хөкүмәте тарафыннан яулап алына. Тарихтан белүебезчә, Казан ханлыгының мәнфәгатьләрен яклаучы ил табылмый. «XV–XVI гасырларда Төркиянең ифрат куәтле бер заманы булып, бу вакытта Төркия бөтен мөселман дәүләтләренең башы булып, аның солтаны да үзен хәлифә итеп игълан кылган заманасы иде. Шуның өчен Төркия азмы-күпме башка мөселман җирләренең хәлләрен тикшереп торадыр. Менә Россия Касим ханлыгын ясап, анда мәчетләр салырга рөхсәт итүе белән Төркия каршында мөселманнарга хилаф дәүләт түгел икәнлеген күрсәтәдер иде. Шуның аркасында Казан, Әстерхан илләрен теләсә нишләтә ала, Төркия аның өчен «мөселманнарга тиясең», – дип бәйләнә алачак түгел»[1]. Шулай итеп, хәтта Төркия дә татарларны якламый.

---

[1] Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда: Сайланма хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 141.

Шундый катлаулы чорда Казан халкын физик яктан буйсындыргач, аларны үз кулларыннан ычкындырмас өчен, татарларны рухи яктан да буйсындырырга кирәк була. Моңа фәкать чукындыру юлы белән генә ирешергә мөмкин дип саный Мәскәү хөкүмәте. Православие дине рус хөкүмәтендә зур урын тоткан һәм бөтен сәяси эшләр христиан дине йогынтысы белән алып барылган. Бу гаҗәп түгел, чөнки Европада да «тәре походлары» гадәти хәл булган.

«Религия занимала важное место в идеологии российского империализма, выступая зачастую как идеологическое обоснование захватнической политики русских царей. Далеко не случайной является оценка Иваном Грозным покорения Казанского ханства как победа православного христианства над «басурманством». Да и сам завоевательный поход русских войск Москвой был организован как крестовый. На покорённых землях христианская православная церковь становится господствующей, получает самые широкие полномочия на распространение Христовой веры среди мусульман и языческих народов, а Казань за короткий срок превращается в русский город, главный опорный пункт движения православия на Восток»[1].

А.Н. Григорьев бу турыда бик ачык яза: «Необходимо было найти средство подчинить идеологически свободолюбивые народы края (чуваш, мари, татар) или хотя бы часть этих народов с тем, чтобы ослабить их национальную и классовую силу. Таким средством была избрана русификаторская политика на основе христианизации.

Ещё в 1555 г., по инициативе Ивана IV, в Казани учреждается особая епархия во главе с архиепископом Гурием.

---

[1] Ислаев Ф.Г. Православные миссионеры в Поволжье. Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. С. 3.

Задачей этой епархии являлось крещение татар, чуваш, мари и других народностей края»[1].

Хәзер татар халкына нишләргә? Аднаш хафиз үзенең әсәрендә китерелгән хикәяләргә, риваятьләргә яшерен мәгънә салып, хәзер нәрсә эшләргә кирәк? нинди адымнар ясарга кирәк? ничек бу бәладән котылырга? ничек динне һәм милләтне саклап калырга? дигән сорауларга җавап бирергә тели. Әгәр дә Аднаш хафиз бу мәсьәләләрне турыдан-туры язып белдерсә, Мәскәү хөкүмәте аның бу язмаларын юк итәр иде һәм аларның халык арасында таралуына юл куймас иде. Ләкин тышкы яктан гадәти дини әсәр кебек кенә аңлашылганга, бу әсәр халык арасында тарала, чөнки рус чиркәве бу әсәрдә ниндидер тирән, яшерен мәгънә ятуын сизми.

Мәсгуд Гайнетдинов түбәндәгечә яза: «Народ переживал необычные, трагические дни. Жестокое военное поражение, завершившееся потерей независимости и оккупацией всей территории, распад традиционных, устоявшихся общественных связей, абсолютная беззащитность мирного населения перед военной силой завоевателей подавляли моральный дух трудящихся масс. Народ остро нуждался в мудром совете, руководстве. Таким советчиком своего народа и выступает автор книги «Сирадж ал-кулюб». Его советы мудры и доходчивы»[2].

Аднаш хафиз күтәреп чыккан проблемаларның иң зурысы – иман һәм көферлек проблемасы. Ул әсәренең бик күп җирләрендә иман мәсьәләсенә тукталып үтә. Һәр бүлектә диярлек иман, иманлы кеше мактала, ә имансызлык, кяфер кеше хурлана.

---

[1] Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей, как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии // Материалы по истории Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1948. С. 227–228.

[2] Гайнетдинов М.В. «Сирадж ал-кулюб» // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). Казань: ФЭН, 1999. С. 142–143.

Оҗмах турындагы бүлектә оҗмахка фәкать мөселманнар гына керәчәге турында искәртелә: «Кем «Лә иләһә иллаллаһ» кәлимәсен әйтсә, ул газап кылынмаячак», – дип оҗмахның һәр капкасында язылган, ди автор. Оҗмахта Мөхәммәд өммәте өчен туба агачы яратылган. Аллаһ аларны ахирәттә кунак итеп хөрмәтләр: хур кызлары бирер, төрле тәмле ризыклар ашатыр, шәрабләр эчертер һәм Үзенең йөзен күрү бәхетен насыйп итәр.

Кыямәт көнендә сират күперен үткәндә кяферләр үтә алмаслар һәм тәмугка төшеп китәрләр, ә мөселманнар аны исәнимин чыгарлар.

Газраил фәрештә кяферләрнең җаннарын йөз мең газап белән, мөселманнарныкын исә йомшаклык белән алыр.

Кабердә Мөнкир белән Нәкир сорау алганда мөселманнар аларның сорауларына дөрес җавап биреп котылырлар, ә кяферләр җавап бирә алмаслар һәм бик каты газап кылынырлар.

Мөселманнар өчен хәтта фәрештәләр дә дога кылып торырлар. Автор дәлил итеп Коръәннән аять китерә. Анда гарешне күтәреп торучы фәрештәләр һәм алар тирәсендәге башка фәрештәләр тәсбих әйтерләр һәм Аллаһы Тәгаләгә мөэминнәр өчен ярлыкау сорап, дога кылып торырлар, диелгән.

Күк эчендә бар ителгән кош та намаз укучы мөселманнар өчен тибрәнә һәм Аллаһы Тәгаләдән аларны ярлыкавын, гафу итүен сорый.

Бәйтел-Мәгъмүрдә фәрештәләр җомга көнне азан әйтеп, хотбә укып намаз кылсалар, үзләренең бөтен кылган гыйбадәтләренең савабын мөэмин-мөселманнар өчен багышларлар.

Кыямәт көнендә мизанда «Лә иләһә иллаллаһ» кәлимәсе язылган кәгазь мәшрикътан мәгърибкә хәтле булган гөнаһларны басачак.

Күкләрнең ишекләре бары тик мөэминнәр өчен генә ачылыр, кяферләр өчен алар беркайчан ачылмаслар. Аллаһы

Тәгалә кяферләргә һич рәхмәт кылмас, алар җәннәткә кермәс, киресенчә, мәңге тәмугта калырлар.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең шәригате башка пәйгамбәрләрнекенә караганда асатрак, изгерәк, яхшырак. Коръән башка изге китапларга караганда олуграк санала.

Аднаш хафиз әсәрендә иманның әһәмиятен күрсәтеп, аның бик күп фазыйләтләрен әсәр дәвамында санап бара. Укучы иманның әһәмиятен һәм фазыйләтләрен белгәч, әлбәттә, аны саклап калыр өчен тырышачак икәне көн кебек ачык.

Иманны саклау мәсьәләсен төп проблема итеп кую моңа кадәр татар әдәбиятында бик чагылмый. Аднаш хафиз, бу җәһәттән, беренчеләрдән булып саналырга мөмкин. XVI гасырның икенче яртысына кадәр татар әдәбиятында, гадәттә, әдәп-әхлак, Аллаһтан курку, гөнаһлардан саклану кебек проблемалар карала. Әдипләр кешенең уңай сыйфатларын мактау һәм тискәре сыйфатларын тәнкыйтьләү белән мәшгуль булалар. Мәсәлән, Мөхәммәдъярның бөтен иҗатын диярлек әдәп-әхлак, гаделлек проблемасы тәшкил итә. Аңа кадәр Мәхмүд Болгари «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә намаз, зәкят, рузә, хаҗ гыйбадәтләрен җиренә җиткереп үтәргә, ата-анага хезмәт итәргә, хәләл ризык кулланырга, яхшылыкка өндәргә, төнне уяулыкта булып гыйбадәттә уздырырга, сабырлык сыйфатын булдырырга чакыра. Хаксызга кан кою, зина, хәмер эчү, тәкәббәрлек, ялган, гайбәт сөйләү, дөнья сөю, рия (икейөзлелек), көнчелек, гафләт кебек тискәре сыйфатларны тәнкыйтьләп чыга.

Хөсам Кятиб «Җөмҗөмә солтан» әсәрендә тормышта яхшылык, игелек кенә кылырга, мал-мөлкәт җыймаска, кулында булганын фәкыйрь-мескеннәргә өләшеп, рәхим-шәфкать күрсәтергә һәм теге дөнья турындагы уйлар белән яшәргә куша. Дөрес, әсәрендә ул Мөхәммәд пәйгамбәрне зур дәрәҗәләргә күтәреп сурәтли:

«Ул, Йаратканныйң хәбиби, Мостафа
Ким, къәмуг җанлар табар андыйн сафа;

Ул нөбүвәт мәгъдәнининң гәүһәри,
Һәм кәрамәт, һәм вилайәт сәрвәри.

Ул ким ушбу унсәкиз миң гъәләмиң
Сәрвәридүр җүмлә гасый адәмиң.

Дүнйада һәм ахирәтдә шаһ ирүр,
Аныйң үчүн ким, Хәбибуллаһ ирүр.

(*Ул, Йаратканныйң хәбиби, Мостафа* – ул, Аллаһның дусты, Мостафа (Мөхәммәд с.г.в.). *Сафа* – ләззәтлек, рәхәтлек. *Нөбүвәт* – пәйгамбәрлек. *Кәрамәт* – хөрмәт, юмартлык. *Вилайәт* – өлкә. *Сәрвәри* – башлыгы. *Гасый* – гөнаһлы. *Хәбибуллаһ* – Мөхәммәд пәйгамбәрнең эпитеты)»[1].

Ләкин пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәламне мактау ислам әдәбиятында традиция буларак формалашкан. Бу «Нәһҗел-фәрадис», «Мөхәммәдия» әсәрләрендә дә чагыла. Фәкать Хөсам Кятиб әсәрендә Газраил фәрештәнең Мөхәммәд өммәтенең җаннарын махсус бер йөзен ачып алуын белдертә. Моның белән ул, Аднаш хафиз кебек, бераз Мөхәммәд өммәтенең өстенлеген күрсәтә, ләкин шуның белән генә чикләнеп кала.

Шулай итеп әдипләрнең берсе дә иман, аны саклау проблемасын төп проблема итеп күтәреп чыкмыйлар. Бу инде аңлашыла да, ул заманда халыкның иманына куркыныч янамый, чөнки илне дошманнар басып алулар булмый. Җәмгыятьтә, фәкать бозыклык, әдәпсезлек таралган була һәм шагыйрьләр, язучылар кешеләрнең үзара дустанә мөгамәләдә булуына ирешү, патшаларның халыкка карата мөнәсәбәтен яхшырту максатларын куялар. Мәхмүд әл-Болгариның

[1] Кятиб Х. Җөмҗөмә солтан; текстны басмага әзерләүче Р.Ф. Исламов. Казан: Иман, 2000. Б. 26.

«Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә бирелгән «Ибне Гыймран һәм казый» хикәясендә бер казый янына фәкыйрьләр ризык сорап килгәч, ул аларны куып җибәрә. Ибне Гыймран казыйны үгетләп караса да, ул бернәрсә дә бирми. Соңыннан ул бер яһүдигә мөрәҗәгать итә. Ул яһүди берсүзсез фәкыйрьләргә ярдәм итә. Берәү төш күрә: казый җәннәткә керә алмаган, аның урынына теге яһүди җәннәткә кергән[1]. Яһүдинең мөселманлык кабул иткәне бер җирдә дә әйтелми, ләкин ул шушы юмартлыгы өчен җәннәткә керә алган. Шагыйрь җәннәткә иман гына кертми, ә юмартлык кебек сыйфатлар да кертә икән, дигән фикер уздыра. Ләкин, Аднаш хафиз фикеренчә, кешеләр, әгәр дә имансыз булсалар, нинди генә яхшылыклар кылсалар да, җәннәткә керә алмыйлар.

Аднаш хафиз чорында, Казан ханлыгы яулап алынгач, иманга куркыныч яный башлый. Шуңа күрә автор бу мәсьәләгә бик нык игътибар итә. Аднаш хафиздан соң килгән башка әдипләр дә үзләренең әсәрләрендә шушы теманы төп тема итеп сурәтли башлыйлар, әдәп-әхлак темасы икенче урында кала.

Иманны саклап калу өчен әдип берничә юл күрсәтә. Беренчесе – иманны саклауда нык тору. Хәтта үлем белән янасалар да, гомереңә куркыныч янаса да, барыбер иманда нык торырга кирәк икәнлеген белдертә. Шуңа күрә үлем һәм чукынуның икесе арасыннан татар халкы үлемне сайларга тиеш икән. Әгәр дә халык чукынуны сайлый икән, аның милләт буларак юкка чыгачагын бик яхшы аңлый автор.

Аднаш хафиз шушы фикеренә инандыру өчен ике кыйсса яки риваять китерә. Беренчесе аның «Әсхәбел-үхдүд» турында кыйсса. Бу кыйссаның кыскача эчтәлеге түбәндәгечә:

---

[1] Әл-Болгари М. Нәһҗел-фәрадис; әсәрне басмага әзерләүче, кереш мәкалә авторы Ф. Нуриева. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 210.

Габдулла исемле бер егетне сихер гыйлемен өйрәнер өчен бер сихерчегә укытырга бирәләр. Ул һәр көн сихерче янына дәрескә йөри башлый. Бер көнне юлында бер заһидне очрата. Ул Инҗил китабын укып утыра иде. Габдулла аннан бу укыган китабын өйрәтүен үтенә. Заһид риза була. Габдулла көн саен сихерчегә барганда шул заһид янына кереп дәрес ала башлый. Бервакыт ул бер аждаһаны күрә. Ул аждаһа юл өстендә тора һәм кешеләргә йөрергә комачаулый. Габдулла бер таш ала һәм әйтә: «Әгәр дә заһид дине хак булса, мин бу аждаһаны үтерә алсам иде, йә, Хода!». Ул ташны ыргыта һәм Аллаһ кодрәте белән аждаһа һәлак була. Заһид янына баргач, Габдулла аңа бөтен күргәннәрен сөйли һәм заһид аны: «Син тиздән сыналырсың», – дип кисәтә.

Ул заманда потка табынучы бер патша була. Аның карендәшенең угълы сукыр иде. Ул Габдулланың аждаһа белән булган могъҗизасын ишетеп, аннан күзләрен шифаландыруын сорый. Габдулла Аллаһтан дога кылып сорый – бу кешенең күзләре күрә башлый һәм ул бер Аллаһка иман китерә. Патша карендәшенең улыннан сорый: «Сине кем дәвалады?» Теге әйтә: «Җир һәм күкләрнең Раббысы. Мин Аңа иман китердем». Патша аңа бу диненнән ваз кичәргә боера, тегесе әйтә: «Теләсә нәрсә эшләт, бу диннән ваз кичмәм». Патша аны пычкы белән урталай кистереп, бик каты җәзалап үтертә.

Соңыннан патша теге заһид белән Габдулланы эзләп таба һәм бу диннәреннән кире кайтырга боера. Тегеләр ризалашмый. Заһидне шулай ук пычкы белән кисеп җәзалап үтерәләр. Габдулланы таудан аска таба ташларга боера. Ул Аллаһка: «Бу залимнән сакла!» – дип дога кыла. Тау ишелеп төшә, патшаның гаскәре һәлак була, Габдулла котыла.

Габдулла кабат патша янына бара һәм аңа Аллаһка иман китерергә куша. Патша моның исән калуына гаҗәпләнеп, аны тагын көймәгә утыртып диңгезгә ташларга боера. Габдулла

тагын: «Илаһи, мине бу бәладән коткар!» – дип дога кыла, Аллаһ кодрәте белән көймә каплана, патшаның кешеләре һәлак була, Габдулла котыла. Ул тагын патша янына бара. Патша аны кылыч белән чабарга боера, ләкин аңа бер зыян да китерә алмыйлар. Күп кешеләр, «Габдулланың дине хак икән», – дип, иман китерәләр.

Габдулла патшага әйтә: «Әгәр дә син: «Бу егетнең Раббысы исеме белән», дип әйтеп, ук белән атсаң гына үтерә алырсың». Патша нәкъ шулай эшли һәм аны үтерә. Габдулла иман кәлимәсе әйтеп үлә. Барча халык егетнең Раббысына иман китерә. Патша: «Бу егет мине алдап, шулай халыкны бер Алла диненә кертте», – дип кайгыра һәм барча халыкка бу диннән ваз кичәргә боера. Әмма халык риза булмый. Ул бер чокыр казытып, анда ут төртә һәм бу диннән ваз кичмәгәннәрне шунда атарга боера. Шулай итеп, бөтен мөселманнарны хатыннары, балалары белән утка аталар. Аллаһ ут чыгарып бу патшаны шәһәре белән яндырып-көйдереп һәлак итә[1].

Бу кыйсса тулысынча Аднаш хафиз иҗат иткән заманның хәлләренә туры килә. Кыйссадагы явыз патша урынында шул ук Явыз Иван яки аның Казанга җитәкче итеп куелган кешеләре күздә тотыла кебек. Әсәрдә патша халыкны потка табынырга мәҗбүр итә. Потка табыну – шул ук чукыну, христиан динен кабул итү булырга мөмкин. Чөнки христианнар төрле изгеләр сыннарына, ягъни иконаларга табыналар. Мәскәү хөкүмәте татар халкын чукындыру өчен үзенең бөтен көчен сарыф итә диярлек. Халык икесенең берсен сайларга тиеш була: чукынып христиан динен кабул итү яисә хәерчелек, үлем. Аднаш хафиз, әлбәттә, бу ике нәрсә арасыннан кайсын сайларга кирәклеген әсәрдә ап-ачык итеп күрсәтә.

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 91–95.

Чукындыру сәясәте әле Казанны алганчы ук бик киң кулланылганын Шиһабетдин Мәрҗани дә язып калдырган. Ибраһимнан соң хан булып калган олы улы Илһам (1479–1487) этисенең сәясәтен дәвам иттерә. Моны ошатмаган Иван III Казанга берсе артыннан берсе походлар оештыра. Соңгысы, ягъни 1487 елдагысы нәтиҗәсендә Казан алына, ләкин ханлык бетерелми, аның каравы Илһамны, аның әнисен, хатынын һәм ике энесен – Мәликтаһир белән Ходайголны әсирлеккә алып китеп, Вологда җиренә сөргенгә сөрәләр. Илһам үзе, әниләре Фатыйма, Мәликтаһир тиздән шунда үләләр, Ходайгол һәм Мәликтаһирның ике улын чукындыралар. Ходайгол Пётр Ибраһимович исеме белән Иван III гә хезмәт итәргә мәҗбүр була, хәтта аны бөек кенәзнең сеңлесенә өйләндерәләр[1].

Шулай ук 1549 елда Сафагәрәй үлгәч, аның ике яшьлек улы Үтәмешгәрәйне хан итеп куялар, аның өчен әнисе Сөембикә идарә итеп тора, ләкин аларның икесен дә 1551 елда Мәскәүгә әсирлеккә алып китәләр. Шунда Үтәмеш Александр исеме белән чукындырыла, 1564 елда унсигез яшендә үлеп китә; кабере Пётр Ибрагимович, ягъни Ходайголныкы, һәм рус патшаларыныкы белән янәшә – кремльнең Архангель соборында[2].

1536 елда да татар сугышчыларының әсирлеккә төшкән хатыннары һәм балаларының күпләп чукындырылуы тарихтан билгеле. Бу «Полное собрание летописей» хезмәтенең VI томында бирелә: «Тое же зимы, лета 7044 (1536 г.), онех прежде реченных татар жены же их видевше мужей своих, по своей скверной вере, скорую и нужную смерть и погибши

---

[1] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 115.

[2] Шунда ук. Б. 116.

же душею и телом, они же ярко от злаго сна воспрянувшие и начаша приходяще молитися боголюбивому архиепископу Макарию, просити святаго крещения. И пресвященный архиепископ Макарий посылал к государю великому князю Ивану Васильевичю всеа Русии и моля о них, чтобы их крестити, хотя бо вся человеки спасти и в разум истинный привести; и государь князь великий повеле их крестити. И архиепископ Макарий повеле их роздати по священником соборным святей Софеи и по градским священником, где которым подобно быти, и повели их учити по правилам… И просветити их святым крещением… А крестишася числом в Великом Новгороде жён 43, а детей 36, а во Пскове крестиша жён и детей 50 и един, а в Орешке 12, а в Кореле 30; и се елико множество душ избыша козни лукаваго диявола и познаша святую православную веру…»[1]

1555 елда Аднаш хафиз китергән кыйссага охшаш вакыйга була. Халыкны елга буена алып чыгалар һәм икесенең берсен сайларга кушалар: яки мөселман диненнән ваз кичеп, христианлыкны кабул итәләр һәм исән калалар, яки җәзалап үтереләләр. Чукынырга риза булган кешеләрне исән калдырып монастырьларга озаталар, чукынырга риза булмаганнарны бәкегә атып батырып үтерәләр. Моңа дәлил итеп «Полное собрание летописей» хезмәтеннән түбәндәге язманы китерергә мөмкин: «В лето 7063 (1555 г.)… Да той же зимы, месяца генваря в 1-вторник, давали дияки по манастырем татар, которые сидели в тюрьме и захотели креститись; которые не захотели креститись, ино их метали в воду…»[2]

Моңа охшаш хәлләр, мөгаен, еш булгандыр. Әдип тә бу кыйссаны юкка гына китерми. Ул халыкны иманын, бик зур

[1] История Татарии в материалах и документах. М.: Гос. соц.-экон. изд-во, 1937. С. 145.

[2] Шунда ук. С. 146.

корбаннар белән булса да, саклап калырга, дөнья дип, ахирәтләрен югалтмаска, бу каршылыкларга сабыр итәргә өнди. Чөнки әүвәл заманнарда яшәгән кешеләр, әсәрдән аңлашылганча, үзләренең хак диннәреннән ваз кичмәгәннәр, диннәрен ташларга ашыкмаганнар, иманнарын саклап калу өчен дөрләп янган утка да керергә курыкмаганнар. Алар җәһәннәм утының бу дөнья утына караганда җитмеш мәртәбә көчлерәк, газаплырак икәнен аңлаганнар, шуңа күрә утка курыкмыйча сикергәннәр. Аднаш хафиз бу кешеләрне үз заманы кешесе өчен үрнәк итеп куя һәм, билгеле, алар кебек нык булырга өнди, чөнки бу дөнья һәм анда булган нәрсәләр чүп кебек бернәрсәгә дә тормый, дигән фикер уздыра. Моны аңлау өчен суфичылыкка мөрәҗәгать итеп, суфилар күзлегеннән дә карарга кирәк.

«Дөнья тормышы суфилар өчен – диңгез, ахирәт – аның ярлары, бу диңгезне кичеп, ярга чыгу өчен кешегә кирәк булган көймә – ул иманлылык, диндарлык. Кешеләр – диңгез сәяхәтчеләре, кайчак алар, ярга җитә алмый, бу дөнья диңгезендә батып калалар, кайчагында теләкләренә ирешәләр – ярга чыгалар»[1].

«Урта гасырлар Көнчыгыш фәлсәфи-эстетик фикер тарихында үлем темасы киң каралган. Бу проблеманы аңлау-аңлатуда һәр фәлсәфи юнәлеш, мәзһәбнең үз карашы булып, башкалардан аерылып торган. Мәсәлән, берәүләр Аллаһка омтылу юлында үлемне иң бөек хозурлык, бәхетле күчеш дип санаса (суфичылык), икенчеләре анда дөньяда җыйган гөнаһлардан котылу юлын күрде (калям), өченчеләре исә үлемне матди форманың рухны саклау өчен вакытлыча әверелеше дип күрсәтте (исмәгыйлилек) һ.б.

[1] Сибгатуллина Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык: чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре: филол. фән. док. дис. Алабуга, 2000. Б. 170.

Фәлсәфи планда үлем проблемасы күп кенә галимнәрне аптырауда калдырса, әдәби-эстетик планда бу тема язучыларга кешенең дөньядагы урынын күрсәтү өчен үзенчәлекле бер юлга әйләнде. Урта гасыр Шәрык акыл ияләре бу мәсьәләгә эстетик позициядән якын килеп, үлемнән ниндидер коточкыч фаҗига ясамыйча, оптимистик, гуманистик идеалның тантана итүе итеп сурәтләделәр. Рүдәки, Фирдәүси, Насыйр Хөсрәү, Ибне Сина, Гомәр Хәйям, Җәлалетдин Руми кебек бөек аксакаллар фани дөньядагы явызлык, пассивлык күренешләре белән килешмәүчәнлекне тәкърарлады.

Суфичылык үзенең эстетик доктринасында үлем темасын иң югары ноктага күтәрә, дөньявилыктан ваз кичү, үлем анда иң әһәмиятле мәсьәлә санала, шунлыктан суфичылык теоретиклары үлемне санламаган, искә алмаган укымышлыларны хәтта нәфрәт утына тотканнар. Тасаувыф поэзиясендә җанның Аллаһ рухы белән кушылырга омтылу идеясе матур-матур поэтик образлар, чагыштырулар тудырган»[1].

«Суфилар үлемнән курыкмыйлар, ә, киресенчә, шатланып каршы алалар, чөнки алар үлгән кешенең рухы Аллаһ белән кавыша, дип өмет итәләр»[2].

Димәк, суфилар өчен үлем ниндидер кайгы итеп түгел, ә, киресенчә, шатлык кебек кабул ителгән, чөнки алар теге дөньяда Аллаһы Тәгалә белән кавышканнар, җаннары илаһият белән кушылган.

«Сираҗел-колүб» әсәрендә китерелгән Габдулла турындагы кыйсса Коръәннән һәм хәдисләрдән алынган. Коръәннең «Буруҗ» («Каланча») сүрәсендә кыскача болай тасвирлана:

---

[1] Сибгатуллина, Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык: чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре: филол. фән. док. дис. Алабуга, 2000. Б. 171–172.

[2] Шунда ук. Б. 172.

«Чокыр ияләренә ләгънәт булды һәм һәлак булдылар. Канау казып ул канауны ут белән тутыручы кяферләргә Аллаһның ләгънәте булды. Кяфер гаскәре мөселманнарны утта яндырганда, патша үзенең якыннары илә, тамаша кылып, карап утыралар иде. Алар мөэминнәрне утта яндырып газап кылуларына гуаһлардыр. Ул кяферләр мөселманнарны утта яндырырлык гаеп тапмадылар, мәгәр кодрәт иясе вә мактаулы булган Аллаһка иман китергәннәре өчен генә аларны утта яндырып газап кылдылар» («Буруҗ» («Каланча») сүрәсе, 4–8 аятьләр).

Нурулла хәзрәт төзегән Ногмани тәфсирендә бу аятьләргә аңлатма һәм «Сиражел-колүб» әсәрендәгечә эчтәлек бирелә[1].

Коръәндә тагын шуңа охшаш аять бар: «Ий, сез, мөэминнәр! Аз гына гамәл белән, җиңел генә җәннәткә керергә исәплисезме? Сездән әүвәлге кавемнәргә килгән авырлыклар әле сезгә килгәне юк. Аларны ачлык, сырхау, бәла-казалар һәм сугыш авырлыклары тотты, хәтта көчләре бетте, пәйгамбәр һәм аңа ияргән мөэминнәр әйттеләр: «Аллаһның ярдәме безгә кайчан булыр икән», – дип. Аң булыгыз! Төрле авырлыкка чыдап һидәяттә нык торган мөэминнәргә Аллаһның ярдәме, әлбәттә, бик якын» («Бәкара» («Сыер») сүрәсе, 214 нче аять).

«Әсхәбел-үхдүд» кыйссасы турында «Сахих Мөслим» җыентыгында бер хәдис тә бар. Гадәттә аны «Сихерче һәм егет турындагы хәдис» дип атыйлар. Аның тулы эчтәлеге мәшһүр хәдисләр җыентыкларында очрый. Нигездә, аның эчтәлеге «Сиражел-колүб» әсәрендәгечә бирелә. Ләкин ахыры бераз башкача тәмамлана: иман китергән кешеләрне утка берәм-берәм атканда, чират бер балалы хатынга җиткәч, бу хатын иманыннан ваз кичергәме, юкмы дип икеләнеп торганда, аның

---

[1] Коръән тәфсире. Казан: Татар кит. нәшр., 1996. Б. 657–658.

күкрәк имә торган баласы, телгә килеп: «Әни, сабыр ит, сикергә курыкма, син хак юлда!» – дип әйтә[1].

Шушы ук темага «Сахих әл-Бохари» җыентыгында тагын бер хәдис китерелә: Хәббәб бине әл-Аратт сөйләгән: «Бервакыт Аллаһның рәсүле баш астына киемен куеп Кәгъбә күләгәсендә ятканда, без аңа, мөшрикләрнең рәнҗетүләреннән зарланып, үтендек: „Безнең өчен Аллаһтан ярдәм сорамассыңмы икән? Безнең өчен Аллаһка дога кылмассыңмы икән?» Җавап итеп ул әйтте: «Сезгә хәтле яшәгән кешеләрне тотып, чокыр казып, шунда ташлыйлар иде, соңыннан пычкы белән урталай кисәләр иде, ләкин барыбер үз диннәреннән чыкмыйлар иде. Шулай ук кешеләрне тимер тараклар белән итләрен тарыйлар иде, ләкин барыбер үз диннәреннән чыкмыйлар иде»[2].

Бу кыйсса Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә дә китерелә. Сюжеты аның нәкъ «Сираҗел-колүб» әсәрендәге кебек. Ләкин кайбер детальләрдә аермалар бар. Мәсәлән, «Кыйсасел-әнбия» дә сихерче, картаюы сәбәпле, үзе патшадан бер зирәк бала соратып ала. «Сираҗел-колүб»тә сихерчегә, гыйлем алырга дип, Йәэмән исемле гади бер кеше үзенең баласын җибәрә. Шулай ук «Кыйсасел-әнбия»дә егет теге сукыр кешене күзле иткәч, патша «Кем сине терелтте?», – дип газаплый башлый һәм ул газапларга түзә алмыйча: «Мине теге егет күзле итте»,– дип егетне сата. Егетне патша янына алып килгәч, ул да: «Мине бу дингә заһид өйрәтте», – дип заһидне сата[3]. «Сираҗел-колүб» әсәрендә күзләре сәламәтләнгән кеше,

---

[1] Сахих Муслим. / Пер. И. Попова. В четырёх томах. Т. 4. Казань: Иман, 2004. С. 842–843.

[2] Сахих аль-Бухари / Пер. В.Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим Бин Абдулазиз Аль Ибрагим». 2002. С. 437.

[3] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 324–329.

күпме генә газапланса да, барыбер егетне сатмыйча җәзаланып үлә. Патша Габдулла белән заһидне үзе ничектер таба. Кем аркылы тапканы әйтелми[1]. Димәк, Аднаш хафиз, әсәрне үзенчә бераз үзгәртеп бирә. Монда аның сатлыкҗаннарга мөнәсәбәте күренә. Аллаһ диненә кергән кешеләр берничек тә бер-берсен сата алмыйлар, дигән фикер әйтә. Шуңа күрә Аднаш хафиз мөселманнарның тискәре сыйфатларын күрсәтмәскә омтыла. Әгәр дә күзе сәламәтләнгән кеше Габдулланы сатса яки Габдулла заһидне сатса, бу аларны үлем куркынычы астына куя, патша аны җәзага тартачагы көн кебек ачык. Шуңа күрә: «Синең гомереңбашка мөселманның гомеренә караганда нәрсәсе белән кадерлерәк, яхшырак соң?» – дигән сорау куеп, башка кешенең гомере белән үзеңнең гомереңне саклап калу – бик зур кабахәт эш, дип белдерә автор. Моның белән ул хыянәт проблемасын күтәреп чыга.

Тарихка күз салсак, татарлар арасында хыянәт итү, бер-береңне сату кебек күренешләр бик таралган була. Мисал өчен шул ук Шаһ Галине, шулай ук Мәскәү яклы партия әгъзаларын китерергә мөмкин. Казаннан киткәндә хыянәтче хан Шаһ Гали дары мичкәләренә су агызып китә[2]. Мәскәү яклы партия әгъзалары да, хыянәтләре сәбәпле, Мәскәү тарафыннан бүләкләнәләр: «В этой связи необходимо отметить, что представители татарской феодальной аристократии, являвшиеся сторонниками или членами московской партии, поступившие на московскую службу, получили вотчины и поместья и активно содействовали колониальной политике самодержавия»[3].

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 94.

[2] Фәхретдинов Р.Г. Казан ханлыгы // Казан утлары. 1999. № 10. 113 б.

[3] Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей, как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии // Материалы по истории Татарии. Казань: Татгосиздат, 1948. С. 227.

Казан ханлыгын кире кайтарырга тырышкан азатлык хәрәкәтләрендә дә кайбер татар төбәкләре катнашмый. Киресенчә, үз милләттәшләрен сатып, Мәскәү хөкүмәтенә булышалар. Моны тануы авыр булса да, бу бик күп хезмәтләрдә телгә алына: «Вместе с тем единение не было всеобщим. Татарское население правобережных районов Волги (Горной стороны) в основном не принимало участия в освободительной борьбе. Более того, оно нередко поддерживало русские войска, подавляя выступления своих соплеменников»[1].

Аднаш хафиз, шулай ук, тагын Җирҗис пәйгамбәр кыйссасын китерә. Бу кыйсса да «Әсхәбел-үхдүд» кыйссасы белән охшаш. Мәүсаль җирендә Дәдьянә исемле бер залим падишаһ була. Бер көнне ул Әфлүн исемле потын алтын-көмеш, энҗе, гәүһәр белән бизәп, башына таҗ кидереп, сахрага чыгарып алтын тәхеткә утыртып куя. Аның янына чокыр казытып ут яга. Халыкка шул потка сәҗдә кылырга куша. Кем сәҗдә кылмый – аны шул чокырга ыргытырга боера. Бу арада Җирҗис пәйгамбәр, сәүдәгәр буларак, бу шәһәргә килә. Ул патшаның бу эшен күреп, аңа каршы чыга, аны Аллаһ диненә чакыра. Аны агачка бәйләп, тимер тараклар белән итен тарыйлар, тимер чыбыкны кыздырып, Җирҗис галәйһиссәламнең табаныннан кертеп, тамагыннан чыгаралар. Аллаһ кодрәте белән, ул исән кала. Халык бу хәлне күргәч, аның диненә авыша башлый. Шуннан аны зинданга ябып куялар, аш-су бирмичә тоталар, бәйләп бер зур ташны аркасына бастырып куялар. Бер фәрештә ул ташны Җирҗис галәйһиссәлам аркасыннан ала, ризык бирә, шәраб эчерә һәм зинданнан чыгара. Патша ике такта арасына Җирҗис галәйһиссәламне куеп, пычкы белән ярып, итен арысланнарга ташлыйлар. Аллаһ кодрәте

[1] История Татарстана: Учебное пособие для основной школы. Казань: Тарих, 2001. С. 105.

белән арысланнар аны ашамыйлар, Аллаһ Тәгалә аны кабат тергезә, бер фәрештә килеп ризык ашата, шәраб эчертә. Җирҗис галәйһиссәлам тагын патшаны Аллаһ диненә чакыра. Патша вәзирләре белән киңәшләшә, бер вәзире үтерү ысулын тәкъдим итә. Үгез сурәтен ясап, эчен нефть белән тутыралар, Җирҗис галәйһиссәламне шул үгезгә куеп, ут төртәләр һәм ул вафат була. Аллаһ аны кабат терелтә һәм Җирҗис пәйгамбәр патшага әйтә: «Әгәр Аллаһы Тәгаләгә иман китермәсәң, минем пәйгамбәр икәнемә ышанмасаң, Ул сине газап кылачак». Патша шарт куя: «Әгәр бу багана кабат агачка әверелеп яшәрсә, җимешләр бирсә, синең динеңне кабул итәрмен», – ди. Җирҗис галәйһиссәлам дога кыла һәм Аллаһ кодрәте белән теге багана яшәреп, нигъмәтләр пәйда була. Халыкның бер өлеше, иман китереп, мөселман була. Патша барыбер иман китерми, тагын бер шарт куя: «Бездән элек үлгәннәр терелсен, һәм синең пәйгамбәрлегеңә таныклык бирсеннәр, шуннан соң сиңа ышанырбыз», – ди. Җирҗис галәйһиссәлам дога кыла һәм Аллаһ кодрәте белән зиратта җиде кеше терелеп, әйтәләр: «Әй падишаһ, зинһар, иман китер, без дә мөселман булмаганга газапландык». Патша барыбер иман китерми, Җирҗис галәһиссәламне тотып, бер сукыр карчык өенә, ризык бирмичә, ябып куялар. Аллаһ кодрәте белән бер казык, агачка әверелеп, җимешләр бирә, теге сукыр карчыкның күзләре күрә башлый, ул иман китерә. Патша тагын шарт куя: «Әгәр минем Әфлүн исемле потыма сәҗдә кылсаң, иман китерермен», – ди. Патшаның хатыны иман китерә, моның өчен патша аны җәзалап үтерә. Җирҗис галәйһиссәлам потка табынудан баш тарта, Аллаһка дога кыла һәм күктән ут төшеп, патшаны һәм бөтен кяферләрне көйдереп һәлак итә[1].

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 81–89.

Бу кыйсса белән дә әдип үзенең әйтергә теләгән фикерләрен куәтли. Монда да киная бар: шушы патша образы аша Явыз Иванны яки аның тарафыннан Казан белән идарә итү өчен куелган залим җитәкчеләрне сурәтли сыман. Шушы патша кебек үк, ул да халыкны талый һәм моның белән генә туктап калмыйча, иманнарыннан да, диннәреннән дә ваз кичтерергә тели. Аднаш хафиз халыкны шушы сәясәткә каршы торырга өнди. Әмма ул беркайчан да корал белән каршы чыгуны күздә тотмый, ә моңа каршы халыкка үзләренең ныклыгын, сабырлыгын, иманын, игътикадын куеп җиңәргә өнди. Әгәр дә бу эштә нык торсалар, авырлыкларга сабыр итсәләр, залим патшалардан Аллаһ аларны Үзе саклаячак, ахыр чиктә патша, хурлыкта калып, һәлак булачак икәненә Аднаш хафиз чын күңелдән ышана һәм башкаларны да шуңа ышандырмакчы була.

Залим патшалар проблемасын тикшергәндә Аднаш хафизның Мәхмүд әл-Болгари белән күпмедер дәрәҗәдә охшашлыгы күренә. Мәхмүд әл-Болгари Сәгыйт бине Җабир турында хикәя китерә. Анда Хәҗҗаҗ исемле хәлифә золымыннан Сәгыйт бине Җабир тау куышына качып китә. Хәлифә боерыгы белән аны эзләп табып китерәләр. Үзенә каршы сүз әйткәне өчен, хәлифә аның башын кисәргә боера. Сәгыйт бине Җабир моңа шатланып: «Шаһит булсам, минем дәүләтем һәм бәхетем булачак», – дип, җәннәтне күздә тотып, бер дә курыкмыйча үлемне кабул итә. Шәйх Хәсән Басри Сәгыйтнең үтерелгәнен белгәч: «Йә, Раббым, ул Хәҗҗаҗны үтер!» – дип дога кыла һәм хәлифә, кырык көн чиләнеп ятып, үлә. Берәү Җәҗҗаҗны төшендә күрә: ул әйтә: «Һәр җәзалап үтергән кеше өчен мине берәр тапкыр, Сәгыйт өчен җитмеш тапкыр тәмугта үтереп җәзаладылар»[1].

[1] Әл-Болгари М. Нәһҗел-фәрадис; әсәрне басмага әзерләүче, кереш мәкалә авторы Ф. Нуриева. Казан: Татар кит. нәшр., 2002. Б. 287–290.

Мәхмүд әл-Болгари халыкка җәбер-золым китерә торган патшаларны тәнкыйтьли, гаделлеккә чакыра. Аның залим патшаларга җәза бирүе Аднаш хафиз кебек ислам идеологиясеннән чыгып карала. Алар иҗатының охшашлыгы нәкъ менә шушы яктан күзәтелә. Ләкин Мәхмүд әл-Болгари сурәтләгән залим патша кешеләрне физик яктан гына эзәрлекли, ә Аднаш хафиз сурәтләгән залим патша халыкны физик яктан да, рухи яктан да эзәрлекли.

Казан ханлыгында яшәп иҗат иткән шагыйрь Мөхәммәдъяр хәтта кяфер патшаның гадел була алуына ышана һәм, аның фикеренчә, гадел кяфер патша, залим мөселман патшага караганда, халык өчен яхшырак була ала:

«Көфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым берлә екылыр улуг йөдәп;

Көфер вә кәфир нәфсенә кыйлыр зийан,
Золым берлә булыр ил хале яман»[1].

Шулай итеп, Казан ханлыгы яулап алынгач, халык дәүләтсез калгач, рухи яктан изелүгә дучар булгач, әдипләрнең фикерләре һәм карашлары үзгәрә.

Гадә углы Шәдәд турындагы кыйсса да бик кызыклы. Ул бик бай кеше була. Бер көнне ул, үзенең бөтен байлыгын җыеп, җир йөзендә үзенә күрә бер җәннәт бакчасы төзи башлый. Ул аны бик мул итеп төзи, анда җаның теләгән нәрсә була, ул җиләк-җимешләр дисеңме, алтын-көмеш сарайлар дисеңме. Шәдәд үзен Аллаһ дәрәҗәсенә күтәрә һәм әйтә: «Әй, кешеләр, менә мин сезгә күк Аллаһысыныкы кебек җәннәт бар кылдым!». Ул бик масая башлый. Шунда Аллаһ Җәбраил

---

[1] Мөхәммәдъяр. Нуры содур; кереш сүзне, текстларны, искәрмәләр һәм сүзлекне хәзерләүче Ш. Абилов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. Б. 85.

фәрештәне җибәреп, ул бик каты аваз чыгарып Шәдәдне һәм аның кешеләрен һәлак итә[1].

Моннан аңлашылганга, Шәдәд кешеләрне байлык белән алдап кызыктырмакчы була, кешеләрне көферлеккә чакыра. Безнең Казан ханлыгы яулап алынгач та, бу сәясәт чиркәү тарафыннан бик актив кулланыла. Кешеләргә, үз диннәреннән ваз кичсәләр һәм, чукынып, христиан диненә күчсәләр, матди бәйсезлек, кайбер салымнардан азат ителү, төрле өстенлекләр вәгъдә ителә:

«Крещение проводилось насильственными административными мерами воздействия и при помощи льгот, предоставлявших принявшим христианство, как-то: освобождение на известный срок от уплаты ясака, предоставление лучших земельных и лесных угодий новокрещённым и др.»[2].

Кем чукынырга теләми, аларны, киресенчә, бик зур салымнар түләргә мәҗбүр итәләр. Бигрәк тә морзаларны, ягъни феодаль катлауны христиан диненә кертергә тырышалар. Чөнки гади халык аларның сүзләренә колак салган, тыңлаган һәм хөрмәт иткән.

«Морзалар чукынган очракта утарларын һәм крәстиәннәрен кире кайтарып кына калмыйлар, ә дин алмаштырган өчен аларга хәтта 10 тәңкә акча да вәгъдә ителә; чукынган очракта хатын-кызлар – 5, бала-чага 2,5 тәңкә акча алырга тиеш булган. Йомышлы татарларга чукынган өчен акчалата бүләк икеләтә кимрәк билгеләнә»[3].

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 96–100.

[2] Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей, как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии // Материалы по истории Татарии. Казань: Татгосиздат, 1948. С. 228.

[3] Ислаев Ф.Г. Чабаталы морзалар // Идел. 2000. № 6. Б. 20.

Шулай итеп, Казан алынып бетү белән Мәскәү хөкүмәте татарларны һәртөрле ысуллар белән хәйләләп, кыстап, җәберләп булса да христианлыкка өнди башлаган.

«…А которые татаровя похотят креститись своею волею, а не от неволи, и ему тех велети крестити, и лутчих держати у себя в епископе и поучати всему крестьянскому закону, и покоити их как мочно, а иных раздавати крестити по монастырем; а как новокрещены из под научения выдут, и архиепископу их звати к себе ясти почасту, а поити их у себя за столы квасы, а после стола посылати их поити мёдом на загородской двор»[1].

Аднаш хафиз татарлар алдында килеп туган бу афәттән котылу өчен тагын бер юл тәкъдим итә. Ул – качып китү яки һиҗрәт кылу. Әдип бөтен татарларның да, иманнарын саклап калу өчен, шундый зур корбаннарга барырга, нык торырга көчләре җитмәүләрен аңлый. Чөнки араларында зәгыйфь иманлы кешеләр дә булырга мөмкин һәм аларга бу фетнәдән башка җиргә качып китү кулайрак һәм файдалырак була, дип саный автор.

Бу юлны күрсәтү өчен Аднаш хафиз «Әсхабел-кәһеф» кыйссасын китерә. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгечә:

Үзен Аллаһ урынына куйган бер патша була. Көннәрдән бер көнне аңа фарсы иленә яу килгәнен әйтәләр. Шунда курkуыннан аның башыннан таҗы төшеп китә һәм янындагылар бу хәлгә хәйран калалар. Йәмлиха исемле бер ярдәмче карендәшләренә әйтә: «Бу курка торган патша ничек тәңре булсын? Безне яраткан бер Аллаһ кына тәңре була ала». Алар иман китерәләр һәм патшадан качып китәләр. Юлда алар бер көтүчене очраталар. Ул да, иман китереп, бу егетләргә кушыла. Көтүченең Кыйтмир исемле эте була. Аны куып кайтармакчы

---

[1] История Татарии в материалах и документах. М.: Гос. соц.-экон. изд-во, 1987. С. 146.

булалар, ләкин ул, телгә килеп: «Мин сезне дошманнан саклармын», – дип әйтә. Бу могҗизаны күргәч, алар этне үзләре белән алырга булалар. Егетләр бер тауга килеп җитәләр. Анда эчәргә – чишмә, ашарга хөрмә агачы корыган була. Болар ашыйлар-эчәләр һәм тау тишегенә кереп йокларга яталар. Шунда Аллаһы Тәгалә аларның җаннарын ала, яки уяна алмаслык итеп йоклата. Патша егетләрне эзләп таба һәм, боларның мәетләр кебек ятканнарын күреп: «Болар инде үлгәннәр икән», – дип, китә. Егетләр Аллаһы Тәгалә кодрәте белән өч йөз тугыз ел яталар. Соңыннан торып, гаҗәпләнәләр: чишмә кипкән, хөрмә агачы корыган була. Йәмлиханың кесәсендә бер көмеш була, шуны алып, шәһәргә ризык алып кайтырга китә. Ашчыга бу акчаны биргәч, ул, гаҗәпләнеп, Йәмлихадан бу акчаны кайдан алуын сорый. Йәмлиха: «Үземнең хәләл акчам», – дип җавап бирә. Ләкин ашчы аны патша янына алып бара. Бу патша мөселман була. Йәмлиха аңа бөтенесен сөйләп бирә. Ләкин шәһәрдә аны беркем дә белми һәм танымый. Фәкать бер карт заһид аны танып: «Минем бабам сезнең качып китүегез турында сөйләгән иде», – дип әйтә. Йәмлиха өч йөз тугыз ел үткән булганга бик гаҗәпләнә, халык та бу могҗизага шакката. Патша Йәмлиха белән ике бәген тауга җибәрә. Йәмлиха үзенең иптәшләренә өч йөз тугыз ел үткәнен сөйли. Егетләр: «Безгә дөнья кирәк түгел, ахирәт кирәк; безне үтерсәң иде, йә Аллаһ», – дип дога кылалар һәм үләләр. Йәмлиха белән килгән бәкнең берсе мөселман, берсе кяфер була. Мөселман бәк бу җиргә мәчет төзетергә тели. Кяфер бәк кәлисә (чиркәү) төзетмәкче була. Икесе арасында сугыш башлана. Мөселманнар ярдәмгә киләләр, мөселман бәк кяфер бәкне үтерә, соңыннан мөселманнар бөтен кяферләрне юк итәләр, малларын ганимәт итеп алалар, бу җирдә мәчет салалар имеш[1].

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 124.

Аднаш хафиз динен саклап калу өчен качкан кешеләрне Аллаһы Тәгаләнең ташламавын, аларга һәрвакыт ярдәм итүен, үзенең кодрәте белән төрле могҗизалар кылып, бәлаләрдән коткаруын ассызыклый. Чөнки бөтен галәм Аның кулында, яшәү белән үлем, вакыт төшенчәсе тулаем Аңа буйсына, фәкать Аңа ышанырга, тәвәккәл кылырга, ярдәм сорап Аңа гына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Бу кыйсса Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә дә китерелгән. Нигездә ул анда да нәкъ «Сираҗел-колүб»тәгечә бирелә. Ләкин «Сираҗел-колүб»тә егетләр тауга килгәч, алар өчен ашарга хөрмә агачы һәм эчәргә чишмә суы әзерләнгән була, әйтерсең лә Аллаһы Тәгалә махсус аларның килүенә бу нигъмәтләрне әзерләп куйган[1]. «Кыйсасел-әнбия»дә исә бу турыда берни дә әйтелми.

«Сираҗел-колүб» әсәрендә, «Кыйсасел-әнбия»дән аермалы буларак, Аллаһы Тәгаләдән башка беркемнән курыкмаска, дигән фикер өстәлә. Мәсәлән, көтүченең эте егетләргә: «Кем Аллаһка ышанса һәм тәвәккәл кылса, ул дошманнардан куркырмы?» – дигән риторик сорау куя[2]. Шулай ук ашчы Йәмлиханы мәлик янына алып барырга җыенгач, Йәмлиха аңа: «Мине мәлик берлә нигә куркытасың, мин Аллаһы Тәгаләдән үзгә һич кешедән курыкмасмын», – дип әйтә[3].

«Кыйсасел-әнбия»дә патша тычканнан курыкса[4], «Сираҗел-колүб»тә патша фарсы иленә килгән яудан куркып, башыннан таҗы төшеп китә. Шулай ук егетләрнең исемнәре дә әсәрләрендә төрлечә бирелә. Бу аларның чыганаклары төрле

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 118.

[2] Шунда ук. Б. 118.

[3] Шунда ук. Б. 121.

[4] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 336.

булуы белән аңлатыладыр. Гомумән, ислам чыганакларында егетләрнең төгәл саны билгеле түгел, шул сәбәпле исемнәре дә төрле булуы ихтимал. «Сираҗел-колүб» әсәрендә алты егет Юныс, Зәрьюныс, Бүзлүс, Йәмлиха, Мәксилминә, Милсилинә исемнәре белән бирелә[1]. «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә алар Йәмлиха, Мәкешлинә, Мәшлинә, Мәрнуш, Дәбернуш, Шәзүнүш исемнәре белән бирелә[2]. Этнең исеме (Кыйтмир) ике әсәрдә дә бер үк килә. «Сираҗел-колүб» әсәрендә көтүченең Әркам исемле булуы да әйтелә[3], «Кыйсасел-әнбия»дә аның исеме телгә алынмый.

Коръәндә бу егетләр турында «Кәһеф» («Тау тишеге») сүрәсендә бик ачык итеп сөйләнелә, егетләрнең ничәү булганнары гына төгәл әйтелми: «Тау тишегендә калган егетләрнең саны хакында бәгъзеләр әйттеләр: «Ул егетләр өчәү булып, дүртенчесе этләре иде», – дип. Вә бәгъзеләре әйттеләр: «Ул егетләр биш булып, алтынчысы этләре иде», – дип. Ләкин шулай әйтүләре белеп түгел, бәлки зан гынадыр. Вә мөселманнар әйтерләр: «Ул егетләр җиде булып, сигезенче этләре иде», – дип. Әйт: «Ул егетләрнең санын Раббым белә, аларның хәлен аз кемнәр белер». Син алар хакында кемнәр белән бәхәсләшмә, мәгәр Коръәндә әйтелгәннәрне генә әйт вә аларның хәлен һичкемнән сорама» («Кәһеф» («Тау тишеге») сүрәсе, 9–22 нче аятьләр).

«Кыйсасел әнбия»дән аермалы буларак, «Сираҗел-колүб» әсәрендә өстәмә детальләр кертелгән. Әсәр ахырында мөселман бәге егетләр үлгән җиргә мәчет төзетмәкче була, кяфер

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 115.

[2] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 336.

[3] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 117.

бәге кәлисә (чиркәү) төзетмәкче була. Болар сугыша башлыйлар, мөселманнар килеп – мөселман бәге, кяферләр кяфер бәге яклы булалар. Ахырдан мөселманнар җиңә, кяферләрнең малларын ганимәт итеп алалар һәм бу җиргә мәчет салалар[1]. Авторның христианнарга карата нәфрәте монда күзгә бәрелеп тора. Бу, әлбәттә, татарларны христианлаштыру белән бәйле булган, чөнки кәлисә фәкать христианнарда гына була, потка табынучыларда ул потханә дип бирелә.

Аднаш хафиз бу темага тагын Муса пәйгамбәр һәм аның кавеме турында кыйсса (риваять) китерә. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгечә:

Муса пәйгамбәр, үзенең кавемен ияртеп, Фиргавеннән кача. Фиргавен артларыннан куа китә. Муса кавеме зур дәрьяга очрый. Бер якта дәрья, икенче якта Фиргавен гаскәре. Нишләргә белмәгәндә, Муса пәйгамбәр Аллаһтан дога кылып сорый һәм дәрья икегә аерылып юл хасил була. Ләкин аның кавеме анда керергә курка, чөнки балчык юеш була, анда аяклар бата. Муса пәйгамбәр янә дога кыла һәм балчык кибә. Муса кавеме бу дәрья эченнән чыгып китә. Фиргавен һәм аның гаскәре дә алар артыннан керәләр, шунда Аллаһы Тәгалә дәрьяны кабат үз хәленә кайтара, Фиргавен һәм аның гаскәре суда тончыгып үләләр[2].

Шулай итеп, үз гомерләрен һәм иманнарын саклап калу өчен автор качып котылу юлын күрсәтә.

Бу кыйссаның сюжеты Рабгузыйның «Кыйсасел-әнбия» әсәрендә дә нәкъ «Сиражел-колүб» әсәрендәгечә бирелә. Бу кыйсса да, әлбәттә, Коръәннән алынган: «Фиргавен кавеменнән сезне коткаруыбызны да хәтерләгез! Алар сезне яман газап белән газаплап, кыз балаларыгызны калдырып, ир

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 123–124.

[2] Шунда ук. Б. 55–58.

балаларыгызны бугазлый иделәр. Бу эшләр сезгә Раббыгыздан бәла вә зур каза иде. Янә фикер итегез, ярдык Без сезләргә дәрьяны һәм сезне коткарып, Фиргавен кавемен һәлак иттек суда батырып, үзегез дә карап тордыгыз» («Бәкара» («Сыер») сүрәсе, 49–50 нче аятьләр).

Үз гомереңне һәм динеңне саклап калыр өчен, ислам дине буенча качып китәргә яки һиҗрәт кылырга ярый. Ярый гына түгел, бу хәтта мәҗбүри дә булып санала. Мәсәлән, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре Мәккә шәһәре мөшрикләренең рәнҗетүләренә, газаплауларына, мыскыл итүләренә түзә алмыйча, Мәдинә шәһәренә күчеп китәләр. Коръәндә дә һиҗрәт турында аятьләр бар.

Чыннан да, тарихтан мәгълүм булганча, татар халкының күбесе төрле якларга качып китәләр:

«Чтобы спастись от рук русских, разбежались они в разные стороны. Большинство их разбежалось в сторону запада в Крым и на Кубань; в тех местах, говорят, есть город Бахчисарай; путешественники о нём говорят, что он большой город, другой город называется Яхсай. В понизовье городов было много: Ак-Тубя (Актюбинск), Сары-Танг, Сарайчик, Куске, крепость Ишан. Многие переселились на реку Джим и Куан. Смешались с киргизами и превратились в киргизский народ. Около города Уфы, на реке Белой, там, где впадает река Дема, была крепость Кунгурат; жители оттуда переселились в Ургенч. Там соорудили крепость и её назвали тоже Кунгуратом»[1].

«Ихтиляльдә (1552–1558) иштирак кылган татарларның авыллары яндырылган, аларның күбесе Уралга таба, Себергә таба да качканнар»[2].

---

[1] История Татарии в материалах и документах. М.: Гос. соц.-экон. изд-во, 1937. С. 123.

[2] Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 167.

«Казан өлкәсендә калган татарлар да качып вә куылып яхшы мөнбит җирләрдән китеп, начар, таулы, коры урыннарга китеп утырганнар, аларның калдырып киткән урыннарын, мөнбит кырларын колонизаторлар ишгаль итә баралар, яисә усал Мәскәү түрәләре, алпавытлары төрле бәһанәләр белән татарларны куып, үзләре аларның җирләрен ишгаль итәләр»[1].

«Сахих әл-Бохари» җыентыгында Әбү Хөрәйрәдән түбәндәге хәдис китерелә: Аллаһның рәсүле саллаллаһү галәйһи вә сәлләм әйткән: «Шундый фетнәләр чыгар, ул вакытта утырып торучы басып торучыга караганда хәерлерәк булыр, басып торучы атлап баручыга караганда хәерлерәк булыр, атлап баручы йөгереп баручыга караганда хәерлерәк булыр. Кем алар янына барса, алар аны һәлак итәрләр. Шуңа күрә ул выкытта кем алардан качу урыны тапса, тизрәк качсын»[2].

Аднаш хафиз әле бу ике кыйсса белән генә чикләнмичә, кяферләрнең золымыннан Ильяс пәйгамбәрнең дә тауларга качып, анда җиде ел яшәгәнлеген сурәтли[3]. Шулай ук Гозәер пәйгамбәр дә, халыкны Аллаһ диненә чакырып йөргәндә, бер бик явыз патша шәһәрне басып алгач, ишәгенә атланып шәһәрдән качу ягын карый[4].

Шул ук вакытта Аднаш хафизның карашларында каршылыклы фикер дә бар кебек. Мәсәлән, Юныс пәйгамбәр белән бәйле вакыйгада. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгечә:

Юныс пәйгамбәр үз халкын Аллаһ диненә чакыра башлый, ләкин аның кавеме аны кабул итми, кире кага. Шунда Аллаһ

---

[1] Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 167.

[2] Сахих аль-Бухари / Пер. В.Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим Бин Абдулазиз Аль Ибрагим», 2002. С. 402.

[3] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 70–71.

[4] Шунда ук. Б. 87–91.

Юныс пәйгамбәргә, бу кавем өстенә газап җибәрәчәкмен, дип кисәтә. Юныс пәйгамбәр бу кавемгә газап килсә, мин болар арасында калып үзем зыян күрермен дип, бу җирдән китә. Аллаһ болар өстенә ут җибәргәч, бу халык куркып Юныс пәйгамбәрне эзли башлый, ләкин тапмый һәм һәлак була. Юныс пәйгамбәр үзе өчен куркып халкын ташлап киткән өчен Аллаһ аны җәзалый: аны бер балык йота һәм ул берничә көн шул балык карынында яши. Соңыннан гөнаһысы өчен тәүбә кылгач, Аллаһ аның тәүбәсен кабул итә һәм балык карыныннан чыгара[1].

Ләкин бу риваять яки кыйсса югарыда китерелгән кыйссалардан аерыла. Юныс кавеме үзләре теләп көферлектә була, аларны беркем дә иман китерүдән тыймый. Шуңа күрә аларны ташлап китү зур җинаять булып санала. Юныс пәйгамбәр ниндидер залим патшадан качып китми, ә Аллаһы Тәгаләнең тиздән җибәрәчәк газабыннан кача. Шуның өчен дә автор аны тәнкыйтьли.

Безнеңчә, Юныс пәйгамбәр турындагы кыйсса чукындырылган керәшен татарларын башка мөселман татарларының кире үз диннәренә әйләнеп кайтырга чакырмавына, газаптан куркып, ташлап китүләренә аллегориядер.

Тарихтан белүебезчә, татарларны көчләп чукындыргач, керәшен татарлары барлыкка килә. Аларны башка татарлардан аерып, аерым бер керәшен авыллары ясыйлар. Әдип аларны ташларга ярамый, киресенчә, рус чиркәвенең дин буенча эзәрлекләвенә карамыйча, аларны кире үз иманнарына чакырырга, үгетләргә кирәк, дип белдерә. Әгәр дә татар халкы аларны ташласа, мөртәдләр, дип кире какса, Аллаһы Тәгалә каршында зур гөнаһлы булалар һәм, балык карынына эләккән кебек, азатлыкларын югалтачаклар, дип әйтергә тели.

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 40–43.

Юныс пәйгамбәрнең вакыйгасы да Коръәндә китерелә: «Юнысны да хәтерләгез, ачуланып кавеменнән аерылып китте, ул уйлады: кавемен ташлап киткән өчен аңа Безнең хөкем булмас, дип. Ул караңгыда яки балык эчендә дога кылып әйтте: “Йә, Аллаһ, синнән башка һич Илаһ юк, мәгәр Син генә, Сине һәр кимчелектән пакь дип беләмен, Синең рөхсәтеңнән башка кавемемне ташлап китүем белән үземә золым итүчеләрдән булдым”» («Әнбия» («Пәйгамбәрләр») сүрәсе, 87 нче аять).

«Сиражел-колүб» әсәрендә Зөлкифел турындагы бүлектә өч бертуган хакындагы кыйсса бик кызыклы. Бу өч бертуганның икесе бик изге кеше, ә өченчесе түрә була. Шул түрә хакимлек иткәндә бик яман эшләр эшли, гадел булмый, бик күп гөнаһлар җыя. Соңыннан ул тәүбә итәргә уйлый һәм туганнарыннан: «Аллаһ мине кичерерме икән?», – дип сорый. Карендәшләре: «Алай түгел, кеше күпме генә гөнаһ кылса да, тәүбә ишекләре ябылмый»,– дип әйтәләр. Ул түрә бер карендәшенә фәлән җирдә торучы бер заһид янына барып, Аллаһ тәүбәмне кабул итәрме икән, дип сорап кайтырга куша. Тегесе барып сорый, заһид: «Һичшиксез, Аллаһның рәхмәте киң, кичерер», – ди. Түрә карендәшеннән, шул заһид язмача язып җибәрсен, дип сорый. Ул заһид аңа язмача «Аллаһ сине кичерер», – дип язып җибәрә. Шуннан соң бу түрә шул заһидкә барып хезмәт итә. Соңыннан икенче бер заһид янында яши. Заһид үлгәч аның кабере өстендә бер хат пәйда була. Анда: «Әй заһид, мин түрәне ярлыкадым, аңа оҗмах насыйп иттем», – дип язылган була[1].

Бу түрә образы аша Шаһ Гали бирелергә мөмкин. Бу турыда Мәсгут Гайнетдинов та язып чыга[2]. Шаһ Гали, беренчедән,

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 76–79.

[2] Гайнетдинов М.В. «Сирадж ал-кулюб» // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). Казань: ФЭН, 1999. С. 144.

түрә була, ягъни Казан ханлыгы, Касыйм ханлыгы белән идарә итә; икенчедән, бик күп яман эшләр кыла. Ул үз туган иленең иминлеге өчен бөтенләй көрәшми, киресенчә, рус хөкүмәтенең бер ялчысы, куштаны була. Татар халкы аңа бик каты рәнҗи. Сөембикә ханбикәне көчләп хатынлыкка алып, ул аны рәнҗетеп, мыскыл итеп яши. Шаһ Галинең хыянәтен, татар халкына китергән зыянын санап бетергесез. Ләкин күпме генә гөнаһлар, яман эшләр кылса да, автор аны иманга, изгелеккә, тәүбә итәргә чакыра. Әгәр ул чын күңелдән тәүбә итсә, Аллаһы Тәгалә аны кичерер, ярлыкар, дигән фикер әйтә, ялгышлыкларын төзәтер өчен форсат биреп, аңа әсәрдәге түрә үрнәгенә иярергә куша кебек.

Аднаш хафиз әсәрендә күтәрелгән проблемаларның тагын берсе – кеше хакына керү. Бу исә ашъяулык иңү турындагы риваятьтә чагыла. Гайсә галәйсһиссәлам үз кавемен ураза тотарга чакыра һәм, моны эшләсәгез, Аллаһы Тәгалә сезгә теләгәнегезне бирер, дип вәгъдә итә. Болар утыз көн ураза тоткач, Гайсәдән Аллаһы Тәгаләнең ашамлык белән ашъяулык җибәрүен сорыйлар. Гайсә дога кыла һәм Аллаһы Тәгалә күктән ашъяулык иңдерә, ләкин кисәтә: «Әгәр дә моннан соң көферлек кылсагыз, бик каты газаплармын». Ашъяулык иңгәч, Гайсә кавеме куркудан ашаудан баш тарталар. Гайсә дәрвиш-мескеннәрне чакыртып, аларны ашата. Икенче көнне тагын ашъяулык иңгәч, Гайсә шарт куя: «Бүген тагын дәрвишләр, мескеннәр ашасыннар, иртәгә сез – байлар ашарсыз». Ләкин аның кавеме риза булмый, Гайсәне сихерче дип атап, көферлек кылалар. Иртән торсалар, алар дуңгызлар һәм маймыллар рәвешенә кергән булалар. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә аларны хурлыкка төшереп һәлак итә[1].

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 64–67.

Әлбәттә, автор бу риваятьне юкка гына китермәгән, монда да үзе яшәгән чор белән тиңдәшлек бар. Тарихтан белүебезчә, Казан ханлыгы басып алынгач, татарларның җирләре талап алына, аларның хакларына керәләр, хәтта хатыннарын һәм балаларын тартып алалар, ирләрне шәһәрдән куып тараталар.

«Мәскәү хөкүмәте илне тиз генә руслаштыру өчен алпавытлардан качып килүче рус крестьяннарын да тотмады, гайре рәсми булса да, Казан җиренә килеп утырырга мөсәгадә бирде. XVI гасырның ахырында бу рус крестьянының килүе шулкадәр күбәйде ки, Мәскәү өлкәсендә җирләр бушап кала башладылар, алпавыт кулындагы җирләр, эшче кулы булмаганга, игелми кала башладылар. Хәтта хөкүмәт бу Казан өлкәсенә качып, гайре монтазам килүчеләрне тыярга чаралар кыла башлады.

Хөкүмәт Казан өлкәсен тизрәк колонизация ясау өчен башта бөтен мәгъюб кешеләрне вә сәяси мөттәһәм кешеләрне шунда сөрә башлады»[1].

Риваятьтә юкка гына Гайсә кавеме дип күрсәтелми. Рус христианнары да үзләрен Гайсә кавеменнән дип саныйлар. Шуңа күрә әсәрдәге рус христианнары, Гайсә кавеме кебек үк, мескен татарларның өлешләренә, хакларына керәләр. Гайсә кавеме дуңгызлар һәм маймылларга әверелеп һәлак булганга күрә, әдип тә залим рус миссионерларының, әгәр дә золымлыкларыннан туктамасалар, хурлыклы рәвештә һәлак булачакларына ышандырырга тырыша.

Бу кыйсса Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» әсәрендә дә китерелә. Аның сюжеты нәкъ «Сираҗел-колүб» әсәрендәге кебек. Ләкин кайбер детальләрдә аермалар күзәтелә. «Сираҗел-колүб» әсәрендә ашъяулыкның ике көн иңгәнлеге әйтелә. Беренче көнне байлар, куркып, ашъяулыктан ризыклар ашамыйлар,

---

[1] Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда. Сайланма хезмәтләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 154–155.

фәкать фәкыйрьләр, дәрвишләр генә ашый. Икенче көнне Гайсә галәйһиссәлам тагын фәкыйрьләр ашасын дип боера, байларга иртәгә ашарсыз дип вәгъдә бирә. Байлар моңа риза булмыйча көферлеккә чыгалар[1].

«Кыйссасел-әнбия» әсәрендә ашъяулык кырык көн иңә. Андагы ризыкларны байлар да, фәкыйрьләр дә ашый. Кырык көн иңгәч, Аллаһ әйтә: «Инде фәкать фәкыйрьләр, авырулар гына ашасын, байлар, сәламәт кешеләр ашамасын!» Шуннан соң байлар, моңа риза булмыйча, каршы чыкканнары өчен дуңгызларга һәм маймылларга әйләндерeләләр. Бу эштән куркып фәкыйрьләр дә: «Йә, Гайсә, башка маидә (*ашъяулык*) иңмәсен, алайса үзебез дә гөнаһка төшәрбез», – дип, Гайсә пәйгамбәрдән ашъяулык иңүен туктатуны сорыйлар[2].

Аднаш хафиз, Рабгузыйдан аермалы буларак, маидә фәкыйрьләр соравы буенча түгел, ә байларның көферлекләре сәбәпле туктавын искәртә. Димәк, халыкның бер өлеше көферлек кылса, Аллаһы Тәгалә алар өчен бөтен халыкны да үзенең рәхмәтеннән башка калдыра ала дигән фикерне уздыра. Шул рәвешле әдип көферлекнең никадәр куркыныч икәнен һәм аның аянычлы нәтиҗәләрен күрсәтергә тели.

Аллаһы Тәгаләнең гаделсез, залим, денсез кешеләрне бу дөньяда, һичшиксез, юк итәчәге, аларга җәза бирәчәге икәне әсәрдә кат-кат искәртелә. Шул ук ашъяулык турындагы риваять моңа дәлил булып тора. Шулай ук, дөньяда үз җәннәтен ясап кешеләрне көферлеккә чакырган Шәдәд бине Гадәне Аллаһы Тәгалә һәлак итә[3]. Җирҗис пәйгамбәргә инанмаган

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 66–67.

[2] Рабгузый Б. Кыйсасел-әнбия. Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Дом печати, 2003. Б. 313.

[3] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 96–101.

патша да, Габдулланы үтергән мәлик тә Аллаһ тарафыннан юк ителәләр. Моңа өстәп, тагын тәкәбберлеге белән бер зур бина салдырган Фиргавеннең һәлак ителүен дә китерергә мөмкин. Ул, масаеп, Мусаның Раббысын күктә күрим әле, дип, зур бина төзетергә куша. Илле мең кеше тырышып эшлиләр һәм җиде елдан төзеп тә бетерәләр. Ул бина түбәндәге болытлардан да биегрәк була, Фиргавен хәтта өскә таба аты белән генә менә ала. Муса Аллаһтан бу бинаны җимерергә дога кылып сорый һәм Җәбраил фәрештә, канаты белән бәреп, бинаны өч өлешкә бүлә һәм өч якка туздырып ата. Фиргавен һәм бу бинаны төзүчеләрне Аллаһ утта көйдереп үтерә[1]. Нух пәйгамбәргә инанмаган халыкны да Аллаһ туфан суы белән батырып һәлак итә[2].

Аднаш хафиз үзенең әсәрендә Аллаһның бөеклеген, кодрәтен кат-кат искәртеп тора. Һәр бүлектә Аллаһы Тәгалә бөтен эшкә кадир, җиңелмәс, гадел, рәхимле, шәфкатьле, бөек, бөтен нәрсәне белүче, күрүче, ишетүче, мөэминнәргә булышучы, кяферләрне һәлак итүче зат буларак тасвирлана. Аллаһы Тәгаләнең безгә билгеле булган бөтен туксан тугыз исеме һәм сыйфаты «Сиражел-колүб» әсәрендә чагыла, дип әйтергә мөмкин. Ләкин автор Аллаһның мөэминнәргә һәрвакыт булышуы сыйфатына күбрәк басым ясый. Бу, әлбәттә, шул чорның вакыйгалары белән бәйле. Аллаһы Тәгаләнең мөэминнәргә ни рәвешле булышуына килгәндә, ул Аның төрле могҗизалар, кәрамәтләр күрсәтүендә чагыла. Әсәрнең күп өлеше Аллаһның пәйгамбәрләргә, мөэминнәргә төрле могҗизалар күрсәтеп булышуына багышланган. Мәсәлән, Муса пәйгамбәргә кирәк чакта еланга әверелә торган могҗизалы таяк, эченнән су чыга торган таш бирелүе, Салих пәйгамбәр өчен таштан дөянең бар-

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 92–94.

[2] Шунда ук. Б. 89–91.

лыкка килүе, Ибраһим пәйгамбәргә күктән сарык төшүе, Гайсә пәйгамбәрнең ана карынында һәм бишектә сөйләшүе, Җүрәйҗ заһидның ана карынындагы баланы сөйләштерүе, Адәм, Идрис, Гайсә, Һарун, Мөхәммәд пәйгамбәрләрнең күккә ашулары, Адәм белән Хәвваның юктан бар кылынулары, чыннан да, зур могҗизалар булып саналалар.

Автор «Сиражел-колүб» әсәрендә, мөселманнарны Аллаһы Тәгалә һәрвакыт үзенең яклавы астына алачак, дигән идеяне күтәреп чыга. Иманын сакларга тырышкан кешене Аллаһ та явыз бәндәләрдән һәрвакыт саклый дип, ул мисал итеп пәйгамбәрләр, изгеләр белән булган төрле вакыйгаларны, риваятьләрне китерә.

Мөселман кеше һәрвакыт Аллаһның саклавын тойсын өчен Аднаш хафиз Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләрне искә ала. Әсәрдә китерелгән риваять буенча, бу ике пәйгамбәр белмичә тереклек суы эчәләр һәм дөньяда кыяматкә хәтле үлмичә яши башлыйлар. Хозыр пәйгамбәр дәрьяларда йөрүчеләргә булыша, төрле куркынычлардан саклый, ә Ильяс пәйгамбәр кырларда, болыннарда йөрүчеләргә булыша, адашканнарга юл күрсәтә, ачыккан һәм сусаган кешеләргә ризык һәм су бирә. Шул ук вакытта әдип кайбер галимнәрнең, Ильяс пәйгамбәр күктә гыйбадәт кылып тора, дигән фикерен дә әйтеп уза[1]. Димәк, Аднаш хафиз төрле дин галимнәренең фикерләрен куллана һәм, нәрсә турында гына сөйләсә дә, аның турында бөтен мәгълүматларны, фикер каршылыкларын бирергә тырыша. Бу исә аның бер якны гына кабул итеп, икенче якны санга сукмау кебек сыйфатлардан азат икәнен күрсәтә. Чөнки күп кенә әдипләрнең күптөрле фикерләр арасыннан үзләренә охшаганын гына сайлап алып, башкаларны да үз фикеренә иярттергә тырышу очраклары аз түгел. Әдип бик күп җирләрдә «бәгъды

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 70.

бер гуләмаләр болай әйтә, бәгъды гуләмаләр тегеләй әйтә» дип яза. Мәсәлән, Локман, Зөлкифел, Хозыр, Ильяс, Һарун хакында аларның пәйгамбәрме яки түгелме, дигән сорауга дин галимнәренең төрле карашларын тәкъдим итә[1].

Автор берничә тапкыр Муса пәйгамбәрнең таягын искә алып уза. Муса таягы – дошманнарны җиңә торган тылсымлы корал буларак сурәтләнә. Шулай ук Дауд пәйгамбәрнең каш балдагы да искә алына. Бу исә шәрык әдәбиятында хакимлек символы булып санала. Димәк, Аллаһы Тәгалә үзенең сөйгән бәндәләренә төрле тылсымлы әйберләр биреп, аларны дошманнарын җиңүгә ирештерә. Шул ук вакытта, хакимлеккә ирешер өчен, бу тылсымлы әйберләргә хаксыз ия булырга теләгән кеше һәлак булачак икәнлеге дә күрсәтелә. Бу Булкыя турындагы риваятьтә чагыла. Гаффан исемле кеше, бөтен галәмне үзенә буйсындыру өчен, хәйлә белән Сөләйман пәйгамбәрнең дәрьядагы каберенә барып, аның кулыннан йөзеген салдырып алмакчы була, ләкин Аллаһы Тәгалә аны ут белән көйдереп һәлак итә[2].

Димәк, кешедә изге ният (Аллаһ диненә чакыру һ.б.) булганда гына Аллаһы Тәгалә аны үз саклавы астына ала; әгәр дә башка начар ният (хакимлек, байлык алу һ.б.) булса, ул кешене Аллаһы Тәгалә сакламас, ә, киресенчә, һәлак итәр, дигән фикер әйтелә.

«Сиражел-колүб» әсәрендә кяферләрне, залимнәрне каргаган, нәфрәт утына тоткан урыннар да бар. Бу, әлбәттә, халыкны рәнҗеткән рус гаскәрләренә карата әйтелгән сүзләр булса кирәк. Аднаш хафиз аларны үзе турыдан-туры каргамый, ә бик оста итеп яшереп, киная рәвешендә, төрле хайваннар сүзләре аркылы бирә. Рус чиркәве моны сизмәсен, аңламасын

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 75–76.

[2] Шунда ук. Б. 110.

өчен ул аларны гарәп телендә яза һәм хәтта татар теленә тәрҗемә дә итми. Әдип фикеренчә, ишәк бакырганда һәрвакыт: «Ләгънәтуллаһи галәз-залимин», – дип әйтә икән[1]. Гарәп теленнән татар теленә тәрҗемә иткәндә: «Залимнәргә Аллаһның ләгънәте булсын!» – дигән сүзләр килеп чыга. Эт өргәндә: «Аллаһүммәгъриз вөҗүһәш-шәйтанә ганил-мөслимин», – дип әйтә[2]. Ягъни: «Йә, Аллаһ, мөселманнарны шайтаннардан сакла!» Әдип монда «шайтаннар» дип дошманнарны атарга мөмкин, чөнки алар шайтаннар кебек мөселманнарның иманнарын тартып алырга тырышканнар. Ат кешнәгәндә: «Аллаһүммәнсур гыйбадәкәл-мөэмининә галәл-кәфирин», – дип әйтер[3]. Тәрҗемәсе: «Йә, Аллаһ, үзеңнең мөэмин колларыңа кяферләрне җиңәргә ярдәм ит!»

Мөселман өйрәтүләре буенча, хайваннар, кошлар, бөҗәкләр – барысы да Аллаһы Тәгаләгә зикерләр, тәсбихләр, мактау сүзләре әйтәләр. Бу Коръәндә һәм хәдисләрдә ачык чагыла. Ләкин алардан һәрбер төр хайванның нинди сүзләр әйткәнлеге хакында бернинди мәгълүмат килми. Аднаш хафиз исә үзенең әсәрендә һәрбер төр хайваннарның үзләренә генә хас тәсбихләре һәм зикерләре барлыгын һәм алар нидән гыйбарәт икәнлеген яза. Ул, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, үзенең дошманнарына мөнәсәбәтен белдерү өчен яңа ысул уйлап таба. Бу – үз мөнәсәбәтеңне кайбер хайваннарның сүзләре аша бирү. Шул ук вакытта ул бу сүзләрне гарәп телендә бирә. Чөнки татар телендә турыдан-туры белдерсә, әйткәнебезчә, рус чиркәве аның әсәрен юк итәр иде һәм халык арасында таралуына чик куяр иде.

Шундый оста ысул белән Аднаш хафиз дошманнарына карата үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдергән. Хәтта хайван-

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 114.

[2] Шунда ук. Б. 113–114.

[3] Шунда ук. Б. 113

нар да кяферләргә карата шундый тискәре мөнәсәбәттә булгач, кешеләрнең аларга карата нинди мөнәсәбәттә булырга кирәклеге көн кебек ачык. Бу Аднаш хафизның ни дәрәҗәдә тапкыр, хикмәт иясе икәнлеген тагын бер кат раслый.

Автор, берникадәр, ата-ана һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә тукталып уза. Гадәттә, барлык дәвер әдипләре дә үз әсәрләрендә бу мәсьәләне кузгатмый калмыйлар. Аллаһы Тәгаләнең Коръәндә анага яхшылык кылу белән боерган аятьләре дә аз түгел:

«Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһуны гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек кылырга. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга: “Уф!” та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак, вә мөлаем сүзләр сөйлә! Вә аларга шәфкать итеп, рәхим канатларыңны җәй! Вә әйт: “Ий, Раббым, алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл!”» («Бәни Исраил» («Ягъкуб балалары») сүрәсе, 23–24 нче аятьләр).

Бу турыда хәдисләр дә байтак:

«Хатыннарына карата ирләренең хакы олы, балаларына карата аналарының хакы олы» (137 нче хәдис)[1].

«Җәннәт аналарның аяк астында» (377 нче хәдис)[2].

Аднаш хафиз ана һәм бала арасындагы мөнәсәбәт хакында түбәндәге риваятьне китерә:

Көннәрдән бер көнне Җүрәйҗ исемле заһид янына анасы килә һәм өенә кермичә генә тыштан улын чакыра. Җүрәйҗнең намаз укыган вакыты була һәм, намазын бозарга теләмичә, анасына җавап бирми. Анасы аңа үпкәли, рәнҗи һәм: «Хак Тәгалә сине яман хатын белән түбәнсетсен», – дип каргап

[1] Мең дә бер хәдис. Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2003. Б. 17.

[2] Шунда ук. Б. 41.

китә. Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итә. Ул шәһәрдәге бер явыз хатын заһидның йорты янында көтүче белән зина кыла һәм балага уза. Аны патша янына тотып алып киләләр һәм җәзаламакчы булалар. Бу хатын: «Мин Җүрәйҗ заһид белән зина кылдым», – ди. Җүрәйҗне тотып алып киләләр һәм зина кылуда гаеплиләр. Ул анасы янына алып баруларын үтенә. Аны алып баралар һәм ул анасыннан гафу үтенә һәм ни өчен теге вакытта җавап бирмәгәнен аңлата. Анасы Җүрәйҗне гафу итә һәм аның өчен дога кыла. Җүрәйҗ теге зиначы хатынның карынына кулын куеп: «Әй, сабый, синең атаң кем?» – дип сорый. Ана карынындагы бала телгә килеп: «Минем анам бер көтүче белән зина кылды, минем атам шул көтүче», – дип җавап бирә. Барча халык моңа шакката һәм Җүрәйҗнең гаепсезлеген аңлыйлар[1].

Бу риваятьтән аңлашылганча, әдип ана хакын сакларга, аңа изгелек кылырга, хезмәт күрсәтергә, хөрмәт итәргә, һәр эштә ризалык алырга, каршы сүз әйтмәскә, үгет-нәсыйхәтләренә колак салырга, берничек тә рәнҗетмәскә, ни кушса – шуны эшләргә, аның рөхсәтеннән башка берни эшләмәскә чакыра. Аднаш хафизның өйрәтүләре бүгенге көндә дә бик актуаль яңгырыйлар. Бала анасын рәнҗетсә, аның Хак Тәгалә каршында кылган догалары да кабул булмый, дип искәртә автор. Аның бу фикерләре беркайчан да әһәмиятен югалтмаячак.

Аднаш хафизга кадәр иҗат иткән әдипләр дә бу теманы яктыртмыйча калмаганнар. Һәрберсенең әсәрләрендә ата-анага карата яхшы мөгамәләдә булырга чакыручы үгет-нәсыйхәтләрне табарга мөмкин. Мәсәлән, Мәхмүд әл-Болгари «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә ата-анага изгелек кылу турында махсус бер баб яза. Ул аларга изгелек кылуның савабы намаз

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 71–72.

уку, ураза тоту, хаҗ кылу савабыннан да артык торыр, ди[1]. Шулай ук аларга «уф» дияргә дә ярамаганлыкны, күпме генә хезмәт итсәң дә, хакларын кайтара алмауны ассызыклый[2]. Мәхмүд әл-Болгари моңа карата бик күп хәдисләр китерә. Бер хәдистә түбәндәгечә сөйләнелә: «Йәмән иленнән Мөхәммәд пәйгамбәр янына бер кеше килә һәм җиһадка барырга теләген белдерә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам аннан: "Синең ата-анаң бармы?" – дип сорый. Теге: "Бар", – дип җавап бирә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: "Алар сиңа җиһадка барырга ризалык бирделәрме?" – дип сорый. Теге кеше: «Юк, ризалык бирмәделәр», – дип җавап бирә. Шунда Мөхәммәд пәйгамбәр: "Алайса, бар, аларга хезмәт ит, чөнки ата-анага хезмәт итү савабына бернәрсә дә җитмәс", – дип әйтә»[3].

Әле бу гына түгел, Мәхмүд әл-Болгари, ата-анасына хезмәт кылган кеше күпме генә гөнаһ кылса да, беркайчан тәмугка кермәс һәм ата-анасын рәнҗеткән кеше, күпме генә гыйбадәт кылса да, һичкайчан оҗмахка кермәс, ди[4].

Аднаш хафиз заманында, иманга куркыныч янаган вакытта, бер кеше дә, бер әдип тә Мәхмүд әл-Болгари кебек сүзләр әйтә алмаган. Чөнки ата-анага хезмәт кылган кеше имансыз булса, ата-анасына күпме генә хезмәт кылса да, тәмугка керәчәк, дигән караш көчле була. Мәхмүд әл-Болгари фикеренчә, кеше җәннәткә иманлы булу сәбәпле түгел, ә ата-анасына хезмәт кылу сәбәпле кергән булып чыга. Шулай ук аныңча, ата-анасын рәнҗеткән кеше мәңге тәмугка кяфер булганы өчен түгел, ә ата-анасын рәнҗетү сәбәпле керә. Әгәр дә иманлы кеше ата-анасын рәнҗеткән өчен генә беркайчан

[1] Әл-Болгари М. Нәһҗел-фәрадис; әсәрне басмага әзерләүче, кереш мәкалә авторы Ф. Нуриева. Казан: Тат. кит. нәшр., 2002. Б. 235–236.

[2] Шунда ук. Б. 236–237.

[3] Шунда ук. Б. 241.

[4] Шунда ук. Б. 237.

да оҗмахка керә алмагач, иманлы, динле булуның бернинди мәгънәсе дә калмый. Шуңа күрә Аднаш хафизның, имансыз кеше ата-анасына изгелек кылу белән генә җәннәткә керә алмаячак, дигән фикерен бик ачык абайларга мөмкин.

Мәхмүд әл-Болгари, ата-анага изгелек кылу намаз уку һәм башка гыйбадәтләрдән саваплырак, дип язса, Аднаш хафиз, киресенчә, намаз уку кебек зур гыйбадәтләргә бернәрсә дә җитә алмый, дип саный. Чөнки Җүрәйҗнең анасы улының намаз уку сәбәпле аңа җавап бирә алмаганын белгәч, аны шунда ук кичерә һәм бик күп яхшы теләкләр теләп дога кыла. Намаз уку Аллаһы Тәгалә хакы булганлыктан, бу хак башка кешеләрнең хакларыннан өстен торуын искәртә автор.

Аднаш хафиз гаделлек проблемасына да туктала. Сөләйман пәйгамбәр образы аша ул гадел патша нинди булырга тиеш икәнлеген күрсәтә. Сөләйман галәйһиссәлам никадәр байлыкка, хакимлеккә ия булса да, гөнаһка төшмичә, беркемне дә рәнҗетмичә, бик гадел яши. Ул кешеләргә карата гына түгел, хәтта кырмыска кебек күзгә ташланмый торган бөҗәкләргә карата да шәфкатьле. Бу исә Сөләйман пәйгамбәр һәм кырмыска турындагы риваятьтә чагыла. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгечә:

Бервакыт Сөләйман үзенең гаскәре белән юлдан барганда кырмыска оясына тап булалалар. Аларның патшасы башка кырмыскаларга: «Сезне Сөләйман һәм аның гаскәре таптап харап итмәсен өчен, тизрәк ояларыгызга керегез!» – дип кычкыра. Сөләйман пәйгамбәр аның сүзләрен ишетә һәм үз янына чакыртып: «Әй, кырмыска, син мине залим дип уйлыйсыңмы әллә, минем гаскәрем ничек итеп синең кырмыскаларыңны таптасыннар?» – дип сорый. Кырмыска: «Син – пәйгамбәр һәм гадел, гаделлек өчен йөрерсең. Мин сезнең гаделлегегезне аларга һәрвакыт сөйлим. Аларны тапталмасыннар өчен түгел, бәлки сезне күреп гыйбадәтләрен калдырмасын-

нар өчен кисәттем», – дип җавап бирә. Соңыннан Сөләйман галәйһиссәлам кырмыскадан үгет-нәсыйхәт бирүен үтенә. Кырмыска сорый: «Синең исемең нәрсә аңлатканын беләсеңме?» Сөләйман галәйһиссәлам: «Әйт», – ди. Кырмыска әйтә: «Синең исемең Сөләйман – сәламәт кеше, дигәнне аңлата, зинһар, исемең фигылеңә туры килмичә калмасын. Йә, Аллаһ пәйгамбәре, ничә мең гаскәрне үзең белән йөртәсең, зинһар, гаскәреңә ышанма, Аллаһка тәвәккәл кыл. Дөнья милкенә ышанма, ахирәтеңне онытма!»

Шул рәвешле, чиксез хакимияткә, байлыкка ия булуына да карамастан, Сөләйман пәйгамбәр, гаскәрен юлдан туктатып, кечкенә, көчсез бер кырмыска белән үз тиңедәй күреп сөйләшергә вакыт таба, хәтта аннан үгет-нәсыйхәт кылуын үтенә. Аднаш хафиз бөек затларны кодрәт, дәрәҗә, байлык ягыннан үзләреннән түбәндәрәк торучыларга кечелекле, ихтирамлы булырга, аларны кимсетмәскә, масаймаска, үгет-нәсыйхәтләр алырга чирканмаска чакыра. Шулай ук кырмысканың әйткән нәсыйхәтеннән аңлашылганча, дөнья байлыгына ышанмаска, ахирәтне онытмаска һәм иң мөһиме – гаскәреңнең көченә ышанмыйча, фәкать бер Аллаһы Тәгаләгә генә тәвәккәл кылырга, бөтен эшләреңне бары тик Аңа гына тапшырырга кирәк икәнлеге аңлашыла. Чөнки гаскәр саны бик күп булса да, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәллек булмаса, аз санлы дошман гаскәре җиңәргә мөмкин.

Дөньяви әдәбиятта кырмыска һәм Сөләйман образларының нисбәте, башлыча, алар арасындагы физик һәм социаль контрастка нигезләнгән. Шундый мотив татар халкының тарихи-этик дастаны «Идегәй»дә дә урын алганын Х.Ш. Мәхмүтов искәртеп уза. «Әсәрдә Туктамыш хан һәм Идегәй улы Нурадын бергә-бер орышу алдыннан, борынгы батырлар йоласы буенча, әүвәл «тел кылычлары»н чәкештереп алалар. Туктамыш Нурадын алдында Чыңгыз нәселеннән килгән хан

булуы белән һавалана, аны «Син минем колымсың», дип мәсхәрәли. Ләкин баһадир егет ханны бик тиз үз урынына утырта:

Анда әйтте Норадын:
– Мин бер колың түгелмен,
Син дә Чыңгыз түгелсең.
Мин кырмыска булып та,
Син Сөләйман түгелсең!

Ислам чыганакларында кырмыска белән Сөләйманның каршы куелышы рухани-әхлакый яссылыкта да эшләнә. Кырмыска гаять куәтле гаскәр якынлашуын күргәч, үз кавеменә җир астына качарга куша, әмма бу Сөләйман алдында калтырап төшү галәмәте түгел, ә кырмыскаларның Аллаһны зикер итүләренә зыян килмәсен дип борчылу. Чөнки бөекләрнең дә иң бөеге – Хак Тәгалә!»[1]

Гомумән, автор китергән пәйгамбәрләр, изгеләр турында дини хикәятләрдәге образларда, гыйбрәтләрдә, кешелекнең меңнәрчә ел дәвамында сыналган, тупланган тәҗрибәсе гәүдәләнә. Алар һәркемгә аңлаешлы ориентирлар, гамәл кыйбласы һәм кисәтү булып торалар[2].

Шулай итеп, бу бүлектә Аднаш хафизның иманны саклап калу юлларын тикшердек, ул күтәреп чыккан проблемаларны, мәсьәләләрне ачыкладык, һәрберсенә аерым-аерым тукталдык. Автор күтәреп чыккан проблемалар һәм мәсьәләләр үз чоры өчен дә, аннан соң да әһәмиятләрен җуймыйлар. Аднаш хафиз үз заманының бурычларын яхшы аңлаган, мөһим булган мәсьәләләрне күтәргән. XVI гасырда татарларны

---

[1] Мәхмүтов Х.Ш. Акмулла шигырьләрендә мәкальләр һәм канатлы гыйбарәләр // Акмулла һәм хәзерге заман: мәкаләләр җыентыгы. Казан, 2007. Б. 161–162.

[2] Хисамов Н.Ш. Урта гасыр әдәбиятын өйрәнүнең принципиаль мәсьәләләре // Хәтер сагында: әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. Казан: Мәгариф, 2004. Б. 65.

колониаль изү, христианлаштыру сәясәте башланып китүгә үк, ул тиз арада, беренчеләрдән булып, халыкка акыллы киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен бирә. Аның өстенлеге менә шунда чагыла.

## 1.4. Әсәрдә суфичылык мотивлары

«Сиражел-колүб» әсәре тулаем суфичылык әдәбияты үрнәге булмаса да, аның шактый өлеше суфичылык тәгълиматына, риваять һәм легендаларына нигезләнеп язылган. Аның шундый характерда булуы исеменнән үк күренә. Ләкин монда көтелмәгән бернәрсә дә юк: әдип шәригать кысаларыннан читкә чыкмый. Аның суфилыгы шәригать кануннарыннан өстә торган суфилык түгел. Суфичылыгында да беренче чыганак булып Коръән һәм хәдисләр, соңыннан гына суфиларның төрле әсәрләре, мифологиясе тора. Шуңа күрә, аның суфилыгы белән танышканда, бернинди чит күренешкә тап булмыйсың.

Гомумән, Урта Азиядән килгән суфичылык фәлсәфәсендә, гарәп һәм төрек суфичылыгыннан аермалы буларак, рәсми исламга каршы чыгу рухы юк дәрәҗәсендә. Идел буендагы мөтәсаувифлар һичбер вакыт мөселман руханилары тарафыннан куылуга, дошманлыкка дучар булмыйча, киресенчә, халык арасында суфи кеше үзенең диндарлыгы, Аллага ныклы тугрылыгы белән аеруча хөрмәт казанган. Гасырлар буена Идел буе татарлары тормышында ислам белән тәсаувиф һәрвакыт диярлек мөселман руханилары өчен христиан миссионерларына каршы көрәштә зур ярдәмче көч булып хезмәт итте[1].

Авторның дәрвишләргә, заһидләргә карата мәхәббәте һәм хөрмәте зур. Шулай ук аның зөһедлеккә (аскетизм) чакыруын,

---

[1] Сибгатуллина Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык: чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре: филол. фән. док. дис. Алабуга, 2000. Б. 72.

бу дөнья артыннан кумаска, дөнья байлыкларына кызыкмаска дигән фикерләрен бик ачык абайларга мөмкин. Галәмнең яратылышын сурәтләгәндә дә автор суфичылык күзлегеннән сурәтли. Бу дәлилләр Аднаш хафизның суфилар тәгълиматын яхшы белгәнлеген күрсәтә. Язучы дәрвишләргә, заһидләргә соклана, аларны мактый. Мәсәлән, «Зөлкифел пәйгамбәрме, йә юкмы?» дигән бүлектә бер түрә турында хикәя китерелә. Ул түрә, явыз эшләр кылганнан соң, тәүбәгә килергә уйлый һәм карендәшеннән фәлән җирдә яшәүче бер заһид янына барып: «Аллаһ мине хәзер ярлыкармы?» – дип сорап кайтырга куша. Карендәше заһиднең: «Аллаһ сине ярлыкар!» – дип әйткәнен җиткерә һәм бу түрә шул заһид янына барып аның мөриде була, заһидкә хезмәт итә, бергә гыйбадәт кылалар.

Нинди дә булса тәкъвалыгы, заһидлеге белән билгеле булган кеше (ишан) янына барып аңа хезмәт итү – суфилар арасында бик киң таралган күренеш. Кеше әгәр дә суфи булырга тели икән, ул башта ишанга барып, аның мөриде булып, аңа хезмәт итәргә тиеш. «Рәсми исламнан аермалы буларак, суфичылык, мөселманның Аллаһ белән бәйләнешкә керүенә ярдәм итүче арадашчы булуны күздә тота. Бу – «мөршиде камил», ягъни камиллек дәрәҗәсенә ирешкән, Аллаһы Тәгаләнең һәм Рәсүлулланың әхлагы кебек әхлаклы тарикать җитәкчесе, мөршид, пир, шәйх, остаз, ишан һ.б. (һәр тарикать үз җитәкчесен үзенчә атый). Суфи булырга теләгән кеше, ягъни мөршид, үз теләге белән тарикать төрен һәм җитәкчесен сайлый»[1].

Әсәрдә Сөләйман пәйгамбәрне сурәтләгәндә аның бакчасында 70 михрабы бар икәне әйтелә. Һәр михрабында заһидләр, дәрвишләр ак тун киеп Ходай Тәгаләгә тәгать кылып уты-

---

[1] Сибгатуллина Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык: чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре: филол. фән. док. дис. Алабуга, 2000. Б. 90.

ралар. Ул заһидләрнең дәрәҗәләре шул кадәр иде, бармагы белән тауга ишарәт кылса, тау урыныннан куба[1].

Заһидләр, суфичылык өйрәтүләре буенча, төрле кәрамәтләр, могҗизалар эшли алалар. Әдип тә моңа басым ясый, аларның төрле могҗизалар эшли алуларын ассызыклый.

Аднаш хафиз зөһедлек (аскетизм), дөньядан ваз кичү хакында бик күп яза. Дауд пәйгамбәр турындагы хикәя тулысынча суфичылыкның төп нигезләренең берсе булган зөһедлеккә багышлана. Дауд пәйгамбәр үзенең бөтен улларын җыеп унөч сорау бирә һәм җавап бирә алучыны үзеннән соң патша итеп калдырырга вәгъдә итә. Уллары арасыннан фәкать Сөләйман галәйһиссәлам җавап бирә ала. Дауд пәйгамбәрнең сораулары, нигездә, зөһедлеккә кагыла. Алар түбәндәгечә (янәшәләрендә дөрес җаваплары да урнаштырылды):

«– Адәм угыллары эчендә иң аз нәрсә? – Якынлыктыр.

– Адәмнәр эчендә иң күп нәрсә? – Дөнья куу.

– Һәр нәрсәдән дә ачырак нәрсә? – Дәрвишлек һәм фәкыйрьлектер.

– Иң явыз кем? – Хатыннар.

– Иң ерак нәрсә? – Бу дөньядыр.

– Күктән дә биек нәрсә? – Падишаһларның гаделе.

– Дәрьядан тирән нәрсә? – Канәгатьтер.

– Таштан да катырак нәрсә? – Монафикълар күңеледер.

– Уттан да эссерәк нәрсә? – Хирыслык.

– Бу дөньяда үлек күпме, терекме? – Үлек күп, чөнки тереләр барысы да үләчәк.

– Дөньяда төзекме, вәйранмы күп? – Вәйран күп, чөнки төзекләр вәйран булачактыр.

– Ирме, хатынмы күп? – Хатын күп, чөнки хатыннар сүзе белән йөргән ирләр дә – хатындыр.

---

[1] Сиражел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 102–103.

– Таудан олуг нәрсә? – Ялган сүздер»[1].

«Мәликә китабы»нда да боларга охшаш кайбер сораулар телгә алына:

«– Гыймарәтме (*төзү*) күп, вәйранәме (*җимерү*) күп? – Вәйранә күп. Шуның өчен, чөнки барча гыймарәтләр вәйран булыр.

– Дөньяда үлекме, терекме күп? – Үлек күп торыр, чөнки барча терекләр үләчәк»[2].

Кайбер сорауларның җаваплары анда башка төрлерәк бирелә:

«– Дөньяда ачы ни торыр? – Юксыллык торыр.

– Дөньяда каты ни торыр? – Байлык торыр»[3].

Шулай ук «Мәликә китабы»нда мондый төр сораулар бик күп бирелгән. «Сираҗел-колүб» әсәрендә кайбер сорауларда аермалар булса да, кайберләре һәм аларның җаваплары бу әсәр белән тәңгәл килә.

Бу сорауларда суфичылыкның, аерым алганда, татар халкының тормыш фәлсәфәсе һәм тәҗрибәсе бирелгән. Алар «алтын сүзләр» буларак буыннан-буынга күчеп барган. Хәтта бүгенге көндә дә бу сорау-җаваплар актуаль булып калалар.

Гадәттә, Аднаш хафизга хәтле яшәп иҗат иткән әдипләрнең бөтенесе диярлек дөньядан читләшү темасын яктыртып уза. Мәсәлән, Мәхмүд әл-Болгари да «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә бу темага, бик киң тукталып, аерым бер баб багышлый. Аднаш хафиз да ислам һәм суфичылыктан алынган зөһедлек проблемасына тукталмыйча уза алмый һәм электән килгән бу традицияне башка әдипләр кебек үк дәвам итә.

---

[1] Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1864. Б. 101–102.

[2] Мәликә китабы / Китапны нәшер итү өчен әзерләүче Ш.Х. Зәбиров. Казан: Идел-пресс, 2002. Б. 23.

[3] Шунда ук. Б. 23.

## 2. XVII–XVIII ГАСЫРЛАРДАГЫ ТАТАР ӘДИПЛӘРЕ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ АДНАШ ХАФИЗ ӘСӘРЕ ПРОБЛЕМАЛАРЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Элеккедән килгән тәҗрибәне алу һәр сәнгать төре үсешенең мөһим факторы булып тора. Шул исәптән сүз сәнгатендә дә. Әдипнең чын оста булып җитешүенә, рухи һәм иҗади үсешенә, күп очракта, аның үзенә кадәр булган әдипләрнең тәҗрибәләре белән таныш булуы зур йогынты ясый. Элекке язма истәлекләр белән кызыксыну, үзе иҗатында үткән буыннар җыеп килгән тәҗрибәне куллану сүз сәнгатенең баетылуына һәм үсешенә дә китерә. Һәр әдип традицион темаларга мөрәҗәгать иткәндә, аларны үз максатларына буйсындырырга омтыла бит. Чын язучының һәм шагыйрьнең иҗатында элеккедән килгән иҗади тәҗрибә һәрвакыт аның индивидуаль стиле һәм концепциясе белән яраша. Икенче төрле әйткәндә, бөек әдип, элекке әдәби традицияләрне үзләштереп, һәрвакыт үзен оригиналь сүз остасы буларак таныта алачак[1].

Традиция (лат. tradition – тапшыру, сөйләү) – элеккеге, тарихи формалашкан һәм буыннан-буынга тапшырыла торган кыйммәтләр, идеаллар, үрнәкләр, нормалар, гадәтләр, ягъни яңа шартларда яшәвен дәвам итүче иҗтимагый-тарихи

---

[1] Маханова Р.Р. Творчество Суфи Аллаяра и его традиции в татарской литературе: дис. канд. ... филол. наук. Казань, 2008. С. 78.

тәҗрибә. Әдәбият белемендә аны «мәдәни хәтернең әдәбиятта чагылыш табуы» дип тә атыйлар. Әлеге чагылыш формалары төр һәм жанрларга, стильләргә бәйле һәм язылу вакытына карап аерыла.

Әдәбиятта күп кенә элементлар һәм алымнар, әдәби дөнья тудыру чаралары тотрыклы сакланып килә. Беренчедән, тел-сурәтләү чаралары һәм элеккеге текстлардан өзекләр куллану; икенчедән, дөньяга караш, концепция, идеяләр; өченчедән, әдәби формаларның тормыштагы аналоглары[1].

Гомуми һәм әдәби традицияләрнең бөтен рухи культураны баетудагы һәм үстерүдәге роле бик күп галимнәрнең хезмәтләрендә чагыла. Мәсәлән, А.Н. Веселовский фикеренчә, һәр яңа буын үткән буыннардан үз рухи тәҗрибәсенең сурәтләү алымнарын кабул итә[2]. Х.Й. Миңнегулов, гасырлар дәвамында сыналып килгән традицияләрне яңарту һәм үстерү милләтне саклап калуның мөһим шарты булып тора, дип яза[3].

Мәгълүм булганча, сүз осталарының элекке әдәби ядкарьләр белән кызыксынуы, элекке әдипләрнең иҗади тәҗрибәләрен үзләштерүе, теге яки бу традицияләрне алуы әдәби процессның нигезен тәшкил итә. Моннан шул аңлашыла: әдәби әсәрнең тормышы үз чоры белән генә чикләнеп калмый. Шуңа күрә дә бөек әсәрләр гасырлар буе үзләренең кыйммәтләрен югалтмыйлар.

Аднаш хафизның «Сиражел-колүб» әсәрен дә аннан соң килгән әдипләр укып, үзләштереп, аның идеяләреннән үзлә-

---

[1] Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 190–191.

[2] Веселовский А.Н. Историческая поэтика. М.: Высшая школа, 1989. С. 19.

[3] Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика (вопросы взаимосвязей и поэтики). Казань: Издательство Казанского университета, 1993. С. 354.

ренең яңа әсәрләрен иҗат иткәндә файдаланмый калмаганнардыр, чөнки бу әсәр кулъязма рәвешендә кулланылып, халык арасында таралган була. Күп әдипләр, бәлки, бу әсәрне укып, үзләре дә язу эшенә илһамланганнардыр. Шуңа күрә XVII–XVIII гасыр әдәбиятында аның чаткылары һәм алар арасында берникадәр уртаклык чамаларга мөмкин. Чөнки, XVI гасырдагы кебек, ул чорда да рус чиркәвенең чукындыру сәясәте дәвам итә. Шуңа күрә халыкның үзенә файдалы киңәшләр бирүчегә ихтыяҗы кимеми.

## 2.1. «Сиражел-колүб» идеяләренең Мәүла Колый хикмәтләрендә үстерелеше

Мәүла Колый иҗаты белән шөгыльләнгән барлык авторлар да бердәм рәвештә аның суфи шагыйрь булуын күрсәтәләр. Мәүла Колый шигырьләренең язылу урыны: «Әйтелде Шәһре Болгар кәндләрендә», – дип күрсәтелә. Бу сүзләрдән аның хикмәтләрен Шәһре Болгар тирәсендәге авылларның берсендә язуы аңлашыла. Шагыйрьнең чын исеме – Бәйрәмгали Колыев. Татар галиме Марсель Әхмәтҗанов язганча, ул 1678 елда дуслары белән Биләр шәһәренә күчеп, нигез кора. Алар мөселман мәдәнияте үзәкләрен саклап калу нияте белән күченәләр. Нәтиҗәдә, Биләрдә мөселманнар яши торган торак пункт барлыкка килә. Монда татарларның ныгый баруы патша хөкүмәтенә ошамый. Моның ише урта гасыр мөселман мәдәни мәркәзенең татарларны оештыру үзәге булып китүен христиан дәүләте үзенә куркыныч дип санаган. Шунлыктан, бу төбәктән татарларны куып таратып, анда рус хәрби үзәге оештыру планына керешәләр[1].

---

[1] Әхмәтҗанов М.И. Яңа археографик табышлар һәм аларны татар әдәбияты тарихын тикшерүдә куллану: филол. фән. док. ... дис. Казан, 1998. Б. 113–118.

Билгеле, XVII гасырда Идел буенда суфичылык идеяләре аеруча көчәеп киткән. Дин эшеннән һәм хөкүмәт идарәсеннән читләштерелгән руханилар, галим-укымышлылар арасында суфичылык идеологиясе шактый кулай җирлек таба, аларның күңел халәтенә аваздаш булып чыга.

«Кеше авыр тормыштан котылуның реаль юлын күрә алмаган, ярдәм сорап Аллага, илаһи көчкә мөрәҗәгать иткән. Иске Болгар хәрабәләрендәге «изге» каберлекләргә, гыйбадәтханәләргә суфи-дәрвишләр, догачы габидлар килеп тулуы моңа бер мисал. Шулай да монда килүчеләр үз эчләрендә шактый чуар төркемне тәшкил иткәннәр. Фикер ияләренең кайберәүләре суфичылыкка иярсәләр дә, тәгать кылып, кул кушырып кына гомер үткәрә алмаганнар»[1].

Шундый тынгысыз заманда Мәүла Колый халкына кирәкле киңәшләрен, үгет-нәсыйхәтләрен бирүне үзенең бурычы итеп саный. Чөнки тормышта җәбер-золымның соңгы чиккә җитүен күреп торган нинди әдипнең йөрәге әрнемәсен дә, ничек бу турыда уйланмасын.

Мәүла Колый, Аднаш хафиз кебек үк, иман саклау мәсьәләсенә бик киң туктала. Үзенең хикмәтләренең күп җирләрендә ул иман белән дөньядан үтү өстенлекләрен санап үтә:

«Иман берлә үлсәм диү өмидем вар,
Иман әйтү – үлгән колга рәхмәт дуслар»[2].

Шулай ук:

«Бу дөньядин иман берлә үтәр булса,
Гүрдә юлдаш гүр эчрә ятар имеш.

---

[1] Дәүләтшин, К.С. XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колый иҗаты: филол. фән. канд. дис. Казан, 1971. Б. 136.

[2] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 17.

Оҗмахка илтер, кыямәт көн йитәр булса
Оҗмах өмид идеп, иман әйгем килер»[1].

«Сираҗел-колүб» әсәрендәгечә, Мәүла Колый да иманлы килеш үлүчегә кыямәт көнендә рәхәтлекләр, яхшы тормыш хәзерләнгәнлеген әйтә. Кабердәге Мөнкир белән Нәкир кешедән: «Раббың кем?» – дип сорау алганда, мөэмин кеше җиңел җавап бирер һәм кабердә бернинди газап күрмәс, ди:

«Ул сөальгә бирсә җавап,
Гүр эчрә күрмәс газап»[2].

Әгәр кеше имансыз килеш дөньядан үткән булса, ул бу фәрештәләрнең сорауларына җавап бирә алмас һәм төрле газапларга дучар булыр, ди:

«Ул өюгә фәрештәләр киләседер,
Изге – явыз, барча эшең сорасыдыр.

Имансызга төрле газап кыласыдыр,
Иман әйтү, тәүбә-тәүфикъ кыла күргел»[3].

Соңыннан мәхшәр көнендә бәндәләрнең гамәлләре үлчәнерләр. Мөэмин кешенең яхшы гамәлләре авыр килер һәм ул котылыр. Кяфер бәндәнең явыз гамәлләре авыр килер һәм ул тотылыр, газапланыр:

«Андин соңра мизаныла барасыдыр,
Һәр гамәлең ул мизанга буласыдыр.

Изге гамәл йиңсә, чәндан буласыдыр
Явыз гамәл йиңер булса, бардыр хәтәр»[4].

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 23.
[2] Шунда ук. Б. 77.
[3] Шунда ук. Б. 85.
[4] Шунда ук. Б. 121.

Сират күперен кичкәндә мөэмин бәндә исән-имин генә аны кичеп чыгар һәм оҗмахка керер. Кяфер бәндә исә сират күперен кичеп чыга алмас, йөзтүбән тәмуг утына төшеп китәр:

«Галәм халкы ул көн, анда, терелүбән,
Гарасатка килер анда, сөрелүбән.

Кырык мең ел ул мәкамдә булып һаман,
Йегерме биш мең ел сиратда калыр ирмеш.

Йегерме биш мең елдин соң, әмер булгай,
Кяфер, мөэмин бер-берендин аерылгай.

Мөэмин коллар дидар күреп җәннәт булгай,
Кяфергә бакый тәмуг булыр ирмеш»[1].

Шулай итеп, бәндә үзенең иманлы булуы аркасында мәңге җәннәткә, имансыз кеше исә мәңге җәһәннәмгә лаек булыр.

Мәүла Колый заманында халык күтәрелешләре күп була, алар рәхимсез рәвештә бастырылалар. Патша тарафыннан Степан Разинга каршы җибәрелгән җәза отрядының эшләре түбәндәгечә тасвирлана:

«Место сие являло зрелище ужасное и напоминало собой преддверие ада. Вокруг были возведены виселицы, и на каждой висело человек сорок, а то и пятьдесят. В другом месте валялись в крови обезглавленные тела. Тут и там торчали колы с посаженными на них мятежниками, из которых немалое число было живо и на третий день, и еще слышны были их стоны. За три месяца по суду, после расспроса свидетелей, палачи предали смерти одиннадцать тысяч человек»[2].

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 31.

[2] Записки иностранцев о восстании Степана Разина. М.: Наука, 1968. С. 112.

Мәүла Колый менә шундый тынгысыз бер чорда яши. Бу елларда илдә җәбер-золым түзмәслек дәрәҗәгә җитә. Гаделсезлектән котылу өчен, динен һәм милләтен саклап калу өчен татар халкы актив көрәшкә күтәрелә. Халык арасында азатлык идеяләре тарала башлый. Әмма бу кузгалышлар рәхимсез рәвештә бастырылып килә. «Крестьян кузгалышларын бастыру царизмга колониаль политиканы тагын да шәфкатьсезрәк үткәрергә нигез бирә. Шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә йортсыз-җирсез калган хәерче-гарипләрнең саны хисапсыз арта. Өстәвенә, бу елларда таралган төрле эпидемияләр, ачлык һәм хәерчелек халык өстенә күтәрә алмаслык афәт булып төшә. Мондый бәхетсез адәмнәр, әлбәттә, дөньядан туя, бу авырлыклардан котылу юлын күрә алмаганлыктан, яшәүнең мәгънәсен югалта. Менә шушы өметсезлеккә баткан, язмышына да, Алласына да рәнҗегән бәндәләрнең күңелен юатуны Мәүла Колый үзенең бурычы итеп саный»[1].

Мәүла Колый гарипләр турында язганда тәннәре зәгыйфь яки имгәнгән кешеләрне күздә тотмый, бәлки, җаннары, күңелләре имгәнгән, рәнҗетелгән, кыерсытылган кешеләрне күздә тота. Бу исә чукындыру сәясәте белән бәйле булган. Автор татар халкының тормышы искиткеч авыр булуын, хәтта аларның тыныч кына ятып үләрлек урыннары да юклыгын җан тетрәткеч юллар белән тасвирлый:

«Гарипләргә тормага йорт-мәкян каны?
Баш агырса, әҗәл йитәр, куркар җаны, –

Олуг-кардәш кыла алмас сәне гани,
Гариплектә үлем килсә, дөшвар иркән.

Башында ултырмага ятасы юк,
Өстендә хәсрәт йияр анасы юк.

---

[1] Дәүләтшин К.С. XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колый иҗаты: филол. фән. канд. дис. Казан, 1971. Б. 132.

Уңлы-суллы, хәлен сорар иясе юк, –
Бер үлмәке мең үлмәкдин яман иркән,

Гарипләргә үлем килсә, моңлыг башы,
Юк аның гүргә куяр карендәше.

Аш кылмагай, гарип өчен тикмә кеше, –
Гариплектә килгән үлем шул тик иркән»[1].

«Мәүла Колыйның гарипләр турындагы хикмәтенә таянып, шуны әйтергә була: шагыйрь бу әсәрендә кыерсытылган ярлы халык вәкилләренең канлы яшь түгүен чагылдыра алган. Чөнки шагыйрь үзе дә, тормыштан аерылган ниндидер дәрвиш-аскет булмыйча, ватандашларының аһ-зарын күреп, тоеп яшәрлек актив шәхес булган. Авыр хәлләргә дучар ителгән «бичара»ларга теләктәшлек күрсәтеп, аларга ярдәм кулы сузарга теләгән һәм башкаларны да шуңа чакырган»[2].

Мәүла Колый, Аднаш хафиз кебек үк, татар халкына бу коточкыч хәлдән чыгу юлын күрсәтергә омтыла. Бу юл – Аллаһы Тәгаләгә таянып һәм сабыр итеп, дошманнар алдында ныклык күрсәтү. Мәүла Колый XVI гасырда ук Аднаш хафиз тарафыннан тәкъдим ителгән юлны үзенең замандашларына тәкъдим итә. Бу исә Аднаш хафиз киңәшләренең универсаль булуын, XVII гасыр өчен дә кирәкле һәм үз кыйммәтләрен югалтмауларын күрсәтә. Мәүла Колый да, нык тору дигәндә, дошманнарны корал белән түгел, ә иман ныклыгы һәм сабырлык белән җиңүне күздә тота. Чөнки татар халкы инде бик күп мәртәбә корал белән каршы чыгып карады, ләкин аның файдасы булмады, киресенчә, бик күп кеше кырылды, һәлак булды. Бу исә милләтнең бөтенләй кырылып юкка чы-

---

[1] Колый М. Хикмәтләр ; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 69–70.

[2] Дәүләтшин К.С. XVII йөз татар шагыйре Мәүла Колай иҗаты: филол. фән. канд. дис. Казан, 1971. Б. 136.

гуына китерергә мөмкин иде. Моны Мәүла Колый бик яхшы аңлый. Бу сынауны кеше беркайчан да берүзе генә үтеп чыга алмавын белгәнгә, таянырга ниндидер бер терәк кирәк булганга, шагыйрь монда терәк итеп Аллаһы Тәгаләне күрсәтә. Сынаулар никадәр авыррак, күбрәк булса, кешенең Аллаһы Тәгаләгә таянуы да шулкадәр арта. Мәүла Колый халык үзе үч ала алмаганлыктан, бу үч алуны Аллаһка калдырырга үгетли, чөнки Аллаһның кяферләрне, залимнәрне кыямәт көнендә, һичшиксез, җәзага тартачагын әйтә. Мондый төр сынауларны хәтта пәйгамбәрләр, әүлиялар да күрә. Мисал итеп, әдип Ибраһим пәйгамбәрне китерә. Аны Нәмруд исемле патша утка ата. Әмма Аллаһы Тәгаләгә чын күңелдән таянганга күрә, Аллаһ аны коткара. Шулай ук «Сираҗел-колүб» әсәрендә китерелгән Җирҗис кыйссасы да китерелә. Ул дине өчен дүрт тапкыр җанын биреп, ахыр чиктә җиңүгә ирешә:

«Бу дөнья газапларын Җирҗис күрде,
Ул, газапта, дүрт кат Хакка җанын бирде.

Ул хәлдә икән, Хак күзенә күренү торды, –
Шул вакытта Хак дидарын күрмештер ул»[1].

Мәгълүм булганча, Мәүла Колый белән Аднаш хафиз бер үк кыйссаларны китерәләр. Күрәсең, Мәүла Колый «Сираҗел-колүб» әсәре белән бик яхшы таныш булгандыр һәм аннан күп элементларны файдаланып яза. Ләкин ул, талантлы әдип булуы сәбәпле, бу теманы бераз үстереп җибәрә һәм өстәмә дини риваятьләр, кыйссалар китерә. Мәсәлән, Йосыф, Әюб пәйгамбәр һ.б.лар турында. Бу пәйгамбәрләр, әүлиялар Аллаһка таянып һәм сабыр итеп, ахыр чиктә уңышка, җиңүгә ирешәләр. Мәүла Колый аларны үрнәк итеп биреп, халыкка бу

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 74.

авырлыклардан чыгу юлын күрсәтә. Ул хәтта үлем белән янасалар да, гомереңә куркыныч янаса да, барыбер иманны, динне саклауда нык торырга, кирәк икән җаныңны корбан итәргә кирәклекне белдертә:

«Ихлас илә һәркем кылса Хакның эшен,
Тәгать кылып Хакга еглап түкәр яшен;

Хакка бирер корбан өчен җанын-башын,
Хакны эстәгән баш җандин кичмәй булмас»[1].

Үзеңне дин өчен корбан иткәндә, үлемнән куркырга кирәк түгеллекне әйтә автор. Чөнки мөэмин кешегә үлгәннән соң куркырга сәбәп юк, аны анда җәннәт көтә. Ләкин моны бөтен кеше булдыра алмый, фәкать үзенең иманы, тәвәккәллеге белән әүлияләр дәрәҗәсенә җиткән кешеләр генә булдыра алуын аңлый шагыйрь. Ул андый кешеләрне мактап яза:

«Хак юлында коллык өчен башын салса,
Хак әмренә газиз җанын корбан чалса,

Бу дөньяны, бер сәгать дип, фани белсә,
Әүлиялык нишаннары бардыр анда»[2].

Бу дөньяга ябышып ятып, дин өчен җанын корбан итәргә теләмәүчеләрне ул бик каты тәнкыйтьли һәм аларны этләр белән чагыштыра:

«Этләр, өрешеп, үләр. Калыр – сасыг ит, бел,
Гыйбрәт алып Хак эшенә күңел биргел.

Дөнья өчен эт булмагыл, бизә күргел,
Тәгать өчен җаным фида итәен мән»[3].

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 119.

[2] Шунда ук. Б. 124.

[3] Шунда ук. Б. 68.

Гомумән, һәр суфи әдип кебек, Мәүла Колый да дөньялыкка карата тискәре мөнәсәбәттә тора. Бу дөньяны ул бик каты хурлый, ахирәт тормышына гына әһәмият бирә. Бу тормышны мәңгелеккә хәзерлек, чын һәм тулы булмаган яшәеш дип күз алдына китерә, аңа бик үк җитди булмаган, игътибарга лаексыз, кайбер очракта бөтенләй җирәнгеч нәрсә итеп карый. Алдаучан бу дөньяны сурәтләү өчен күп төрле чагыштырулар кулланып яза:

«Бу дөнья зиндан ирмеш, белең монда,
Бу тәнемез бостан ирмеш ул зинданда.

Җанларымыз миһман ирмеш ул бостанда
Ул бостан бозылыр булса, хәсрәт анда»[1].

Дөньяга мондый караш җирдә яшәүнең мәгънә-әһәмиятен киметә, бу тормыш «мәңгелеккә хәзерлек», чын һәм тулы булмаган яшәеш дип күзаллауга китерә.

Бу дөньяга шундый тискәре караш булгач, әлбәттә, Мәүла Колый үлемдә бернинди фаҗига күрми һәм кешенең, үз иманын саклап калу өчен, үлүен дә ул куркыныч нәрсәгә санамый. Чөнки, аның фикеренчә, иманлы кеше генә ахирәттә чын тормыш белән яши башлый, ә бу дөньяда хайваннар кебек динсез яшәүнең әһәмиятен күрми. Аның бу карашлары Аднаш хафиз карашлары белән туры килә.

«Мәүла Колыйның йөзгә якын хикмәтләренең, ким дигәндә, яртысында авторны бик уйландыра торган глобаль тема – үлем темасы ята. Моның сәбәбе – беренче чиратта, әлбәттә, автор яшәгән авыр тормыш шартларында, идеологик торгынлык һәм халыктагы рухи пессимизмда. Мәүла Колыйның үлем

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 13.

турында уйланулары, нигездә, ислам дине өйрәтмәләреннән читкә чыкмый»[1].

Аднаш хафиз кебек үк, Мәүла Колый да динне саклауда бик нык сабыр булырга куша. Сабыр иткәндә генә Аллаһ уңыш һәм җиңү бирәчәк икән. Чөнки пәйгамбәрләр дә сабырлык аркасында гына җиңүгә ирешкәннәр:

«Сабыр берлә Әюп тапты сиххәт үзен
Сабыр берлә Ягкуп ачты күрмәс күзен.

Сабыр берлә Йосыф тапты дәүләт йөзен,
Сабыр сүзен телдин җөда итсә булмас»[2].

Татар халкына күп җәфалар китергән залим патшаларның тәхетләре, барыбер, кайчан да булса юкка чыгачак һәм аларның, һәрбер явыз эшләре өчен, Аллаһ каршында җавап тотачакларын белгертергә тырыша шагыйрь:

«Дөньядагы тәхетләр егылгусы,
Күрер күзгә туфраклар һәм тулгусы.

Бөтелгән намәләр укулгусы
Хисап-сөаль биререндин хәбәре юк»[3].

Мәүла Колый Аллаһка һәрвакыт сыена һәм Аннан һәрвакыт үзен, халкын саклавын һәм рәхмәтен сорый. Бу – чукындыручылардан саклауны аңлатадыр:

«Изем җәббар, өмидебез рәхмәтендин
Хәтәребез тәмуг атлы афәтендин.

Тереклектә сән саклагыл михнәтеңдин,
Рәхмәтеңдин мәхлук өмид өзмәк юктыр»[4].

---

[1] Сибгатуллина Ә.Т. Татар әдәбиятында суфичылык: чыганаклар, тематика һәм жанр үзенчәлекләре: филол. фән. док. дис. Алабуга, 2000. Б. 175.

[2] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 19.

[3] Шунда ук. Б. 135.

[4] Шунда ук. Б. 62.

Шагыйрь Аллаһның бөеклеген, кодрәтен кат-кат искәртеп тора һәм, Аллаһ мөэминнәрне үз яклавы астына ала, дип ышана. Аднаш хафиз кебек үк, мөэмин кеше һәрвакыт Аллаһның саклавын тойсын өчен, Хозыр белән Ильяс пәйгамбәрләрне искә ала:

«Туннары илә, мәңге суына чумды анлар,
Ул сәбәбтин тузмас анлар кигән туннар.

Кемдин хушнуд булып, кыйлса дога монлар,
Дөнья-ахирәт дәүләтен бирер булгай.

Яланда азсаң, йә суда булса хәтәр,
Анларга иткел нияз, мәдәд итәр,

Азмыш улырсың, юл түндерер ярдәм итәр,
Һәм дәрьяда йеп салып тартар булгай»[1].

Шулай итеп, Мәүла Колый иманны саклауда нык торырга, сабыр итәргә, Аллаһы Тәгаләгә таяныргa, Аннан яклау көтәргә чакыра. Аллаһтан башка бүтән затка табынудан катгый рәвештә тыя:

«Билең игеп, куя күрмә башың потка,
Баш бирде Изем сәҗдә кыйлгаймы дип»[2].

Беркемгә дә сер түгел, иман кешенең тормышында мөһим роль уйный һәм зур урын алып тора. Дин әһелләре фикеренчә, кешенең бу дөньядагы бәхете һәм ахирәттәге бәхете нәкъ менә иманына, аның дөреслегенә, чисталыгына бәйле. Шуңа күрә, бу өммәтнең әүвәлгеләре, җиңнәрен сызганып, бер-берсе белән иманнарын дөресләүдә, арттыруда ярышканнар. Бу турыда бик күп риваятьләр бар. Мәсәлән, Гомәр бине Хаттаб

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 35.

[2] Шунда ук. Б. 53.

үзенең иптәшләрен: «Утырыгыз безнең белән, иманнарыбызны арттырыйк,» – дип чакыра торган булган.

Габдулла бине Мәсгуд тә нәкъ шундый сүзләр кабатлый торган булган. Бу гына түгел, ул һәрвакыт бер дога кылган: «Йа, Раббым, минем иманымны, динне аңлавымны арттыр!»[1].

Ислам динендә иман – артырга яки, кимеп, бөтенләй бетәргә мөмкин. Бу турыда бик күп ислам галимнәре әйтеп калдырган. Мәсәлән, бөек дин галиме Әхмәд бине Ханбәлдән сораганнар: «Иман арта һәм кими аламы?» Ул җавап биргән: «Ул җиденче күккә хәтле артырга һәм җиденче җиргә хәтле кимергә мөмкин. Иман сүзләрдән һәм гамәлләрдән тора. Әгәр син яхшы эш кылсаң – ул арта, әгәр дә начарлык кылсаң – кими».

Шулай ук бервакыт Габдрахман бине Гамр әл-Әүзәидән сораганнар: «Иман артырга мөмкинме?» Ул җавап биргән: «Әйе, ул тау хәтле булганчы». Тагын сораганнар: «Иман кимергә мөмкинме?» Ул: «Әйе, ул кимеп хәтта юкка чыгарга да мөмкин», – дип җавап биргән.

Гомәйр бине Хәбиб әл-Хәтми әйткән: «Иман арта да, кими дә». Аннан сораганнар: «Аның артуы һәм кимүе нәрсә аңлата соң?» Ул җавап биргән: «Әгәр дә без Аллаһы Тәгаләне олыласак, Аны мактасак, иман арта, әгәр дә Аны онытып, гафиллектә йөрсәк, ул зәгыйфьләнә»[2].

Дин галимнәре һәрвакыт үзләренең иманнарына игътибарлы булганнар. Аларның фикеренчә, яхшы гамәлләр, гыйбадәтләр күбрәк кылган саен, иман арта һәм көчәя, гөнаһлы эшләрне кылган саен, ул кими һәм зәгыйфьләнә икән[3]. Шуңа

---

[1] Аль-Бадр А. Причины увеличения и уменьшения веры; пер. с араб. Э. Кулиева. М.: Умма, 2003. С. 3.

[2] Шунда ук. С. 4.

[3] Шунда ук. С. 5.

күрә алар халыкны фарыз һәм важиб булган гыйбадәтләрне үтәргә һәм гөнаһтан мөмкин кадәр тыелырга чакырганнар.

Мәүла Колый да, укымышлы кеше буларак, бу турыда яхшы белгән, аңлаган һәм үз халкы өчен кайгырган. Ул заманда кеше теләсә кайсы вакытта имансыз калырга мөмкин иде. Чөнки Мәүла Колый яшәгән заман көчләп чукындыру вакытына туры килә. Кешеләрне төрле ысуллар белән христиан диненә кертү юллары уйлап табыла: көч белән, төрле өстенлекләр аша, матди ярдәм итү юлы белән һ.б. Шуңа күрә иманы зәгыйфь булган кеше, үзе дә сизмәстән, иманыннан ваз кичәргә мөмкин икәнлеген аңлый автор һәм иманны ныгыту юлларын күрсәтә. Моңа исә, иң беренче чиратта, Аллаһы Тәгалә бәндәләргә фарыз кылган гыйбадәтләрне үтәү һәм гөнаһлардан саклану юлы белән ирешеп булуын аңлата. Моңа намаз уку, ураза тоту, зәкят бирү керә. Иманын арттыру өчен мөселман, тырышып, бу гыйбадәтләрне фәкать бер Аллаһ өчен генә кылырга һәм алар еш, даими эшләнергә тиеш. Шәригать буенча эшләнелгән һәр гамәл, һичшиксез, кешенең иманын арттыра, чөнки ул гыйбадәт кылган саен көчәя генә бара[1].

Мәүла Колый, кеше иманын арттыру өчен иң зур гыйбадәтләрдән башларга кирәк, дип саный. Белгәнебезчә, зур гыйбадәтләргә намаз, ураза, зәкят, хаҗ керә. Моның шулай икәнлеген һәр мөселман белә, бу турыда хәдисләр дә шактый күп.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Ислам дине биш баганага таяна:

1. Аллаһыдан башка илаһ юк һәм Мөхәммәд Аның илчесе, дип шәһадәт бирү.

2. Үз вакытында бөтен шартларын үтәп намаз уку.

3. Зәкят түләү.

---

[1] Аль-Бадр А. Причины увеличения и уменьшения веры; пер. с араб. Э. Кулиева М.: Умма, 2003. С. 47.

4. Рамазан аенда ураза тоту.

5. Мөмкинчелеге булган кешегә үз гомерендә бер мәртәбә Мәккәгә барып хаҗ кылу.

Ошбу биш нәрсә – Ислам диненең нигезләре. Бинаның нигезе сыман алар зәгыйфь булса яки бөтенләй булмаса, ул вакытта баланың сәламәт торуы мөмкин булмаган кебек, диннең нигезләре какшавы мәгълүм. Шуңа күрә һәр мөселман кеше ошбу биш нәрсәгә җитди карарга һәм аларны үтәргә тиеш»[1].

Намаз – ул билгеле бер сүзләр һәм хәрәкәтләр белән Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу. Аллаһы Тәгаләне бар һәм бер, дип иман китергәннән соң, ул гыйбадәтләрнең иң зурысы булып санала. Намаз – бөтен йөкләнгән эшләрнең (фарызларның) нигезе һәм диннең терәге[2].

Намаз хакында Мәүла Колый бик күп хикмәтләрендә яза. Намаз кабердә нур һәм юлдаш, сират күперен кичкәндә ике канат, кыямәт көнендә яклаучы булыр, ди шагыйрь. Аллаһы Тәгалә кешене гыйбадәт кылыр өчен яраткан, ә гыйбадәтнең иң зурысы – намаз. Аллаһ билне намазда иелер өчен, ике тезне сәҗдә кылыр өчен, ике күзне сәҗдә урынын күрер өчен, маңгайны сәҗдә вакытында җиргә куяр өчен яраткан, ди. Әгәр бу әгъзалар сиңа кадерле икән, син аларны фәкать Аллаһка коллык өчен генә файдаланырга тиеш. Әгәр коллык күрсәтмисең икән, Аллаһ аларны синнән алырга мөмкин икән.

Намазның мөэмин-мөселман өчен мәҗбүри икәнлеген әдип кат-кат искәртә һәм аны үтәүченең бик күп фазыйләтләргә ия булуын аңлата. Аны үтәүче кеше җәннәттә яхшы тун кияр, төрле нигъмәтләр табар, хур кызларына ия булыр. Намаз укы-

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. I. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль-Ибрагим», 2002. – С. 33.

[2] Мәүлетдинов Ф., Кәбиров Р. Җәннәт ачкычлары. Казан: Арт-экспресс, 2008. Б. 42.

маучы кешене Мәүла Колый үлек кеше белән чагыштыра. Аларның күңелләрендә начарлык кына булыр һәм алар – мөэминнәргә зарар кылучы дошманнар, ди автор. Шулай ук намаз укымаучының урыны тәмуг булыр, кабере елан-чаян белән тулган булыр, фәрештәләр аны ләгънәт кылыр, Аллаһ ул кешедән бизәр. Мәүла Колый намаз укымаучыны дуңгыз белән чагыштырып, бик оста тасвирлый:

«Бинамазлар сыйфаты охшар, белгел дуңгыз,
Тизәк тотып йорт төзегән кара коңгыз.

Бинамазда мал йыймакдин йук үзгә сүз,
Йыйган малы монда хәрам кылыр ирмеш.

Күргел, коңгыз йорт иткем дип, тизәк тотар,
Суык булса, кара йиргә инеп китәр.

Бинамазлар намаз кылмаз, дөнья тотар.
Хур-зар булып кара йиргә керер ирмеш»[1].

Ни өчен соң Мәүла Колый намазга шулкадәр әһәмият бирә? Чөнки, беренчедән, алда күрсәтелгәнчә, намаз – ислам диненең бер терәге. Икенчедән, ул заманда динне актив рәвештә кысрыклау барган, намаз укучыларны төрлечә җәзалаганнар һәм намаз укырга ирек бирелмәгән. Шул рәвешле, халык намаз укудан читләшә барган. Өченчедән, намаз укымаучының иманы бик зәгыйфь була һәм ул иманыннан бик тиз ваз кичәргә мөмкин. Чөнки христианлаштыру сәясәте һаман да бик актив рәвештә дәвам ителгән һәм кешеләрне чукындыру өчен төрле ысуллар кулланылган. Дүртенчедән, намаз – мөселманны кяфердән аера торган нәрсә һәм аны үтәмәүчеләр, инкарь итүчеләр кяфер булалар. Бу турыда әдип түбәндәгечә яза:

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 25.

«Кяфер-мөшрик Аллаһ дәю Хакны белмәс,
Языкындин тәүбә кылып Хакка килмәс.

Намаз вакыты булса, Хакка сәждә кылмас,
Гасый колга тәмуг атлы гокбәте бар»[1].

Балигълык яшенә җитеп, Аллаһ фарыз кылган биш намазны укымау зур гөнаһлардан санала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) балаларны намазга җиде яшьтән күндерә башларга, ун яшьтән исә намаз укуларын һәрвакыт күзәтеп торып, нык торырга кушкан.

Бөтен галимнәрнең карашы буенча, намазны инкарь итүче кеше кяфер булыр һәм Ислам милләтеннән чыгар. Әмма кем намаз Аллаһы Тәгалә тарафыннан йөкләнгән һәм аны үтәргә кирәк икәнлегенә ышана, ләкин ялкаулык сәбәпле калдырса, күпчелек галимнәрнең карашы буенча, ул кеше зур гөнаһлы мөселман булып саналадыр. Ләкин кайбер галимнәрнең карашы буенча, намазны ялкаулык сәбәпле калдыручы да кяфер булыр. Моңа дәлил итеп пәйгамбәребезнең (с.г.в.) кайбер хәдисләрен китерәләр, шулардан:

«Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Мөселман кеше белән көферлек арасында – ул намазны калдыру" (Әхмәд, Мөслим, Тирмизи һ.б.), ягъни намаз укымаучы кеше көферлеккә якынлашкан була»[2].

Намаз укымаучылар Коръәндә дә кисәтеләләр:

«Намаз укымаучылардан сорарлар: "Сезне сәкар (җәһәннәмнең бер исеме) җәһәннәменә нәрсә кертте?" Алар: "Без намаз укучылардан түгел идек", – диярләр» («Мүдәссир» сүрәсе, 42–43 нче аятьләр).

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 83.

[2] Мәүлетдинов Ф., Кәбиров Р. Җәннәт ачкычлары. Казан: Арт экспресс, 2008. Б. 78.

«Ул пәйгамбәрләрдән соң явыз кавем килде, алар намазларын кичектереп, казага калдырып яки бөтенләй укымыйча харап итүчеләр һәм шәһвәтләргә, нәфес теләгән нәрсәләргә иярделәр, алар, тиздән, ахирәттә каты газапка очраучылардыр» («Мәрьям» сүрәсе, 59 нчы аять).

«Ни үкенеч һәм һәлакәт ихлассыз намаз укучыларга. Алар намазларыннан гафилләр, вакытында укымаслар һәм рөкеннәрен хөрмәт кылмаслар, намазларының вакытыннан кичегүенә кайгырмаслар» («Мәгун» сүрәсе, 4–5 нче аятьләр).

Аднаш хафиз да «Сиражел-колүб» әсәрендә намаз хакында яза, ләкин чагыштырмача азрак яза. Мәүла Колый исә бу теманы тагын да үстереп, тәфсилләп, киң итеп сурәтләп бирә.

Шулай ук Мәүла Колый кешеләрне намазларын җәмәгать белән мәчеттә укырга өнди:

«Хак яратты кыям өчен ике аяк,
Мәсҗед сары җәмәгатькә баргыл уяг.

Аяк басып хәзерләри гүргә чыраг.
Хак бирде аяк мәсҗед сары йөрмәк өчен»[1].

Шулай ук:

«Тәгать кыла, тор уяг,
Мәсҗед сары бас аяк. –

Мәсҗед сүмәз җаһилгә
Нигә кирәк бу аяк»[2].

Шагыйрь яшәгән чорда мәчетләрне күпләп җимерәләр. Шуңа күрә әдип мәчетләргә карата кешеләрнең игътибарын көчәйтергә омтыла. Бу өзекләрне җимерелгән мәчетләрне кабат торгызырга, яңа мәчетләр салырга чакыру дип аңлап

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 52.

[2] Шунда ук. Б. 82.

була. Чөнки мәчетләргә йөрер өчен Хак Тәгалә аяклар биргән. Мәчетләр булмаса аякларга хаҗәт калмый кебек булып чыга.

Ислам диненең өченче баганасы булган ураза хакында да Мәүла Колый күп яза. Ураза (*фарс.* көн буе тыелып тору) – ислам динендә билгеләнгәнчә, мәгълүм вакытка ашау-эчүдән, бозыклыклардан, яман гадәтләрдән тыелу. Ураза тоту мөселманнар өчен фарыз[1].

Шагыйрь Рамазан аенда ураза тотуның мәҗбүри икәнен искәртә:

«Рамазан рузасын фарыз белгел,
Руза тотып, фарыз белеп фитра биргел.

Рузаның вакытын белеп, сәхәр торгыл –
Хак хәбибе Мөхәммәдкә вир салават»[2].

Ураза тоткан кешенең нинди фазыйләтләргә ия булуын да әдип тасвирлап үтә. Мәсәлән, андый кеше тәмуг утын күрмәс, оҗмахта кәүсәрдән шәраб эчәр һ.б. Ураза тотмаган кешегә исә Аллаһы Тәгалә җәза бирер. Шуңа күрә кеше ахирәттә Аллаһ рәхмәтенә ирешергә теләсә, уразаны калдырмаска тиеш булып чыга:

«Тереклектә кылган булсаң руза – тәгать,
Үлеп барсаң, гүр өендә булыр рәхәт;

Юлың ачып күргәзгәйләр рәхмәт җәннәт,
Бу дөньяда изге гамәл кылмышындин»[3].

Коръәндә дә уразаның фарыз икәнлеге хакында искәртелә:

«Әй мөэмин бәндәләр, әүвәл замандагы мөэминнәргә фарыз кылынганы кебек, тәкъвалыгыгыз артсын өчен, Рамазан-

---

[1] Ислам. Белешмә сүзлек. Казан: Татар кит. нәшр., 1993. Б. 143.

[2] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 49.

[3] Шунда ук. Б. 113.

да руза тоту сезгә дә фарыз кылынды» («Бәкара» («Сыер») сүрәсе, 183 нче аять).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам дә әйткән: «Руза уттан саклый торган калкандыр. Аллаһ руза тотучы турында: «Ул Минем өчен ашаудан, эчүдән һәм якынлык кылудан баш тартты. Минем өчен руза тотты һәм Мин шуның өчен аны бүләкләрмен, һәр яхшы эше өчен унлата савап белән кайтарырмын», – дип әйтә[1].

Мәүла Колый ислам диненең дүртенче баганасы – зәкят турында да яза. Зәкят (*гар.* – арыну, садака, салым) – мал-мөлкәт хисабыннан чыгып, ярлы мөселманнар өчен дип бирелә торган садака, салым[2]. Шагыйрь зәкят, аның күләме, кемнәргә мәҗбүри икәнлеге турында тәфсилләп яза һәм байлыгы булган кешеләрне зәкят түләргә өнди:

«Хак яратты дөньяга,
Хакны бер дип белсәнә,

Мал вә нигъмәт бирде Хак,
Малдин зәкать бирсәнә»[3].

Ашлыкның уннан бер өлешен ел саен гошер итеп түләргә куша, һәрвакыт садакалар таратып ярлы-фәкыйрьләрнең күңелләрен күрергә өнди, зәкят бирмәүчеләрне Аллаһның газабы белән куркыта автор[4].

Коръәндә дә зәкят турында аятьләр бар:

«Ий, мөэминнәр! Кәсеп итеп тапкан малларыгыздан һәм Без сезнең өчен җирдән чыгарган уңышлардан яхшысын Аллаһ күрсәткән урыннарга бирегез! Әмма начар нәрсәләр

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. I. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль-Ибрагим», 2002. С. 397.

[2] Ислам. Белешмә сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 48.

[3] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 102.

[4] Шунда ук. Б. 103–104.

аралаштырып бирмәгез. Шундый малны сезгә бирсәләр, әлбәттә, ул начар нәрсәне күзегезне йомып, чыраегызны сытып кына алыр идегез. Белегез, Аллаһ чиксез бай һәм мактаулы» («Бәкара» («Сыер») сүрәсе, 267 нче аять).

Мөхәммәд пәйгамбәр зәкят түләмәүчеләр хакында түбәндәгечә әйтә:

«Кыямәт көнендә кешенең зәкят бирелмәгән байлыгы агулы елан кыяфәтендә килер, авызында ике агулы тимер булыр. Ул үзенең иясе янында бөтерелер һәм аның яңагына ябышып: «Мин синең байлыгың, мин синең хәзинәң», – дип әйтер[1].

Ислам диненең бишенче баганасы – хаҗ турында автор чагыштырмача аз яза. Бәлки, бу бөтен кешенең дә хаҗ кылырга мөмкинлекләре булмау сәбәпледер, ул моңа бик басым ясамый. Хаҗ (*гар.* табыну) – мөселманнарның Мәккә шәһәрендәге изге Кәгъбә ташы янына барып гыйбадәт кылулары[2]. Татар халкы арасында шагыйрь яшәгән заманда хәлле кешеләр бик аз була. Шуңа күрә күбесенә хаҗ турында хыялланырга гына кала. Чөнки хаҗ – үзе сәламәт булып, Мәккәи-Мөкәррәмәгә барып кайтырлык малы булган бай кешегә генә фарыздыр[3].

Ләкин барыбер әдип хаҗ кылуның савапларын һәм фазыйләтләрен тасвирлап бирә:

«Кәгъбә сары йөрегәннәр – ирнең ире,
Тәваф кыйлып гөнаһындин булыр ари.

Кыямәт көн күрер анлар Хак дидары,
Хаҗи булып Хак дидарын күрсәмче мән»[4].

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. I. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль-Ибрагим», 2002. С. 313–314.

[2] Ислам. Белешмә сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 150.

[3] Шунда ук. Б. 150.

[4] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 31.

Корънннең бер сүрәсе «Хаҗ» исеме астында бирелгән. Анда бу зур гыйбадәт хакында бик җентекләп язылган:

«Кешеләрне хаҗга чакырып кычкыр, җәяү йөреп сиңа килерләр, вә арык дөяләргә атланып килерләр, ул дөяләр ерак юлларның һәрбереннән килерләр. Хаҗиларның дөньяларына вә диннәренә файда китерсеннәр өчен һәм тәшрикъ кебек билгеле бәйрәм көннәрендә Аллаһ исемен күп зекер итсеннәр өчен дөя, сыер вә куйлар белән ризыкландыруына шөкер итеп, хаҗда чалган корбан итләрен ашагыз, аны фәкыйрьгә ашатыгыз. Соңра чәч, мыек, тырнак кебекләрне кисеп артыгын бетерсеннәр, нәзерләрен үтәсеннәр вә Минем иске өем Кәгъбәне таваф итсеннәр» («Хаҗ» сүрәсе, 27–29 нчы аятьләр).

Мөхәммәд галәйһиссәлам түбәндәге сүзләрне әйткән: «Кем дә кем Аллаһ Тәгалә өчен хаҗ кыла һәм хатынына кагылмаса, гөнаһ, начар эшләр кылмаса, өенә яңа гына анадан туган килеш гөнаһсыз әйләнеп кайтыр»[1].

Шулай итеп Мәүла Колый югарыда китерелгән гыйбадәтләрсез иманны, динне саклап калып булмавына ышана һәм башкаларга да моны аңлатырга тырыша. Чөнки бу гыйбадәтләрсез дин буш һәм зәгыйфь була, ә алар булганда кешенең дине нык, сынмаслык була. Ләкин бу гыйбадәтләрне чын ихласлык белән үтәргә кирәк, югыйсә алар файда китермәячәкләр икәнен дә аңлата әдип:

«Ихласлылар төн-көн еглап кылыр намаз, –
Игътикадлә хакка кылыр руза-намаз.

Җөмлә эшен кабул кылыр, Ул бинийаз.
Ихлассызның «Хак» дип сүләр сүзе юктыр»[2].

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. I. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз Аль-Ибрагим», 2002. С. 342.

[2] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 26.

Шагыйрь, ихласлы кешенең гөнаһлары кичерелер, Хак Тәгалә рәхмәтенә ирешер; кыямәт көнендә оҗмахлы булыр, ди. Гомумән, мөэмин кешенең һәр эше ихластан булырга тиеш икәнлеге ассызыклана. Ихлассыз эшләнелгән эш беркайчан кабул булмас, лаеклы эш булмас. Ихлассызның бөтен эше дөнья өчен булыр, ди. Андыйлардан Мәүла Колый аерылырга һәм алардан ерак булырга куша.

Шагыйрь иманны зәгыйфьли торган нәрсәләргә дә игътибарны юнәлтә. Бу – гөнаһ эшләр. Гөнаһларның бик күп зарары бар икәнлегендә бернинди шик юк. Күп кенә борынгы мөселман галимнәре әйтүенчә, иман Аллаһка буйсыну аркасында арта, Аңа карышу аркасында кими. Мөхәммәд бине Салих әл-Госәймин исемле галим әйткән: «Иман аерым бер сәбәпләр аркасында кими. Гөнаһлар кылу иманны киметәләр. Гөнаһлар кабахәтрәк булган саен, иман ныграк кими. Шулай ук ике гөнаһ, бер гөнаһка караганда, аны ныграк зәгыйфьли[1]. Мәүла Колый да иманны зәгыйфьләүче бу фактордан халыкны ерак булырга чакыра. Шушы гөнаһларга әдип түбәндәгеләрне кертә: хәмер эчү, тәмәке тарту, зина кылу. Бу эшләр шул заманда күп халыклар арасында таралган була. Шуңа күрә татарлар да бу начар гадәтләрне үзләренә ала башлыйлар. Мәүла Колый акыллы, зирәк кеше буларак, бу гөнаһларның татар халкының иманы өчен никадәр куркыныч булганын тиз арада аңлый һәм бу эшләрдән үз халкын тыюны, кисәтүне үзенең бурычы итеп куя.

Хәмер эчүнең нәтиҗәсе бик аяныч булганын һәркем аңлый. Исерек килеш кеше, үзе дә аңламыйча, төрле эшләр кыла ала, шул исәптән имансыз калырга да мөмкин. Шуңа күрә ислам дине моны тыя. Коръәндә исерткеч эчемлекләр турында болай диелгән:

---

[1] Аль-Бадр А. Причины увеличения и уменьшения веры; пер. с араб. Э. Кулиева. М.: Умма. С. 75.

«Ий, мөэминнәр, исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннары һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү – Аллаһтан башка мәхлукларга табыну эшләре, шулай ук ырымланубагучылык эшләре хәрамдыр, шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер, һәлак булудан котылмаклыгыгыз өчен бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять, котылырсыз – өстенлек табарсыз» («Маидә» («Ашъяулык») сүрәсе, 90 нчы аять).

Мөхәммәд пәйгамбәрнең бу эштән тыюы хакында бик күп хәдисләрдә килә. Әгәр хәдисләрне җентекләбрәк тикшерсәк, чыннан да, хәмер эчкән кешенең иманы үзеннән-үзе юкка чыгуы һәркемгә аңлашыла. Бер хәдистә түбәндәгечә диелгән:

«Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән: зина кылучы зина кылганда, ул кеше мөэмин булып бу эшен кылмас, мөселман кеше хәмер эчкәндә бу эшен мөэмин булып кылмас, мөселман кеше урлаганда, ул бу эшен мөэмин булып кылмас»[1].

Бу хәдистән аңлашылганча, хәмер эчкәндә кешенең иманы чыгып тора икән, бу эшеннән туктагач кына аның иманы кире кайта. Димәк, Мәүла Колый бу хәдисләрне бик яхшы белгән һәм үз заманындагы чукындырулардан гарык булганга, хәтта бу эшләрне эшләп, вакытлыча гына булса да, үз халкының имансыз калуын теләмәгән.

Шагыйрь хәмер эчкән кешенең кырык көнгә иманы качар, ди. Әгәр шул вакытта үлеп китсә, ул имансыз килеш үлгән булып саналганын әйтә:

«Хәрамхур, мәстлек өчен, шәрап эчәр,
Белгел, андин кырык көнгә иман качар;

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз аль-Ибрагим», 2002. С. 308.

Ул арада, әҗәл килсә, гасый кичәр,
Мәст үлеп, андаг гасый була күрмәң»[1].

Хәмер эчү катгый рәвештә хәрам, аны эчкән кеше шайтан белән бергә тәмугта янар, ди. Хәмерне фәкать бик каты сусаган вакытта, су булмаганда бер тапкыр йоту хәләл булганлыгын да искәртә автор. Гомумән, хәмер эчүчеләр Мәүла Колый тарафыннан бик каты тәнкыйтьләнәләр. Алар иң явыз бәндәләр булып саналалар, хәтта аларны кешегә дә санамаска куша автор. Шулай ук, аларның сүзләрен тыңлама, йөзләренә карама, аларны дус тотма, үзләреннән еракка кач, дип үгет-нәсыйхәтләр бирә.

Тәмәке тартуга килгәндә, бу эшне дә хәмер эчү белән бер дип карарга мөмкин. Тәмәке ислам галимнәре тарафыннан шулай ук тыелган һәм гөнаһ эш булып санала. Тәмәке – шайтан эше һәм аны тарткан кеше пакь булмас, нәҗес кебек булыр, ди Мәүла Колый. Ул тәмәкенең 13 төре бар икәнен күрсәтә, аннан ерак булырга һәм башка мөэминнәрне дә бу эштән тыярга өнди:

«Тәмәкедин ерак булып, тот Хак юлын,
Тәгать кылып, Идигә мөэмин булың.

Тәмәкедин тыйгыл Хакның мөэмин колын,
Сәңа сәвап, Хак юлына килер булса»[2].

Зина кылу да бик зур гөнаһлардан санала. Коръәндә ул ачыктан-ачык тыелган:

«Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш вә бик яман кабахәт юлдыр» («Бәни Исраил» («Ягъкуб балалары») сүрәсе, 32 нче аять).

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 107.

[2] Шунда ук. Б. 46.

Алда карап үткән хәдистә дә зина кылган кеше иманлы хәлдә килеш зина кылмавы, зина кылганда кешенең иманы чыгып торуы турында әйтелгән иде. Шуңа күрә Мәүла Колый да бу зур гөнаһны кылудан катгый рәвештә тыя: зина кылучылар кыямәт көнендә сасы исле булып кубарылыр, бөтен галәм халкы алдында рисвай булып, бөтенесе аларны ләгънәт кылыр, ди. Аларның төрле газапларга дучар булуларын ассызыклый автор. Мәсәлән, елан-чаяннар аларның тәннәрен чагарлар һ.б. Шагыйрь, акыллы булсаң, бу эштән ерак тор, дип нәсыйхәтен бирә:

«Гакыйль ирсәң, зина эшен асан белмәң,
Зина кылма, Хакдин тәүбә-тәүфикъ teләң;

Тәүбә кылу, Хак эшенә билең баглаң,
Зиначыга терлек газап булыр дирләр»[1].

Аның бу кисәтүләре бик урынлы була. Чөнки автор яшәгән заманда татар морзалары үзләренең татар крестьяннарын бик нык мыскыл итәләр. Бигрәк тә христиан диненә кергән татар морзалары. Хәтта хатыннарын һәм кызларын көчләүдән дә тартынмыйлар. Бу фактлар крестьяннарның Шейдяковтан зарланып язган хатларында да чагыла: «Когда Шейдяков приехал в деревню, он тех крестьян, которые начали к нему приходить на поклон с хлебами, как у других помещиков, тех он начал бить, на ледник сажать, татарок начал к себе в постель брать..»[2].

Югарыда санап үтелгән гөнаһлар кешенең иманын бик нык зәгыйфьлиләр булып чыга. Ләкин бу гөнаһларны эшләүчеләргә

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. – Б. 108.

[2] Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей, как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии // Материалы по истории Татарии. Казань: Таткнигоиздат, 1948. С. 231.

автор дәвалану юлын күрсәтә. Бу – тәүбә итү. Тәүбә (*гар.* – яраксыз эшне эшләмәскә сүз бирү) – дини күзлектән караганда, кылган гөнаһлы эшләрең өчен үкенү, Аллаһның ярлыкавын сорау[1]. Мәүла Колый фикеренчә, тәүбә кылган кешенең гөнаһлары юкка чыгачак:

«Тәүбә кылсаң, гөнаһдин киткүседер,
Нуры рәүшан күкрәктә тапкусыдыр.

Тәүбә суы юса, гөнаһ киткүседер,
Гөнаһ татын юмага үзгә дәва юктыр»[2].

Ислам динендә тәүбә өч нәрсәне үз эченә ала:

1. Әлеге гөнаһны кылудан баш тарту.

2. Бу гөнаһны кылганына үкенү.

3. Аңа беркайчан да әйләнеп кайтмаска дип карар кылу.

Моннан тыш, әгәр дә бу гөнаһны кылу икенче мөселманга зарар кылу белән булган икән, китергән зарарны мөмкин кадәр түләргә тырышырга кирәк[3].

Коръәндә тәүбә хакында сөйли торган аятьләр бихисап:

«Дөреслектә, Аллаһ белмичә гөнаһ кылганнарның һәм тиз арада үкенгәннәрнең тәүбәләрен кабул итә. Чөнки Аллаһ – Белүче, Хикмәт Иясе» («Ниса» («Хатыннар») сүрәсе, 17 нче аять).

«Әй, иман китергән бәндәләр, Аллаһка эчкерсез тәүбә белән мөрәҗәгать итегез! Шунда Раббыгыз сезнең начар гамәлләрегезне гафу итәр һәм астыннан елгалар ага торган бакчаларга кертер» («Тәхрим» («Тыю») сүрәсе, 8 нче аять).

«Минем мөэмин бәндәләремә әйт: “Ий, бәндәләрем, гөнаһ кылып үзегезгә зарар иткән булсагыз, Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ гөнаһларны

---

[1] Ислам. Белешмә сүзлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. Б. 142.

[2] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 71.

[3] Хәкәми Х. Дини тәгълимат. Казан: РИУ, 2003. Б. 144–145.

ярлыкаучыдыр. Ул – Аллаһ ярлыкаучы, вә рәхимледер"» («Зүмәра» («Төркем») сүрәсе, 53 нче аять).

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән килгән хәдисләрнең күбесендә тиз арада гөнаһлардан тәүбә кылырга кирәклеге турында әйтелә. Бер хәдистә болай диелгән:

«Мөхәммәд галәйһиссәлам әйткән: «Куркыныч урында ашамлыклар һәм су төялгән дөясе белән бергә калган кеше башын нәрсәгәдер куеп йоклап китеп, уянгач дөясенең югалганын күрә. Шул вакытта ул эсселектән, сусаудан һәм Аллаһ теләгән башка нәрсәләрдән җәфалана. Әлеге кеше: «Мин элеккеге урыныма кайтам», – дип әйтә һәм кайтып, аз гына вакыт йоклап китә. Ә башын күтәргәч, дөясенең үз янында торганын күреп шатлана. Дөреслектә, Аллаһ үз колының тәүбәсенә әлеге кешедән дә күбрәк шатлана»[1].

Шул рәвешле, Мәүла Колый Коръән һәм хәдисләргә таянып, гөнаһларны бетерүдә тәүбәдән башка бернинди көч юк дип белдерә. Аның фикеренчә, тәүбә иткән кеше бүтән гөнаһларына кабат кайтмаска, киресенчә, үзен Аллаһы Тәгаләгә багышларга, кушканнарын үтәргә, тыйганнарыннан тыелып яшәргә тиеш. Шул вакытта гына аның иманы кире әйләнеп кайтачак, дип саный.

Тәүбә темасын Мәүла Колый юкка гына телгә алмый. Бу шул чордагы чукынучы татарларны күздә тотып язылган булырга мөмкин. Мәгълүм булганча, кайбер татарлар төрле сәбәпләр белән чукыналар. Үз диннәреннән ваз кичәргә мәҗбүр булган татарлар өчен шагыйрь тәүбә юлын күрсәтә. Тәүбә итеп яңадан үз диннәренә кайтсалар, Аллаһ аларның гөнаһларын ярлыкаячак дип әйтергә тели ул. Юкка гына аның

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. 2.. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз аль-Ибрагим», 2002. С. 352–353.

хикмәтләренең күп җирләрендә тәүбә турында язган юллар очрамый.

Халык, бәлки, аның сүзләрен ишетәдер, чөнки тарихтан күренгәнчә, күп кенә чукынган татарлар кире ислам диненә кайталар.

Мәүла Колый динне, милләтне саклап калуда зур роль уйнаган тагын бер факторны аерып чыгара. Бу исә – балаларны дөрес, ислам диненә муафикъ итеп тәрбияләү. Чөнки милләтне фәкать яшь буын гына саклап кала ала. Ул, үз чиратында, балаларга гыйлем бирүдә, аларны дин һәм милләт сакчылары итеп тәрбияләүдә чагыла. Автор аларга нәсыйхәтләр бирергә, Коръән буенча тәрбияләргә куша. Әгәр балаларың синең нәсыйхәтләреңне тыңласалар, ягъни дөрес тәрбия алып үссәләр, Аллаһы Тәгалә сиңа Үз рәхмәтен насыйп итәр, ди:

«Угыл-кыз Хак эшендин гыйбрәт алса,
Нәсихәтең тыңлый белеп, колак салса,

Дәһер ара нәсихәтең берлә йөрсә,
Хак гыйнаят кылып торыр, белмәк кирәк»[1].

Әгәр дә алар тәрбиясез булсалар, үз диннәрен белмәсәләр, ул вакытта яман кешеләр булып үсәчәкләрен кисәтә:

«Угыл-кыз нәсихәтең алмас ирсә,
Яхшы сүзең тыңлап колак салмас ирсә,

Сәҗдә өчен башын Хакга куймас ирсә,
Ул угыл-кыз тугды яман – белмәк кирәк»[2].

Балаларны остазларга биреп укыту да бик хуплана.

Шулай итеп, Мәүла Колый Аднаш хафиз күтәреп чыккан проблемаларны сурәтләүне дәвам итә. Кайберләрен ул нәкъ

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 67.

[2] Шунда ук. Б. 67.

Аднаш хафиз кебек үк тасвирлый. Аерма фәкать шунда гына: Аднаш хафиз аларны проза белән язса, Мәүла Колый поэзия белән яза. Ләкин шул ук вакытта Мәүла Колый аларны тулыландыра, өстәмәләр кертә, бу проблемаларны яңача чишү юлларын таба.

Мәүла Колый чукындыру сәясәтен алып барган залимнәргә карата үз мөнәсәбәтен нәкъ Аднаш хафиз «Сираҗел-колүб» әсәрендә күрсәткән ысул белән белдерә. Бу ысул – дошманнарны турыдан-туры каргау түгел, ә хайваннар сүзләре яки зикерләре аркылы бирү. Мөселман өйрәтүләре буенча, һәр хайванның үзенә хас һәм һәрвакыт әйтә торган зикерләре бар, дип санала. Шунысы кызык: бөтен хайваннарның зикерләре фәкать Аллаһы Тәгаләне мактау сүзләре булырга тиеш дип саналса да, Аднаш хафиз, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, кайбер хайваннарның зикерләрен кяферләрне, залимнәрне каргау һәм дога формасында күрсәтә. Ләкин бу сүзләр гарәп телендә биреләләр һәм тәрҗемә ителмиләр. Шул рәвешле дошманнарга карата үз мөнәсәбәтеңне белдерү ысулын Мәүла Колый да бик киң файдалана. Чөнки, беренчедән, турыдан-туры үзеңнең тискәре мөнәсәбәтеңне белдерү бик куркыныч булып саналса, икенчедән, рус чиркәве мондый әсәрләрне юк итеп барырга һәм аларны халыкка җиткерүне тыярга мөмкин булган.

Хәзер Мәүла Колый хикмәтләреннән кайбер хайваннарның зикерләрен карап үтик.

Ат тәсбихы:

«Илаһым әнсир – диер
Гыйбадәт әл-мөэминин
Галәл – кәфирин, Солтаным»[1].

---

[1] Колый, М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 59.

Тәрҗемәсе: «Илаһым, мөэминнәргә кяферләрне җиңәргә ярдәм ит», дигән җөмлә була.

Этләрнең тәсбихы:

«Этләр Хакны белерләр,
Зикер – сәна кылырлар,

Тәсбих әйтеп өрерләр,
Аять Коръән, Солтаным.

Илаһым, әгърәз вөҗүһ әш-шаятин,
Гән әл-мөслимин – дирләр,

Будыр анларның зикре,
Әйтер тәсбих, Солтаным»[1].

Тәрҗемәсе: «Илаһым, мөселманнарны шайтаннардан сакла», дигән җөмлә килеп чыга. Шайтаннар дип монда, иң беренче чиратта, дошманнар күздә тотылырга мөмкин. Чөнки алар, шайтаннар кебек, мөселманнарның иманнарын тартып алырга тырышканнар.

Шул рәвешле Мәүла Колый күп хайваннарның тәсбихларын әйтеп чыга, «Сиражел-колүб» әсәрендә күрсәтелмәгән хайваннарның да зикерләрен телгә ала.

Мәүла Колый, Аднаш хафиз кебек үк, ата-ана һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә туктала. Ул кайбер хикмәтләрен тулысы белән шушы проблемага багышлый. Ата-ана хакын хаклап аларга изгелек кылган кеше Аллаһның дусты була, ди:

«Һәр угыл-кыз ата-ананы белер булса,
Гыйззәт, хөрмәт берлә хезмәт кылыр ирсә,

Күңелене хушнуд кылып, дога кылса,
Ул угыл-кыз Хак дустыдыр, белмәк кирәк»[2].

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 59.

[2] Шунда ук. Б. 20.

Шагыйрь баланың ата-анасы алдында зур бурычлары булуы турында әйтеп, аларны ата-анага хезмәт күрсәтергә, аларны хөрмәт итәргә, һәр эштә алардан ризалык алырга, үгет-нәсыйхәтләренә колак салырга, каршы сүз әйтмәскә, берничек тә рәнҗетмәскә, ни кушсалар – шуны эшләргә чакыра. Ата-ананың догасы да, каргышы да бик тиз кабул булуы искәртелә:

«Ата-ана сүзе кабул булмас димәң,
Алкышы һәм каргышы килмәс димәң,

Монлар кылган дога сиңа булмас димәң –
Бу хәтәрдән, хәсрәт йотып тормак кирәк»[1].

Ата-анасын сүккән яки кулы белән рәнҗеткән кешегә карата Мәүла Колыйның мөнәсәбәте бик кискен һәм катгый:

«Ата-ананы угыл-кыз сүксә, белең,
Шәригатьтә кисмәк торур моның телен.

Кулы белән сугар булса, янә кулын
Буыныңдин кисмәк торып, белмәк кирәк»[2].

Мәүла Колый кайбер шигъри юлларын гарәп телендә бирә. Гадәттә, аларда ул рус чиркәве алып барган сәясәткә үзенең карашын белдерә. Мәсәлән:

«Хәсба рабби җәлләллаһү, һүвәллаһу,
Мафи кальби гайрилләһи, һүваллаһу;

Нур Мөхәммәд саллә салләлла, һүвәллаһу
Ля иляһә илля Алла, һүвәллаһу»[3].

Татар теленә тәрҗемәсе: «Раббым Аллаһ мине яклаучы буларак җитә, күңелем Аллаһтан бүтәннәр белән бәйле булган нәрсәләрдән арынсын. Мөхәммәд нуры, Аллаһның салаваты булсын аңа; Ул – Аллаһ, Аллаһтан башка илаһ юк, Ул – Аллаһ».

---

[1] Колый М. Хикмәтләр; төзүче, иске татар теленнән күчерүче һәм сүз башы язучы М. Гайнетдинов. Казан: Иман, 2000. Б. 20.

[2] Шунда ук. Б. 20.

[3] Шунда ук. Б. 113.

«Хәсби Рабби, хәсби Аллаһ, хәсбүнә Аллаһ», дигән сүзләр, гадәттә, дошман белән кара-каршы очрашканда әйтү традициясе буларак, Коръәннән үк килә. Бәдер сугышы алдыннан кешеләр мөселманнарны Мәккә мөшрикләре белән куркыталар. Моңа җавап итеп мөэминнәр бу сүзләрне әйтәләр. Коръәндә бу түбәндәгечә тасвирлана:

«Үтеп баручы кәрван кешеләре, мөселманнарга: “Мәккә мөшрикләре сезгә каршы күп гаскәр хәзерләгәннәр, куркыгыз алардан, сугышмагыз”, – диделәр. Мөшрикләрдән куркыгыз дигән сүз мөселманнарның иманын арттырды һәм алар әйттеләр: “Ярдәм йөзеннән безгә Аллаһ җитәдер, Ул ни хуш вәкилдер”, – дип» («Гыймран» сүрәсе, 173 нче аять).

Хәдистә бу сүзләрне Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләреннән башка Ибраһим пәйгамбәрнең дә, утка атылгач, әйткәнлеге күрсәтелә:

«Ибне Габбәс әйткән: “Хәсбүнә Аллаһ вә нигъмәл-вәкил” (“Аллаһ безгә ярдәм итүче буларак җитә, Ул ни хуш вәкилдер”) дигән сүзләрне, кяферләр тарафыннан утка атылгач, Ибраһим пәйгамбәр дә әйтә. Бу сүзләрне Мөхәммәд галәйһиссәлам дә, Мәккә мөшрикләре белән кисәтелгәч әйтә»[1].

Шулай итеп, без Мәүла Колыйның иҗатын тикшереп, аның Аднаш хафиз иҗаты белән бик охшаш икәнен күрдек. Аларның бер-берсенә якынлыгы, темалар уртаклыгы бу ике әдипнең бер үк максат куюлары белән аңлатыла. Максатлары исә татар халкына динен саклап калырга ярдәм итү, киңәшләр бирүдән гыйбарәт.

Аднаш хафиздан аермалы буларак, Мәүла Колый әсәрен шигырь белән биреп, үзенең киңәшләренең, үгет-нәсыйхәтләренең үтемлерәк кабул ителүенә ирешә. Ул татарларның үзе

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз аль-Ибрагим», 2002. С. 207.

яшәгән чорда килеп чыккан проблемаларын күрә белгән һәм милләттәшләре өчен психолог функциясен дә үтәгән.

## 2.2. XVIII гасыр татар әдипләре әсәрләрендә «Сираҗел-колүб» традицияләре

XIII гасыр башында ук татарларның диннәрен тартып алырга күпме генә тырышсалар да, аларда диндарлык үсә генә бара. Мәскәүнең чукындыру сәясәтен җәелдереп җибәрүе аркасында татар халкында мондый дини изүләргә каршы төп корал – ислам дине һәм аннан аерылып чыккан секталарыннан берсе – суфичылык була. Бу корал белән ни рәвешле файдаланырга икәнен халыкка үзенең татар укымышлылары өйрәтә. Алар үзләренең кирәкле үгет-нәсыйхәтләрен бик урынлы әйтеп яки язып татарларны милләт буларак юкка чыгудан саклап калырга ярдәм итәләр. Бу эш Аднаш хафиздан башланып китә һәм, эстафета кебек, әдипләрдән әдипләргә күчеп бара. Татарларга Казан җирләрендә яшәгән әдипләр генә түгел, хәтта бөтенләй читтә яшәгән милләттәшләре дә, кулларыннан килгәнчә, рухи яктан ярдәм итәргә ашкынганнар. Шулардан Урта Азиядә яшәп иҗат иткән Суфи Аллаһиярны атарга мөмкин.

Суфи Аллаһияр – этник чыгышы белән нугай татары. Кайбер чыганакларда аның нәсел-нәсәбенең Әстерхан төбәгеннән булуы да искәртелә. Мөгаен, шагыйрьнең әби-бабалары, күп кенә татарлар кебек, Казан, Әстерхан ханлыклары бетерелгәч, Урта Азиягә күчеп яисә эзәрлекләүләрдән качып киткәннәрдер[1].

Шагыйрь Урта Азиядә яшәсә дә, Казан җирләрендәге татарлар хәлен, ягъни аларның көчләп чукындырылуларын бик

---

[1] Ялчыгол, Т. Рисаләи Газизә; төзүче Х.Й. Миңнегулов. Казан: Иман, 2001. Б. 18.

яхшы белә. Чөнки, анда күченеп килгән татарлар күп була. «...Явыз Иван тарафыннан Казан ханлыгы (1552) һәм Әстерхан ханлыгы (1556) яулап алынганнан соң, көче җиткән һәм динен саклап калырга тырышкан татарлар, шәригать таләбенә буйсынып, Урта Азия якларына һиҗрәт кылганнар, мөһаҗир булганнар һәм үзләренә сыену урыны тапканнар. Ул вакытларда Бохара, Сәмәрканд җирләре төрле әмирлекләргә бүлгәләнеп беткәнлектән, татарларга азатлыкларын кайтарып алуда алар ярдәм итә алмаганнар. Әмма үз яннарына дин кардәшләрен сыйдырганнар, аларга җирләрен дә бүлеп биреп, газиз туфракларыннан өлеш чыгарганнар. Шунысына рәхмәт! Ул гына да түгел, төрле түрәлек эшләрен дә татарларга йөкләгәннәр, аларга ышанып караганнар.

Шундый мөһаҗирләрдән Сәмәрканд янында Миңлән авылы оешып китә. Татарларның динле һәм иманлы булулары аркасында, җирле халык аларга хөрмәт белән карый, авыллары белән үзләрен изгеләрдән күрә», – дип яза Фәрит Яхин[1].

Шулай ук Суфи Аллаһиярның Казанга килүе дә мәгълүм. Ул хаҗ кылырга ниятләп, Казан ягына таба юл тота. Болгар шәһәрен һәм җирләрен зиярәт итә, Казанга килеп татар укымышлылары, галимнәре белән очраша. Риваятьләрдән аңлашылганча, канкардәшләрен дә таба. Казанда Суфи Аллаһияр үзенең «Сөбател-гаҗизин» әсәрен калдырып китә[2]. Шул сәбәпле, бу әсәрен ул нәкъ менә татарларның авыр хәлен белеп, аларга рухи яктан ярдәм итү йөзеннән язгандыр, дигән караш та туа.

«Сөбател-гаҗизин» әсәрендә әдип иман китерү һәм иманлы булуның өстенлекләре хакында бик күп яза, иманлы килеш дөньядан үтүнең ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген күрсәтә. Бу,

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 7.

[2] Шунда ук. Б. 12.

нигездә, ахирәт белән бәйле нәрсәләр турында язганда чагыла. Кеше үлеп кабергә куелгач, аннан сорау алуларын сурәтли автор[1]. Менә шунда инде имансыз кеше кабер газабын татый башлаячак икән, чөнки ул сорау алучы фәрештәләрнең сорауларына мәңге җавап бирә алмаячак:

«Орырлар гөрзи берлән ул ике яр,
Ишетер әсәү-җендин үзгә җандар.

Аларның зарбыга тап итмәгәй таг,
Ничек такать кылыр бер мәште тупрак?»[2]

Инде шушы юллардан ук Суфи Аллаһияр укучыда имансыз килеш үлүдән көчле курку тудыра. Монда аның гаять оста итеп язу таланты күренә. Язганы, туры атылган ук кебек, көчәя һәм төз очып, йөрәкләргә барып җитә.

Дөрес, кайбер гөнаһлы мөэминнәрне, алар кабер газабына дучар булачакларын танысалар да, автор Аллаһы Тәгаләне бер дип таныган кешенең никадәр гөнаһлары күп булса да, кабер газабыннан котылу чарасы бар икәнлегенә ышандырырга тырыша. Чөнки иманлы кешене Аллаһның ташламавын, киресенчә, Үз рәхмәте астына алачагын һәм кыямәт дәһшәтләрен җиңел үтәргә булышачагын белдерә[3].

Суфи Аллаһияр үзен зур гөнаһлы икәнлеген таныса да, барыбер Аллаһ Тәгаләнең аңа бу сорауларны җиңел кылачагына, ярдәм итәчәгенә өметләнә. Чөнки аның бер зур яхшы сыйфаты бар, ул – иманлы булуы:

«Әгәрчә мән яман кол пае та фәркъ,
Булыпмын мәгъсыять дәрйасегә гарк.

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 243–245.

[2] Шунда ук Б. 243.

[3] Шунда ук. Б. 248.

Вә ли садәкъ ирер мән берелегенә,
Таяныпмын мән сәнең көферлегенә»[1].

Мәхшәр көнендә бәндәләргә гамәлләре язылган китаплары йә уң яктан, йә сул яктан, йә аркасыннан бирелүләрен дә автор тәфсилләп яза. Уң яктан китабы бирелгән кеше бик нык сөенәчәк, чөнки аның урыны җәннәт булачак. Әгәр дә китабы сул ягыннан яки аркасыннан бирелсә, ул кеше, кара йөзле булып, оятка калачак, муенына богаулар салынып, чылбырлар белән уралып йөзтүбән тәмугка атылачак икән[2]. Суфи Аллаһияр әсәрендә Аллаһтан бу гамәлләр китабын үзенә уң ягыннан бирелүен үтенә, чөнки ул Аның каршында үзенең кол булуын таный һәм иң мөһиме, ул – Мөхәммәд пәйгамбәрнең өммәтеннән.

«Әгәрчә намөнасыйп мән, яман мән,
Үзең әйдең: «Колымга миһербан мән!»

Әгәр чәнде ки булсам зәмде бәдкәр,
Хәбибем өммәте мән, кол атым бар!»[3]

Димәк, автор фикеренчә, Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтеннән булган кеше генә газаплардан имин булып, җәннәткә кертеләчәк, ә бу өммәттән булмаган кеше, киресенчә, газапланачак, тәмугка кертеләчәк. Шул рәвешле, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның өммәтенең башка өммәтләрдән өстенлеге бирелә.

Суфи Аллаһияр кыямәт көнендә кешенең гамәлләрен үлчәүләре турында да яза. Белгәнебезчә, әгәр дә бәндәнең яхшы гамәлләре авыр булса, ул оҗмахлы булачак, начар гамәлләре

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 244.

[2] Шунда ук Б. 247.

[3] Шунда ук. Б. 248.

авырга килсә, тәмуглы булачак. Шагыйрь яхшы гамәлләрнең фәкать иманы сәламәт булган кешеләрдә генә авыр булачагын белгертә:

«Илаһи, кыл агыр мизанымызны,
Сәламәт тот безең иманымызны»[1].

Моның шулай буласын турыдан-туры әйтмәсә дә, шушы икеюллыктан укучыга моның нәкъ шулай икәнлеге бик ачык аңлашыла.

Сират күперен үтү процессын да әдип бик оста итеп сурәтли. Ул аның бөтен дәһшәтен күләме әллә ни зур булмаган шигъри юллар белән тасвирлап бирә. Аны кяфер кешеләрнең беркайчан үтә алмаячакларын, ә мөселманнарның, тая-тая булса да, барыбер үтәчәкләрен яза[2]. Суфи Аллаһияр Аллаһның аны бу сират күпереннән үткәрәчәгенә өметләнә, чөнки аның иманы бар:

«Әгәрчә саны юк гыйсъян кылыпмыз,
Өмид ул кем, сәне Вахид белепмез.

Илаһи, берлекеңнең хөрмәтендин,
Сәламәт кыл у күпрүк михнәтедин»[3].

Кыямәт көненең дәһшәтле мизгелләрен дә Суфи Аллаһияр бик куркыныч буяулар белән, оста итеп тасвирлый. Шундый авыр һәм куркыныч вакытта мөселманнарга ярдәмгә Мөхәммәд пәйгамбәрнең килүе сурәтләнә. Ул үзенең өммәте өчен шәфәгатьче, яклаучы булачак, башка пәйгамбәрләр исә фәкать үзләре өчен генә кайгыртачаклар[4]. Шул сәбәпле, иманлы булу

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 249.

[2] Шунда ук Б. 250–251.

[3] Шунда ук. Б. 251.

[4] Шунда ук. Б. 253–255.

аркасында Мөхәммәд галәйһиссәлам яклавы астына керүен белгәч, әлбәттә, укучы кыямәт дәһшәтен җиңел үтәр өчен бу дөньяда иманы хакында бик нык кайгырта башлаячак. Әдип нәкъ менә шуңа омтыла да инде.

Җәннәт белән тәмуг бәянында Суфи Аллаһияр кяферләрнең урыны тәмуг булуын (әсәрдә автор тәмугны «дузах» дип бирә), анда бик каты газапланачакларын сурәтли:

> «Керер дузахга кяфер, кайта улмас
> Газабы сохтедин һәргәз котылмас»[1].

Мөэмин бәндәнең, никадәр гөнаһлы булса да, ахыр чиктә, иманлы булганлыгы аркасында, оҗмахка кертеләчәге ассызыклана:

> «Һәмишә калмагай иманлы бәндә,
> Тотар ахыр кулын иманы анда»[2].

Шулай ук:

> «Әгәр чәнди кәбаир кылса бихәд,
> Тәмугда калмас иманлы мүәббәд»[3].

Шулай итеп, Суфи Аллаһияр, нәкъ Аднаш хафиз кебек үк, иманның никадәр дәрәҗәдә кадерле һәм кирәк икәнлеген укучы күңеленә сеңдерә. Иманның фазыйләтләре турында язу Аднаш хафиздан соң бер традиция буларак формалашып китә һәм һәр әдип нинди генә әсәр язса да, бу теманы яктыртмыйча кала алмый.

Суфи Аллаһияр да, Аднаш хафиз кебек, көчләп чукындыру сәясәтенә каршы нәрсә эшләргә, нинди чаралар күрергә,

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин.– Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 256.

[2] Шунда ук Б. 256.

[3] Шунда ук. Б.

халыкка үз-үзен ничек тотарга кирәк дигән сорауларга җавап эзли. Аның фикеренчә, бу бәлаләргә сабыр итеп, бер Аллаһка гына тәвәккәл кылып, дошманны корал белән түгел, ә яхшы әдәп-әхлак белән җиңәргә чакыра. Чөнки бу авырлыклар барысы да Аллаһы Тәгалә тәкъдире белән кешеләрне сынар өчен килгән һәм моңа риза булу мөэмин кешенең бурычы, дип аңлата:

«Зарурдыр, нәфәгъдер, йә хәйрү-шәрдер,
Якын белгел-каза берлә кадирдыр»[1].

Аллаһы Тәгалә ни теләсә, шуны эшләр, шуңа күрә ах-вах килеп зарланып, ризасызлык белдереп йөрүдән мәгънә юк, ди. Тәкъдиреңә риза булудан башка берни эшли алмыйсың, хәтта башыңда тегермән ташы йөрсә дә, каршы була алмыйсың, ди. Әгәр кеше язмышына риза булса, аждаһага да шөкер итәчәк икәнен сөйли[2]. Моны Суфи Аллаһияр кешенең тәне дә, җаны да аның үзенеке түгел, ә Аллаһыныкы булуы белән аңлата[3]. Әдипнең фикерләре барысы да фатализм белән бәйләнгән.

Тәкъдиргә ышану ислам фәлсәфәсенең нигезе булып тора. Коръәндә әйтелгән:

«Кайгы, бәла-каза ирешмәде, мәгәр Аллаһының теләге белән генә иреште («Тәгабүн» («Алдану») сүрәсе, 11 нче аять).

«Җирдә вә үзегезгә бәла-каза ирешмәде, мәгәр ирешә икән – ул Ләүхел-Мәхфузда язылгандыр, ул бәла-казаны яратуыбыздан элек, тәхкыйк бу эш Аллаһка бик җиңелдер» («Хәдид» («Тимер») сүрәсе, 22 нче аять).

Тәкъдир мәсьәләсен дөрес аңламау аркасында VIII–IX гасырларда бик күп бәхәсләр килеп туа һәм төрле дини агымнар

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002.

[2] Шунда ук. Б. 273.

[3] Шунда ук. Б. 275.

барлыкка килә. Җәбәритләр дип аталган агым, барысы да Аллаһ кулында, кешенең бернинди иреге юк, бернәрсә эшли алмый, дип уйлыйлар. Алар агачтагы яфрак кебек – кайсы якка җил иссә, шул якка авышалар. Икенче кырыйда кадәритләр агымы тора. Алар фикеренчә, кеше үзе барысын эшли, Аллаһ аңа берничек тә комачауламый. Ләкин күпчелек дин галимнәре бу ике карашның уртасында торалар һәм бу юл дөресрәк булып санала. Кеше үзе теләгән нәрсәсен эшли ала, сайлау иреге бар, ләкин Аллаһ бу эшкә риза булмаса, кеше берни эшли алмый, дигән караш ислам динендә киң таралыш алган. Тәкъдиргә ышану – язылып куелган яхшылыкка илтүче һәм язылып куелган начарлыктан тыючы бераллалылыкның һәм шәригатьнең башлангычы булып тора. Бары тик тәкъдиргә ышанган һәм шәригать кануннарын үтәгән кешенең генә дине дөрес һәм туры була ала. Моңа дәлил итеп түбәндәге хәдисне китерергә мөмкин. Бер кеше пәйгамбәр галәйһиссәламнән: «Безгә гамәлләрдән баш тартып, тәкъдирдә язылганга гына таянырга кирәкме?» – дип сорагач, ул әйткән: «Гамәл кылыгыз, чөнки һәрберегезгә үзе ни өчен яратылган булса, шуны кылу җиңеләйтеләчәк» (Бохари, Мөслим).

Шулай итеп, ул шәригать белән туры килми дип тәкъдирне инкарь итүче кеше Аллаһны гыйлем, кодрәт кебек сыйфатларыннан мәхрүм итә һәм бәндәне үз гамәлләрендә ирекле дип белдерә. Мондый кеше Аллаһ белән беррәттән тагын яратучы бар дип таный.

Икенче яктан, тәкъдирне танып, аны шәригатькә каршы кулланучы, кешене гамәл кылуга сәләтсез, сайлау иреге юк, дип санаучы, Аллаһ бәндәләренә кулларыннан килми торган эшне йөкләгән, дип санаучы Аллаһы Тәгаләгә гаделсез дип яла яга, аның имамы Иблис була»[1].

---

[1] Хәкәми Х. Дини тәгълимат. Казан: РИУ, 2003. Б. 144–145.

Суфи Аллаһиярның дини карашлары җәбәритләрнеке, кадәритләрнеке белән тәңгәл килми. Ул тәкъдир мәсьәләсендә урталыкта тора. Ул язмышка буйсынырга куша һәм шул ук вакытта диннән ваз кичмәскә, моны булдырмауда кулдан килгән бөтен чараларны кулланырга чакыра. Кулдан килә торган чараларга нәкъ менә сабыр итү, Аллаһка тәвәккәл кылулар кирә дә инде.

Шагыйрь «Сөбател-гаҗизин» әсәрендә бик оста чагыштыру кулланып кешеләргә бик акыллы киңәшен бирә:

«Сүнәр гамь төшсә һәм азадә иргә,
Очар ут төшсә хәсдин хали йиргә»[1].

Ягъни, ут буш һәм чүпсез җиргә төшкәч сүнгән кебек, язмышына риза булган иргә бәла-казалар килсә, юкка чыгарлар, ди. Шуңа күрә, беркайчан да зарланырга ярамый, киресенчә, кайгыларны, авырлыкларны сабырлык белән, риза булып каршы алырга кирәк икәнлеген әйтә:

«Бәла укы кадалса, ормагай аһ,
Кылыч башыга килсә, бозмагай раһ»[2].

Суфи Аллаһиярның бу фәлсәфәсе гаять кыйммәтле һәм кызыклы.

Кем дә кем язмышына риза булмый, каршы чыга икән, ул кешедә көферлек булуын белдерә. Андый кеше, аның фикеренчә, бөтенләй «бәндә» дип аталырга хокуклы түгел, ди[3].

Суфи Аллаһияр, яманлыкка һәрвакыт яхшылык белән җавап бирергә кирәк, дигән идеяне алга сөрә. Халыкны төрлечә мәсхәрәләгән, рәнҗеткән, иманын тартып алыр өчен җәзалаган

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 273.

[2] Шунда ук.Б. 275.

[3] Шунда ук. Б. 364.

залимнәргә карата яхшылык белән җавап биргәндә генә җиңүгә ирешеп булачагын ассызыклый автор:

«Әгәр типсә сәне һәркайсы мәүҗүд,
Зыян итмә, тәкый тигер аңа сүд.

Йөрәкнең кылсалар аһән илә чәк,
Чыкар алдыга төрлек нигъмәте пакь»[1].

Үзенең бу сүзләренең хак икәненә инандыру өчен Суфи Аллаһияр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлыннан үрнәкләр күрсәтә. Бервакыт Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең сәхабәләре белән булганда Гомәр аңа: «Бу кяферләр бөтенесе дә кырылып бетсен өчен Аллаһка дога кыл әле!» – дип үтенә. Чөнки пәйгамбәр үзе дә, сәхабәләре дә кяферләрдән бик күп явызлыклар күргән булалар һәм бүтән түзәр чамалары калмаган була. Әмма Мөхәммәд галәйһиссәлам кяферләрне каргап түгел, ә, киресенчә, Аллаһтан аларның ислам динен кабул итүләрен сорап дога кыла. Аллаһы Тәгалә аның догасын кабул итә һәм шул Мәккә мөшрикләренең юлбашчылары булган Әбү Суфьян һәм Халит, соңрак, ислам динен кабул итәләр. Алар аркасында дин бик күп җирләргә тарала. Халит бик күп сугышларда катнашып, меңләгән кяферләрне тар-мар итә, бөтен сугышларда җиңүче булып чыга. Әбү Суфьян җитәкләгән гаскәр Кытайның кайбер җирләрен, Гыйрак, Дәмәшкъ, Шам илләрен яулап ала[2]. Шушы вакыйгаларны искә алып, әдип татар халкына илбасарлар белән үзләрен ничек тотарга кирәклеген күрсәтә.

Шулай ук Суфи Аллаһияр тагын бер вакыйганы үрнәк итеп китерә. Бервакыт Гавани бер диндарга очрап, аның белән сөй-

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 371.

[2] Шунда ук. Б. 373.

ләшеп китәләр. Соңыннан ачуы чыгып, ул диндарның йөзенә камчысы белән суга. Шунда теге кеше дога кыла: «Йә Хода, моны туры юлга күндер, аны газаплама, яхшылык күрсәт!» Бу сүзләрне ишетүгә, Гавани йөзен җиргә куеп елый башлый, гөнаһларыннан тәүбә итә һәм ислам диненә керә[1].

Шул рәвешле, Суфи Аллаһияр, дошманыңа яхшылык күрсәтсәң, сабыр итсәң һәм аның өчен дога кылсаң, ул синең дустыңа әверелер, дигән идеяне алга сөрә.

Әдип золымлыкны, залимнәрне күралмый. «Сөбател-гаҗизин» әсәрендә залим кешеләр һәрвакыт тәнкыйтьләнәләр, хәтта аларның яшәргә хокукы юк кебегрәк сүзләр дә очрый:

«Терек йөргәнчә залим – үлгәне хуб,
Гөнаһдин һәрнәчә кем булганы хуб»[2].

Хәҗәҗ исемле залим патша турындагы хикәяттә бер суфи патшага түбәндәге сүзләрне әйтә:

«Гөнаһың кәм булыр, үлсәң әгәр тиз,
Китәр залимың аларның башыдин низ»[3].

Ләкин мөэмин бәндә өчен залим кеше бернинди куркыныч тудырмый. Чөнки ул аның золымына түзеп, фәкать әҗер-саваплы гына була икән:

«Әгәр тары кеше золмитсә тартар,
Вә ли мәзлум дигәнне әҗре артар»[4].

Мондый фәлсәфә ислам динендә киң чагылыш тапкан. Мөселман өйрәтүләре буенча, мөэмин кеше рәхәтлек күрсә,

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 374–375.

[2] Шунда ук. Б. 284.

[3] Шунда ук. Б. 285.

[4] Шунда ук. Б. 284.

ул моңа шөкер итеп, әҗер-саваплар ала; михнәт, золымлык күрсә, сабыр итеп, әҗер-саваплар ала, бу гына түгел, авырлыклар сәбәпле газапланса, аның хәтта гөнаһлары бетә. Болар турында Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләрендә өйрәтеп калдырган:

«Мөселман белән нәрсә генә булмасын, авырса, алҗыса, кайгырса, берәр төрле бәхетсезлеккә юлыкса, хәтта чәнечке кадалса да, Аллаһ шуның өчен аның гөнаһларын ярлыкар»[1].

Бер хәдистә түбәндәге очрак тасвирлана:

«Бервакыт Габдулла бине Мәсгуд Мөхәммәд пәйгамбәр янына керә. Ул авырып яткан була. Габдулла аннан сорый: «Нинди көчле икән синең чирең! Сиңа икеләтә әҗер-савап язылганга бу шулаймы?» Мөхәммәд галәйһиссәлам җавап бирә: «Әйе, Аллаһ берәр мөселманга авырулар, газаплар бирсә, аның гөнаһлары агачтагы яфраклар кебек коелып бетәр»[2].

Суфи Аллаһияр фикеренчә, мөселман кешене үлем дә куркытырга тиеш түгел, чөнки бу дөнья фани һәм бик тиз үтеп китүчән. Дөньяга ябышып ятучыны, дөнья артыннан куучыны ул үрмәкүч белән чагыштыра. Үрмәкүч җепләр үреп, тырышып үзенә оя кора, әмма кеше, йортын чистартам дип, ул ояны сибереп тарата, юк итә. Шуның кебек, кешенең дә бөтен дөньясын Аллаһы Тәгалә теләсә кайчан «сибереп» юк итәргә мөмкин, ди автор[3]. Ул дөньяга үлмим дип ябышып ятучыларга көлеп карый.

Суфи Аллаһияр татар халкына тагын бер нәсыйхәтен әйтә, ул да булса – һәрвакыт Аллаһка тәвәккәллек кылырга:

---

[1] Сахих аль-Бухари / Пер. В. Нирша. В двух томах. Т. 2. М.: Благотворительный фонд «Ибрагим бин Абдулазиз аль-Ибрагим», 2002. С. 313.

[2] Шунда ук. С. 314.

[3] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 345.

«Йитәр ахыр тәүвәккәл әйләгән кол,
Тәүвәккәл кыл, тәүвәккәл кыл, тәүвәккәл»[1].

Тәвәккәл – бөтен эшеңне Аллаһы Тәгаләгә генә тапшыру. Аллаһ тәвәккәл кылган бәндәсенә сораган нәрсәсен бирер, ди. Аднаш хафиз кебек, әдип монда да, Аллаһы Тәгаләдән ярдәм көткән кешегә Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләр ярдәмгә килер, дип ышандыра. Аллаһка тәвәккәл кылган кешенең юлына аждаһа очраса да, ул котылыр:

«Үтәрдә аждар агзын сөрсә паең,
Зыян итмәс, аман итсә Ходаең»[2].

Бәлки, аждар (аждаһа) образы аша автор залим рус миссионерларын күздә тотып әйтәдер һәм тәвәккәллек булганда алар татарларга зыян итә алмаслар, дип ышандырадыр.

Шулай ук:

«Тәүвәккәлдин кеше кәм алса бәһрә,
Качан зәһрә улыр гарык, булса зәһрә»[3].

Шул рәвешле, тәвәккәл кылган кеше агуда батса да, куркып калмас, ягъни нинди генә авыр ситуациягә эләкмәсен, ул Аллаһы Тәгаләгә ышануы, Аңа бар эшләрен тапшыруы аркасында, һәрвакыт аның яши торган җире дә җәннәткә әверелер, ди.

Суфи Аллаһияр иҗатында бик мөһим тагын бер юнәлеш бар. Ул – Мөхәммәд пәйгамбәрдән шәфәгать, ярдәм сорау. Ислам динендә кыямәт көне башлангач, Мөхәммәд пәйгамбәрнең үз өммәте өчен шәфәгать кылачагы турында мәгълүмат бар. Ләкин ул шәфәгатьне Аллаһ теләгән бәндәсенә генә насыйп итәр. Коръәндә бу турыда түбәндәгечә әйтелгән:

---

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 315.

[2] Шунда ук. Б. 315.

[3] Шунда ук. Б. 317.

«Алар Аллаһ риза булган кешегә генә шәфәгать итәрләр» («Әнбия» («Пәйгамбәрләр») сүрәсе, 28 нче аять).

Димәк, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд пәйгамбәргә Үзе теләгән кешеләргә генә шәфәгать кылырга рөхсәт бирәчәк. Шуңа күрә, мөселманнар Мөхәммәд галәйһиссәламнең шәфәгатен Аллаһтан сораганнар. Чөнки пәйгамбәр үзе берәр кешегә шәфәгать итәргә теләсә дә, Аллаһ моңа риза булмаса, ул кешегә аның шәфәгате ирешмәс. Шул сәбәпле, Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзеннән, ул исән вакытта да, үлгәч тә, беркайчан шәфәгать сорамаганнар. Чөнки Аллаһ моны тыйган һәм бу ширек гамәл булып санала һәм Аллаһтан башка бүтән заттан ярдәм сорау була.

Ләкин Суфи Аллаһияр шәфәгатьне турыдан-туры Мөхәммәд пәйгамбәрдән сорый:

«Йа, Расүлуллаһ, гөнаһы күп бу гасый бәндәне,
Кыл кәрам берлә шәфәгать бәхрене мәңа рәван.

Йа, Рәсүлуллаһ, кәрам берлә мәңа лотфы әйләгел,
Кәчә вә көндез мәне күңлемдәдер сән би гөман.

Йа, Рәсүлуллаһ, бәнем бәрдем карарым фалымдай,
Дәрдемә кылгыл дәвасын сән Шәфигы миһербан!

Йа, Рәсүлуллаһ, гыйнаять кыл висалеңә мәне,
Җанымы корбан кылаин һәмчу Исмәгыйь рәван»[1].

Суфи Аллаһияр, безнең әдипләрдән беренче булып, Мөхәммәд галәйһиссәламгә турыдан-туры мөрәҗәгать итә. Моңа хәтле татар әдәбиятында бу бик үк ачык чагылмый. Ул фәкать XVIII гасырда киң таралыш ала. Мәсәлән, XVIII гасыр шагыйрьләре Габдрахман бине Туймөхәммәд Тайсугани, Локман, Габделмәннан Мөслимов һәм башкалар әсәрләрендә

[1] Аллаһияр С. Сөбател-гаҗизин (Гаҗизләргә терәк); басмага әзерләүче, кереш мәкалә һәм аңлатмалар авторы Ф.З. Яхин. Казан: ТаРИХ, 2002. Б. 389.

турыдан-туры Мөхәммәд пәйгамбәргә мөрәҗәгать итеп, Аллаһтан сораган кебек ярдәм итүен сорап, аны Аллаһ кебек мактап язалар.

Моны илдәге христианлык сәясәте, колониаль изү, рухи һәм матди яктан кысу белән аңлатып була. Әдипләр һәрвакыт Аллаһтан ярдәм көтәләр. Хәлләре һаман катлаулана баргач, инде алар ярдәм итүен сорап Мөхәммәд галәйһиссәламгә дә мөрәҗәгать итәләр. Кешеләр инде нишләргә белмичә Аллаһтан да, пәйгамбәрләрдән, фәрештәләрдән дә ярдәм эзлиләр һәм тагын кемгә ярдәм сорап мөәрәҗәгать итәргә белмиләр. Халыкның мондый дәрәҗәгә җитүе аның нинди каты авырлыклар, кайгылар кичергәнен аңлата.

Иң бөек шәфәгать кыямәт көнендә кешеләрнең Аллаһның үзләре турында карар чыгарганын көтеп, басып торган вакытларында булачак. Кешеләр үз тирләренә батып, сулый алмый башлагач, Аллаһ үзләре турында карар кабул итсен дип, шәфәгатьче эзли башлыйлар. Алар башта Адәмгә, аннары Нухка, Ибраһимга, Мусага, Гайсәгә мөрәҗәгать итәчәкләр. Аларның һәрберсе: «Мин үзем, мин үзем» (ягъни үзем дә шәфәгатькә мохтаж), – дип әйтәчәкләр. Аннан соң Мөхәммәд галәйһиссәламгә киләчәкләр һәм ул Аллаһка шәфәгать сорап мөрәҗәгать итәргә ризалык белдерәчәк (Бохари, Мөслим)[1].

Хәдистән аңлашылганча, бу шәфәгать кыямәт көнендә генә булачак. Ләкин татар әдипләре моңа бик игътибар итмиләр һәм бу дөнья эшләре өчен дә, кяферләрдән яклавын сорап пәйгамбәр рухына турыдан-туры мөрәҗәгать итә башлыйлар. Хәтта аңлавы да кыен була: алар Аллаһка мөрәҗәгать итәләрме яки Мөхәммәд галәйһиссәламгәме? Фәкать контексттан чыгып кына моны ачыклап була. Татарлар арасында бу традицияне Суфи Аллаһияр башлап җибәрә дияргә мөмкин.

---

[1] Хәкәми Х. Дини тәгълимат. Казан: РИУ, 2003. Б. 120–121.

«Сөбател-гаҗизин» әсәре татар халкының яратып укылган әсәренә әверелә. Чөнки ул татарларның зәвык-ихтыяҗларына нигезләнеп язылган. Авторның максаты халыкка динен саклап калуда рухи ярдәм итү, үзенең моңа карата фикерләрен, киңәшләрен бирү була. Бу әсәрне аңламаган кеше, әлбәттә, шагыйрьнең киңәшләрен, идеяләрен дә аңламыйча кала. Чөнки «Сөбател-гаҗизин» әсәрендә аз сүз белән күп мәгълүмат бирелә һәм ул шактый әзерлеклелек һәм акыл белән фикерләү таләп итә. Шуңа күрә бу әсәргә бик күп шәрехләр, аңлатмалар язылган.

Таҗетдин Ялчыгол исемле кеше дә аңа шәрех яза һәм бу хезмәтен «Рисаләи Газизә» дип атый. Ул да халыкта бик популяр була, аны рухи яктан азыкландыруда мөһим роль уйный. Таҗетдин Ялчыголның бу әсәре «Сөбател-гаҗизин» әсәренең эчтәлеген биреп кенә калмый, аны күңел казанында кайнаткан, зиһене аркылы уздырган, үзенең күп кенә белем-мәгълүматын, фикер күзәтүләрен, уйлануларын бәян иткән.

«Сөбател-гаҗизин» һәм «Рисаләи Газизә» әсәрләре Аднаш хафизның «Сираҗел-колүб» әсәре белән идеяләр, сюжетлар ягыннан охшаш. Бигрәк тә «Рисаләи Газизә» әсәре. Бәлки, Таҗетдин Ялчыгол Аднаш хафизның әсәре белән таныш булгандыр һәм дини гыйлемен бу китаптан алып, аны «Рисаләи Газизә» әсәрендә биргәндер. «Рисаләи Газизә» үзе дә, күпмедер дәрәҗәдә, «Сираҗел-колүб» әсәренең шәрехен хәтерләтә.

Казан ханлыгы яуланып алынганнан соң, татар халкы арасыннан күтәрелеп чыккан укымышлылар киңәшче ролен үти башлыйлар. Алар халыкка динен, милләтен саклап калыр өчен, үз әсәрләрендә акыллы киңәшләрен биреп баралар. Чөнки халык моңа бик мохтаҗ була. Аднаш хафиз, Мәүла Колый, Суфи Аллаһияр һ.б. әдипләр көчләп чукындыру сәясәтенә ничек каршы торырга кирәк икәнлеген ачык күрсәтәләр.

Аларны бер нәрсә берләштерә, ул да булса – бу авырлыкларны, проблемаларны сабыр итеп, чыдам булып, Аллаһка тәвәккәл кылып, тыныч юл белән чишәргә кирәк, дигән караш.

XVIII гасырда кайбер татар укымышлыларының бу карашлары үзгәрә. Алар бу авырлыкларны җиңәр өчен бөтенләй капма-каршы юлны күрсәтәләр. Бу – радикаль юл, ягъни корал белән каршы тору. Татарлар тыныч юл белән динен, милләтен сакларга тырышты, ләкин хәлләре үзгәрмәде, киресенчә, һаман проблемалары арта һәм көчәя генә барды. Халыкның инде түзәр чамасы калмагач, кайбер татар укымышлылары халыкны корал белән каршы торырга өнди башлыйлар. Алар киңәшләрен, фәтваларын һәрвакыт шәригать ягыннан чыгып, дингә муафикъ булган рәвештә биргәннәр. Шәригать татарларга килгән мондый сынаулар вакытында нишләргә, дигән сорауга җавап биргәндә, сабыр итәргә, бирешмәскә, Аллаһка таянырга кирәк, дигән җаваплар бирә килде. Ләкин шәригатьтә тагын бер юл бар икәнлегенә игътибар итә башлыйлар. Бу юл – залимнәргә каршы «изге сугыш» игълан итү. Татар галимнәре һәрвакыт низагларны бетерү өчен диндә тәкъдим ителгән радикаль булмаган юлларны сайлаганнар, тынычлыкка омтылганнар. Моның белән алар, мәсәлән, кызу канлы булулары сәбәпле, радикаль юлга басарга да күп сорамаган Кавказ укымышлыларыннан аерылып торганнар. Ахыр чиктә кайбер татар галимнәре дә корал алып каршы торырга кирәктер, дигән ялгыш нәтиҗәгә киләләр. Әлбәттә, алар бик яхшы аңлап бетермиләр: бу юл бик куркыныч булачак, күп кан таләп итәчәк һәм җиңү дә әле вәгъдә ителми. Бу юлны халыкка җиткерүне, аңлатуны Габдулла Галиев дигән кеше үз өстенә ала. Халыкта ул Батырша исеме астында билгеле була.

Батырша 1715 еллар тирәсендә татарлар яшәгән Карыш (хәзерге Башкортстанның Балтач районы, Югары Карыш авылы) авылында мулла гаиләсендә туа. Ул заманасы өчен дини

яктан зур белемгә ия була. Башта әтисеннән сабак ала, аннары Тайсуган авылында (хәзерге Әлмәт районы) Габдрахман мулла мәдрәсәсендә укый, төпле дини белем һәм тәрбия ала. Ахырда Ташкичү авылында (хәзерге Арча районы) мәшһүр имам Габдессәлам Уразмөхәммәд җитәкчелегендә дини һәм дөньяви белемен камилләштерә. Ул Казан якларында шәкерт булып ун ел чамасы укый (1734–1744 еллар). Аның ике тарихи ядкяре сакланып калган, беренчесе – халыкка мөрәҗәгате – «Тәхризнамә», икенчесе – патшага хаты – «Гарызнамә». Бу әсәрләрендә ул халыкны корал белән көрәшергә өнди, ахыр чиктә, уңышсызлыкларга очрап, һәлак була.

Әлбәттә, Батырша тәкъдим иткән юл Аднаш хафизның «Сиражел-колүб» әсәрендә тәкъдим ителгән юлның капма-каршысы булып тора. Аднаш хафиз беркайчан да мондый радикаль юл сайламый, чөнки ул моның, файдасына караганда, зарары күбрәк булачагын сизенгәндер. Дөрестән дә, корал белән каршы тору аркасында бик күп халык кырыла, ә кеше гомере – ул иң кыйммәтле нәрсә булып тора. Шуңа күрә Аднаш хафиз тыныч, коралсыз юлларны сайлый. Батырша тәкъдим иткән юл бу хезмәттә татар укымышлыларының халык өстенә килгән авырлыклардан чыгу юлларына карата уйлап табылган карашларны чагыштырып күзәтү өчен генә телгә алынды. Ә инде мөселманнарның мөфтияте барлыкка килгәннән соңгы чорны карап тикшерү биредә максат итеп куелмады.

## ЙОМГАК

